1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН

2015 АВГУСТ № 8

# СӨЮМБИКӘ

БЕЗ –
ЯЛГЫЗ ТҮГЕЛ
*хатын-кыз һәм сәясәт*

ТӘКЪДИР
КҮЛМӘК ТҮГЕЛ
*үкенү катыш сагыну*

ИДЕЛИЯ
СЫЙЛЫЙ:
*американча
иртәнге аш*

Эльмира
КӘЛИМУЛЛИНА:

«ЧЕМПИОНАТ
ТАҢ КАЛДЫРДЫ!
ТЫ-РЫШ-ТЫК!!!»



PRESSA.RU



70
1945–2015

# Сугыш язган хатлар

**Барый Галимуллин — Таузар авылы егете. Армия хезмәтенә алынганчы колхозда эшли. 4 ел Кызыл Армия сафларында хезмәт итә. Бөек Ватан сугышына 1941 елның 1 июлендә үк китә, туганнарына хатлары килеп тора. Ул 1944 елның 3 сентябрендә һәлак була. Эстониянең Выру шәһәрендә җирләнә.**
**Низаметдин Сәлахов 1908 елда Карадуган авылында туган. Сугышка кадәр колхозда бригадир булып эшләгән. 1941 елның 27 июнендә сугышка киткән һәм шул ук елның октябрендә инде хәбәрсез югалган...**

**Сәлахов Низаметдинның сугыштан язган беренче хаты:**

«Сагынычлы хат. Сезки вә хөрмәтле булып торучы бу дөньяда мәңгелек булган тормыш иптәшем Миңлебикә. Сиңа иптәшең Низамнан бик сагынып, бер күрергә зарыгып бик күп сәламнәремне җибәреп калам. Сәлам шулай ук улым Хәйдәргә, кызым Зәйтүнәгә һәм дә Нураниягә. Әбиләрнең барчасына күп сәлам диярсез. Сәлам шулай ук Җәләй абыйларга, Хәким абыйларга, Шәрип дус белән Вәли дуска.

Әхмәт белән без бер эшелонда барабыз, Гаптерәуфләр бездән алда чыгып киткәннәр иде, куып җиттек инде. Безне кай якка барасыз дип сорасагыз, без әлегә Мурманский юлы белән барабыз. Бикә бәгърем, авылда ни хәлләр бар соң? Бер кайтып күрер көн булырмы икән соң инде? Шултикле күрәсем килә инде.

Минем, бәгърем, әлегә точный адресым юк. Яңадан хат язарга туры килсә салырмын әле. Адресны да язармын, исән булсам. Бикә, сиңа әйберләрне Казанда салдым. Бар нәрсәм дә сиңа кайтыр. Исән-сау кайтып күрешергә насыйп булса ярар иде инде. Бу хатны Ленинградтан салдым. Безгә дә барып керергә озак калмады инде. Нишләргә дә белгән юк. Хуш-сау бул.

Хат язылды 17.07.1941 ел.»

**Галимуллин Барыйның әнисе Гафифәгә язган хаты:**

«Хат башы. Сезки туган илдә яшәүче газиз әнигә улыгыз Барыйдан бик сагынып бик күп сәлам. Шулай ук Гөлфарыйга, Маһанига, Габделхәйгә, Әминәгә, Мөнәвәрәгә бик сагынып бик күп сәлам. Шулай ук башка агайнеләргә и күршеләргә сагынычлы күп сәлам. Бу да мәгълүм булсын: үзем таза-сау. Шулай ук сезне дә таза-саудыр дип беләм. Шаять таза булсагыз кирәк. Үзегездән бу хәлдә хат алганым юк. Әтидән бер хат алдым. Әни сине авырта дигән. Синең өчен бик кайгырам. Әни, син дә авырткач бик җайсыз булыр инде. Абыйдан да хат килми икән. Аның өчен дә борчыла торгансыздыр. Әни, мин шул иске урынымда ич, минем өчен кайгырмагыз. Мин үзем сезнең өчен бик кайгырам. Ашарыгызга начардыр. Мин дә ярдәм итә алмыйм. Әни, синең авыруыңны ишеткәч, үзем дә бик борчылып торам. Тормышлар авырга калды. Әни, бу хатны ашыгып кына яздым. Башка язар сүзләрем юк. Шуның белән сүземне бетерәм. Ярый, хәзергә хушыгыз, аннан шуны беләсем килә: сатып алырга оннар бармы, юкмы? Һәм хакын әйтеп язысыз, кыйммәт торамы? Адрес: 2375 п.п. часть 177. Получить Галимуллину Борису Исхаковичу.

13.01.1943 ел.»

Бу хатлар Балтач районы Карадуган авылында урнашкан «Себер тракты тарихы һәм Муса Җәлил» музеенда саклана.

**Хөрмәтле укучыларыбыз! Гаиләгездә фронттан килгән хатлар саклана икән, редакциягә җибәрә аласыз. Хатларны сайтыбызда (www.syuyumbike.ru), ә иң кызыклыларын журналда бастырырбыз. Сайтыбыз аша сугыш кырларында ятып калган якыннарыгыз турында мәгълүмат таба аласыз.**

# Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2015

1926 елдан башлап «Азат хатын» исеме белән чыкты. 1991 елда «Сөембикә» итеп үзгәртелде. Хатын-кызларның бөтентатар айлык әдәби-нәфис журналы 1913–1918 елларда чыккан «Сөембикә» журналының дәвамчысы.

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электроннное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кульъязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.




**Директор-баш мөхәррир**
Ләйсән Рәфикъ кызы ЮНЫСОВА

**Редколлегия:**
Нурия Беломоина, Зилә Вәлиева, Нәбирә Гыйматдинова, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Айрат Сибагатуллин, Иркия Төхвәтуллина, Розалина Шаһиева, Гөлназ Шәйхи.

**Редакциянең гомуми телефоны** 222-09-77
**Директор урынбасары**
Рәмзия Кашапова 222-09-78
**Баш мөхәррир урынбасары**
Гөлнур Хәсәншина 222-09-78
**Җаваплы сәркатип**
Лариса Маликова

**Сайт мөхәррире:**
Сөмбел Гаффарова

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

**Дизайн-макет:**
«ASAFIN GROUP»
**Верстка:**
Лариса Маликова

**Тышлыкта:**
Эльмира Кәлимуллина
Фото: Денис Горийко

**Бүлек мөхәррирләре:**
Мәдинә Авзалова
Лилия Гәрәева
Эльмира Закирова
Роза Камалетдинова
Асия Юнысова
**Фотокорреспондент**
Газинур Хафизов
**Корректор**
Фирдәвес Исмәгыйлева
**Гамәли хезмәткәрләр:**
Нәфисә Әскәрова
Ленар Хәкимов

Формат: 225х290 мм.
Күләме 64 бит.

Басарга кул куелды: 3.08.2015 ел.
Заказ О-2090.
Тираж 6378.

**Учредитель:**
Акционерное общество «ТАТМЕДИА»




ТР Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
**www.syuyumbike.ru**
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77
Язылу индексы: 73002

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикә»
р/с 40702810700000005657
к/с 30101810100000000815
в АИКБ «Татфондбанк» г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205815
КПП 165802002





PRESSA.RU



# ҮЗ ИЛЕМДӘ ЯМЬЛЕ МИҢА БӘРӘҢГЕ БАКЧАСЫ ДА?..

## Россия халкы җәйге ялын кайда уздыра








- чит илгә чыгарга җыенам
- үзебезнең ил буенча сәяхәт итәргә телим
- беркая да бармыйм бакчамда ял итәм, балык тотам
- ял алу мөмкинлегем бөтенләй юк

*мәгълүматлар алдагы 6 ай өчен

## Җәйге ялларын үткәрүгә нинди сәбәпләр аркасында үзгәрешләр керткәннәр

Илләр арасындагы «тимер пәрдә» күтәрелгәч, «безнең турист», әкренләп булса да, үзе өчен «яңа дөнья»лар ачарга кереште: Төркия белән Мисырдан башлаган иде, бераздан Америкага, моңарчы исемен дә ишетмәгән утрауларга ук барып җитте. Әмма соңгы вакыттагы вакыйгалар туризмның үсешенә нык аяк чалды. Икътисадый кризис, санкцияләр кесәләребезне шактый җиңеләйтте. Моңарчы популяр саналган курортларның (мәсәлән, Грециядә) дәрәҗәсе төште. «Төсле» революцияләр дулкыны, Африканың төньягында, Якын Көнчыгышта, Украинада булган коралл бәрелешләр дә «утка май сибү» белән бер булды. Күпләгән туроператорлар, авиаөкташучылар бөлгенлеккә төште. Икенче яктан – безне хәзер Кырым курортлары, Олимпия кабул иткән Сочи көтә!




- акча җитмәү
- ватанпәрвәрлек хисләре
- туроператорлар тарафыннан алдану, туроператорларның банкротлыкка чыгуы
- виза алу белән мәшәкатьләр туу
- бандитлар һәм радикаль террористларның һөҗүменнән курку
- чит ил халкының безне өнәп бетермәүләреннән курку
- башка сәбәпләр



## Туристлар Татарстанны – Казанны сайлый!






Болгар һәм Зөя тарихи музей-тыюлыклары торгызылганнан соң, Татарстан Россиядә туристлар иң күп йөри торган биш төбәкнең берсенә әйләнде. Ә быел, чемпионат уңаеннан, Казаныбызга туристлар ташкыны агыла гына! Ярышларны тамаша кылырга 100 меңгә якын турист килде. Рәсми делегацияләр, чакырылган кунаклар, оештыручылар, катнашучылар – дөньяның 190 га якын иленнән барысы 7 меңгә якын кешене – калабызның иң затлы кунакханәләре, Спортчылар Авылы кабул итте. Килүчеләр өчен дип каланың 30 кунакханәсендә 15 мең урын әзерләнде. Туристлар өчен исә Казандагы 156 кунакханә һәм хостелның һәркайсының ишеге ачык. Гомумән алганда, ел ахырына кадәр Татарстан башкаласы 2 миллион турист килүен көтә.

# Баш мөхәррир сүзе



Август ае. Уңышларны барлый торган ай. 25 ел элек кенә даулап-шаулап алган суверенитетыбызга елый-көлә сөенгән ай. Бар татарның башкаласы булып торган Казаныбыз көнен бәйрәм итә торган ай. Горурлану ае. Тарих битләрен актарып чыгу вакыты...

Тарихын белмәгәннең киләчәге юк та юк. Ә яңа көнен кайгыртмаганның киләчәге дә, тарихы да булмый – яңа битләр өстәп тормасаң, ул өзелеп калып, юкка чыга. Шуңа да Татарстан елъязмасындагы һәр яңа сәхифәгә сөенергә кирәк безгә! Яңа технологияләр табып торучы акыл ияләрен безгә җыючы Иннополиска да, Казанны тагын игътибар үзәгенә куючы Дөнья чемпионатына да. Чыгымнарны гына санамыйк әле – акчаның аның беркайчан да җиткәне юк, уңышларыбызны, алгарышлы адымнарыбызны саныйк бүген! Безнең тарих китабында мескенлек булмасын! Кайсыдыр илдә эш урынында елап ала торган бүлмәләр бар икән – бушанасың да, яңадан көр кәеф белән эшеңне дәвам итәсең (хатын-кызлар булган оешмаларда бик тә кирәкле бүлмә бу – безнең күңелләр бигрәк тә нечкә, матурлыкка, яхшыга бигрәк тә нәүмиз шул!). Тормышның бар күңелсез якларын күңелдән бушатып торып, якты караш белән карап карыйк әле без дә!

Әйе, авыр чорга кердек, әмма ничек матур итеп! Татарстан, Казан белән горурланырлык итеп! Болгарыбыз – Юнеско хәзинәләре исемлегендә, Казан Кремленнән ераклардан килгән кунаклар өзелми... Килсеннәр – җуймаган тарихыбыз да, рухи-мәдәни байлыгыбыз да бар! Бакчаларыбызда бөтен татар халкына бүләрдәй зыңлап торган алмалар өлгереп килә, тормышыбызга җуелып барган кыйммәтләр янәдән кире кайта!

Әйе, яхшысын гына күрәсе килә бүген – начары ардырды. Шаулыйдаулый торган вакыт та түгел – дөньяга тынычлык тансык! Тату-имин яшәп, спортта, фәндә, хезмәттә, тормышта җиңүләр яулап, һәр казанышыбызның кадерен белеп яши торган чордыр бу – чирек гасырлык дәвернең август ае...

Яшәргән һәм яңарган Казан урамнарында яшьләр туган телебездә сөйләшә... Балачагым бакчасы – Горький паркына тиеннәр кайткан... Анда тагын кино күрсәтәләр, шигырь укыйлар... Кабан күлендә янә аккошлар йөзә. Казансу чистарган. Ә аның өстендә дөнья сәхнәләрен яулаган татар кызлары татар җырын яңгырата! Сөенәм! Шулай үткәнеяңасы бергә кушылып, бер якты җырга үрелеп, әкиятләрне чын итеп язылсын безнең тарих, без яшәгән дәвер! Киләчәгебез якты, мәгънәле, матур булсын!

*Ләйсән ЮНЫСОВА*

PRESSA.RU



## БЕЗНЕҢ ТЫШЛЫКТА





**КАЗАН, ЧЕМПИОНАТ, ДРАЙВ!!!**
Э. Закирова
12



## ЗАМАН ҺӘМ БЕЗ





8
**ФИДАКАРЬЛӘР КАПКА АЧТЫРА**
М. Авзалова

## ТАТАР ДӨНЬЯСЫ





24
**ИДЕЛДӘН – ЕНИСЕЙГА КАДӘР**
Ф. Мостафина



20
**ТОРМЫШ ЯЗГАН КАГЫЙДӘЛӘР**
Г. Сафиуллина



28
**ТАЛПЫНГАН КОШ ОЧМЫЙ КАЛМАС**
Н. Кәримова

# ЭЧТӘЛЕК


МӘДӘНИ ТОРМЫШ 



36

ТОЛЫМ
Р. Рахман

ШУЛАЙ УК: 

16

КАЗАН БАКЧАЛАРЫ
А. Юнысова

42

«ЯШЬЛЕК МИНА ӨЧ МӘРТӘБӘ КИЛДЕ»
М. Маликова

ЯШӘЕШ 



48

БАЛАЛАР ХАКЫНА...
Г. Сафиуллина

52



КЕМДӘ НИЧЕК, БЕЗДӘ ШУЛАЙ
Л. Рәхмәтуллина

ХАТЫН-КЫЗ ГАЛӘМЕ 



58

БИЗӘКЛЕ КҮН ЯНЧЫК

КИЛӘСЕ САНЫБЫЗДА: 

КИТАПСЫЗ... УКЫТУЧЫ. Милләттәш.

Гүзәл Яхина. Яңа романнан өзек.

«КҮҢЕЛЕМДӘ ИКЕ ЯЗ». Бер җыр тарихы.

НАХАК СҮЗ. Булган хәл.

ИЛСАФтан мастер-класс.




PRESSA.RU




*1980 елның сентябрендә, ТАССР төзелүнең 60 еллыгына багышлап, Лейпциг халыкара ярминкәсендә Татарстан казанышларын күрсәтү мөмкин булды.*

Мин ул вакытта да КХТИның чит телләр кафедрасында немец теле укыта идем. Татарстан делегациясе составында күргәзмәгә тәрҗемәче булып барырга тәкъдим иттеләр.

ТАССР Министрлар советы экспонатлар сайлау, аларны Германия Демократик Республикасына алып китү өчен әзерлек чаралары күрә башлады. Лейпциг – Германиянең эре сәнәгать, мәдәният һәм фән үзәге. Ул китап басу һәм китап сәүдәсе, музыка, университетлар һәм студентлар шәһәре буларак дөньяга танылган. Урта гасырлар башында ук базарлары белән дан тоткан. Заманында бөек композитор Себастьян Бах изге Фома чиркәве каршында оештырган атаклы «Томанеркор» малайлар хорын җитәкләгән.

Димәк, анда үзебезнең сәнәгать казанышларыннан тыш, республикабызның алга киткән мәдәниятен дә күрсәтергә мөмкин булачак. Атаклы җырчылар, музыкантлар, Татарстан дәүләт җыр һәм бию ансамбле дә ярминкәгә җыенды. «Сез кайдан, дип сорасагыз, без Казаннан, Иделдән», – дип, мәһабәт тавышы белән һәммәсен әсир иткән Айрат Арсланов, Зилә Сөнгатуллина, Вафирә Гыйззәтуллина кебек җырчыларыбыз безнең арада иде. Миңа шигырьләрне генә түгел, җырларның да кыскача эчтәлеген тәрҗемә итәргә кирәк иде. Ә биюләрне яратып кабул иттеләр. «Әпипә» күңелләренә хуш килде. «Кәккүк»не җырлагач, Нәфисә Василованы кат-кат чакырып чыгардылар. Концертлардан соң журналистлар сорауларга күмә иде. Сизелеп тора, татар халкы турында бөтенләй дә белмиләр. Безне кайдадыр Памир тауларында, йә Себер тайгаларында яши дип күзаллыйлар. Картадан Татарстанны күрсәткәч кенә, Россиянең нәкъ үзәгеннән килүебезгә инаналар. Мин үзләренә нефть җибәреп торучы «Дуслык» нефть үткәргеченең бездән юл алуын сөйлим.

ТАССР экспозициясенә керү юлында өч модификациядә җыелган КамАЗлар, бездә җитештерелгән вертолет каршы ала. Калган экспонатларны урнаштырыр өчен СССР павильоны эчендә безгә 100 квадрат метр урын бирелгән иде. Анда «Дуслык» нефть үткәргеч моделе һәм авиатөзелеш предприятиеләре җитештергән соңгы маркалы самолет макетлары урын алды, шул чор өчен бик уникаль исәпләнгән компрессор куелды, безнең данлыклы мехкомбинат экспозициясендә балалар, хатын-кызлар туннары, бүрекләр, төрле төстәге һәм фасондагы бияләйләр халыкта зур кызыксыну уятты. Сатып алырга теләүчеләр дә күп иде. Ләкин аларның «МУСТЕР», ягъни үрнәкләр генә икәнен аңлатырга туры килде. Безнең кабатланмас татар читекләре һәм чүәкләре күргәзмәгә килүчеләр күңеленә аеруча хуш килде. Кулдан чигелгән бу нәфис аяк киемнәре чын-чынлап сәнгать әсәренә тиң иде! Шунда ук китап нәшрияты чыгарган китаплар, географик карталар, Казан күренеше төшерелгән открыткалар белән танышырга була иде. Янәшәдә генә Чистай сәгать заводы продукциясе, төрле хронометрлар тезеп куелган: бәрелеп тә ватылмый, су керми торганнар, хром, корыч, титаннан эшләнгән, алтын белән йөгертелгән сәгатьләр... Без, горурланып, космонавтларның кулларында Чистай сәгатьләре иде дип сөйләдек. Күргәзмә ахырында медицина инструментлары заводы экспонатлары белән таныштырдык, хирургиядә кулланыла торган инструментлар һәм җайланмаларны күрсәттек. Кызыл күннән милли нәкышлар белән бизәп ясалган чатырда бик дәрәҗәле кунакларны кабул иттек, аларны чәк-чәк, бал белән сыйладык. Атаклы аш-су остасы Юныс Әхмәтҗанов җитәкчелегендәге ашчылар милли ризыклар әзерләргә махсус килде бирегә.

Хәтергә уелып калган ул кадерле көннәр еш исемә төшә. Бүген дә яраткан эшемдә, Казан технология университетында (КХТИ) немец теле укытам. Республикабыз казанышлары, Лейпциг күргәзмәсе хакында студентларыма еш сөйлим.

Роза САДЫЙКОВА.
Казан.

*Кешене гомер буе җыр озатып бара. Җыр-моңга һәвәслекне табигать бар кешегә дә бердәй бирмәсә дә, матур җырны һәркем ярата.*

Без үскәндә тыңлаган җырларны хәзерге яшьләр тыңламый, чөнки

аларның күңел халәте башка. Күрәсең, нинди көйгә тартылуыбыз эчке дөньябызга бәйледер. Менә чит илләрдә яшәүче татарларның милли көйләрен тыңласаң да, аларның безнекеннән үзгә булуын беләсең.

Әйтер идем, милли җыр сәнгатебез рухи тормышыбызның индикаторы кебек. Рухи тормыш ярлыланган саен, җырлар да саега. Әйтик, кайбер башкаручыларның концертыннан чыгабыз да, кайтканда көен күңелдән кабатлап карыйм әле дисәң, ник берсе истә калсын. Бу сиңа Габдулла Рәхимкуловтан беренче тапкыр ишеткән «Арча кичләре» җыры түгел инде. Аны заманында бер ишетүдән отып калган идек. Яшьләр чит илләрдә күп йөри, шуннан ияреп кайткан көйләрне татар җырына кушып җырлыйлар. Өстәвенә, сүзләре дә, көе дә үземнеке дип җибәрә кайберләре. Башкаручысы да шул ук бер кеше икән, бу әсәрнең чиле-пешле буласы көн кебек ачык. 1968 елда ук иҗат ителгән «Китмә, сандугач!» җыры ни өчен бүген дә сәхнәләрдән төшми? Чөнки аны өч иҗатчы (бер түгел!) дөньяга чыгарган: шагыйрә Гөлшат Зәйнашева сүзләренә СССРның халык артисты, композитор Рөстәм Яхин көен язган һәм шуны Россиянең халык артисты, бөек җырчы Илһам Шакиров халыкка ишеттергән.

Мин җәйне сагынып көтеп алам. Шәһәр тормышыннан арынып, гаиләм белән авылдагы бакчамда кайнашам. Эш эшләгән арада рәхәтләнеп Фәридә Кудашева, Мөнирә Булатова, Зифа Басыйрова, Таһир Якупов һәм хәзер дә сәхнәләрдә еш күренүче Рабига Сибгатуллина язмаларын тыңлап киенәм. Казаннан «Болгар», Уфадан «Юлдаш» радиоларын да ачкалыйм. Алар да көн дәвамында күңелгә хуш килердәй ике-өч җыр биреп куйгалый: җырчылары йә Флера Сөләйманова, йә Рафаэль Ильясов, йә Әлфия Афзалова була. Уфадан сирәк-мирәк Илфак Смаков, Зәки Мәхмүтев язмалары да ишетелә, аларны тыңлагач та күңелләр күтәрелеп китә.

Уйлап куям, кая икән элекке шикелле музыка белгечләре, чын композиторлар һәм, ниһаять, эфир аша бирергә ярыймы-юкмы икәнен ачыклаучы сәнгать советлары?

Яшьләргә үрнәк булырлык җырчылар хәзер дә бар ул. Шуларның берсе – Мирсәет Сөнгатуллин. Тик аның башкаруындагы җырлар бик сирәк яңгырый. Бүгенге көндә Мирсәет Сөнгатуллин кебек җырчыларның иҗатын Татарстан дәүләт радиосы һәм Казанның «Тәртип FM» радиосы пропагандалый. Әмма радиоалгычлар бу дулкыннарны күп җирдә тотмый. Кешеләрнең җанын дәвалый, яшәргә дәртләндерә, күңелен күтәрә торган матур җырларны һәм шуларны халык күңеленә үткәзеп җырлый белүче җырчыларны онытмыйсы иде бит.

*Хәким ГЫЙЛӘҖЕВ.*
*Азнакай.*
*Фотода: М. Сөнгатуллин «Тәртип FM» радиосында.*

*Бераз гына сәеррәк кешеләр һәр авылда була бит ул. Аларның сәерлекләрен еллар үткәч тә сагынып искә алалар, кызык итеп сөйлиләр. Безнең Көек Ерыкса авылында да бар алар. Шул уңайдан бер гаилә турында языйм әле.*

Мөхәммәди абый белән Бикә апа ике кыз, бер ул тәрбияләп үстерделәр. Әти-әниләре вафат булганнан соң, тормыш алып бару аларның өчесенә калды.

Олы кызлары Аврора («Аврора» крейсеры хөрмәтенә кушылгандыр инде) җир җимертеп ирләр эше башкара: мич чыгара, бура бурый, койма тота, түбә яба. Тимерчелек эшенә дә кулы ятып тора. Таза, нык бәдәнле, көчле кыз ирләрдән һич калышмый. Көч-куәт дигәннән... Бервакыт Минкә сазлыгында баткан атны берүзе тартып чыгара ул.

Кече кызлары Гүзәлия дә апасына охшаган. Җәен-кышын колхозда атлы эштә эшли: фермага салам, печән ташый, кырга тирес чыгара. Кирәк булганда, такта да яра. Озын буйлы, таза гәүдәле кызны ирләр белән урман эшенә дә җибәрәләр.

Уртанчы бала булып туган Рәфкать кызларның гел киресе. Нечкә күңелле Рәфкать өстендә өйдәге бөтен эш: идән юа, су китерә, сыер сава, кызларның киемнәрен ямый, ашарга пешерә. Почта эшен дә җиренә җиткереп башкара ул, һәр өйдә көтеп кенә торалар үзен. Рәфкать абыйның бик яраткан тагын бер шөгыле бар: ул кызлар белән җырлый-җырлый кульяулык чигә, тамбур энәсе белән нәфис итеп челтәрләр үрә. Аның чиккән әйберләренә бөтен кеше сокланып карый.

Кичке якта колхоз эшеннән кайтучы ир-атлар инештә хатын-кызлар белән кер чайкаучы Рәфкатьне күреп елмаеп үтәләр. Ә шофер Сәлим, елмаеп-көлеп кенә калмый, очраган саен: «Рәфкать, кайчан кияүгә чыгасың инде?» – дип аптырата. Мондый көлүләрдән тәмам туйгач, Рәфкать абый Сәлимнең үзен кызык итә.

Беркөнне сеңлесенең күлмәген киеп, корсагына мендәр кыстырып, кулына фанерадан ясалган чемоданын тота да, Сәлимнәргә юнәлә. Аларның төшке ашны ашап утырган чаклары була. Рәфкать килеп тә керә, тегеләр танып алганчы һөҗүмгә дә күчә: «Сәлим җаным! Мин балага уздым бит. Хәзер нишлибез инде? Бөтенләйгә дип килдем сезгә, зинһар, ачулана күрмәгез...» «Кыз»ның бу сүзләреннән Сәлим дә, хатыны Мәймүнә дә телсез калалар.

Шушылай кызык иткәннән соң, Сәлим егеттән башкача көлми, үртәми инде. Илленче еллар ахырында өч туган да Урал якларына чыгып китә. Еллар үткәч, Рәфкать абый сабан туена хатыны һәм игезәк балалары белән кунакка кайта. Ул кайткач, теге хәлне искә төшереп, авыл халкы тагын бер көлешеп ала.

*Рәим ГОБӘЕВ.*
*Мамадыш районы,*
*Яңа Комазан авылы.*

***Хөрмәтле укучыларыбыз! Сездән хатлар көтеп калабыз. Безнең адрес: Казан, Декабристлар урамы, 2. e-mail: ssuum@yandex.ru***

PRESSA.RU



# ФИДАКАРЬЛӘР КАГЪКА АЧТЫРА



Аның хезмәт биографиясе безнең күз алдында язылды. Ул Татарстанның иң танылган журналистларыннан иде. Халыкка Югары Советтан берсеннән-берсе кайнар-үткен мәкаләләрне ирештереп торучы ул булды. Татарстан референдумына каршы көрәш барган көннәрдә «Известия Татарстана» журналисты, Дәүләт Советы депутаты Зилә Вәлиева, Мәскәүгә барып, Россия Югары Советы Рәисе Руслан Хасбулатов белән әңгәмә кора. Бик катлаулы, киеренке чорлар иде ул. Татар журналистының берсеннән-берсе зәһәр, маңгайга бәреп бирелгән сораулары Руслан Хасбулатовны гаҗәпкә калдыра. Ә бәлкем, ачуын да китергәндер. Бу сөйләшүдә ул чагында һәркайсыбызны уртак борчыган сораулар яңгырый: «Руслан Имранович, Борис Ельцинның автономияле республикаларга карата позициясе Татарстанга килгәч, ап-ачык итеп белдерелде: «Йота алган кадәр мөстәкыйльлек алыгыз...» «Ялгыш позиция булган бу, – ди парламент җитәкчесе. – Россия Федерациясе составына кергән республикалар – бербөтен Россия дәүләтенең аерылгысыз өлеше. Без аларга чикләнмәгән автономия бирәбез...» «Татарстанга Президент нигә кирәк булды инде?.. Россия Президенты аны теләсә кайчан эшеннән төшерә ала бит», – дигән җөмләләр дә ычкына аның авызыннан. Бу әңгәмәне соңыннан бик күп газеталар күчереп бастыра. Көннәрдән бер көнне аның үзен Татарстан Югары Советы Рәисе урынбасары итеп сайлыйлар! Республиканың киләчәге хәл ителгән мөһим чор, сессия саен Югары Совет бинасы каршында халык... Кыю-зәһәр телле депутатлар... Вакыйгалардан бер адым алда бару өчен аңа нинди көч, нинди зирәклек кирәк булгандыр?!

ИКЕ ДИСТӘ ЕЛ ЭЛЕК ОЕШКАН «ТАТАРСТАН ХАТЫН-КЫЗЛАРЫ» ИҖТИМАГЫЙ ОЕШМАСЫ ҮЗ ТИРӘСЕНӘ РЕСПУБЛИКАБЫЗНЫҢ ИҢ ЗИРӘК, ИҢ БУЛДЫКЛЫ ХАНЫМНАРЫН, ТУТАШЛАРЫН ТУПЛЫЙ АЛДЫ.

Язмыш адәм баласын үзе теләгән юлдан йөртә: кемнедер күтәрә, күкләргә чөя, ә кемнедер, киресенчә, күктән җиргә төшерә дә, ач күзеңне, дөнья бу дигәндәй, чынбарлыкка кайтара. Зилә Рәхимҗан кызы Вәлиева үз гомерендә нинди генә дәрәҗәле һәм җаваплы вазыйфалар башкармаган: матбугат эшләре, телерадиотапшырулар һәм гаммәви коммуникация чаралары министры, Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары; Премьер-министр урынбасары – мәдәният министры да булып эшләде. Ул – илебезнең иң көчле сәясәтче хатын-кызлары исемлегендә. Хатын-кыз кайда да булдыра, дигәнне үз мисалында раслап бирде. Бүген исә ул «Казан Кремле» дәүләт тарихи-архитектура һәм сәнгать музей-тыюлыгын җитәкли. Һәм нинди генә вазыйфа биләмәсен, үзенең җан тарткан, күңел тарткан эшенә тугры кала килә. Инде 20 ел дәвамында ул – «Татарстан хатын-кызлары» иҗтимагый оешмасы рәисе.

Әле күптән түгел генә аның Россия Федерациясе Советы Рәисе Валентина Матвиенко кулыннан мәртәбәле бүләк алуына – Россия Федерациясе Советы Рәхмәтенә лаек булуына – без дә шатландык. Аның адресына яуган рәхмәт хатлары, чын йөрәктән әйтелгән рәхмәт сүзләре болай да җитәрлек анысы. Андыйлары кадерлерәк тә була әле аның.

Урау-урау юллар аша үткән көннәргә кайтып, әкрен генә хәтер йомгагын сүтәбез. Күңелнең иң түренә кереп оялаган да, вакыт-вакыт искә төшеп уйландыра, ә кайчак артта калган көннәр өчен горурлык хисе уята торган ул мизгелләр әңгәмәдәшем сөйләгәннәрдән ап-ачык булып күз алдына килеп баса.

## «Югары»да күп сөйләшеп тормыйлар

– Татарстан Югары Советы депутаты вазыйфасына керешүегезгә ике ел узуга, Сез инде парламент Рәисенең беренче урынбасары. Ничектер барысы да бик тиз булган шикелле. Үзегез моңа әзер идегезме соң?

– Минем өчен ул көтелмәгән тәкъдим булды. Һәм, чыннан да, мәсьәлә күз ачып йомганчы хәл ителде. Югары Совет Рәисе Фәрит Мөхәммәтшинның үзенә урынбасар итеп чакыруына мин шундук: «Юк, – дидем, – минем эш түгел, омтылганым да ул түгел». Ул түземәде, әйтеп куйды: «Юк та, юк, дисең, әзрәк уйлап карыйм диген, ичмасам». «Ярый, алайса, уйлап карармын», – дидем. Җитмәсә, ирем дә чит илдә, кем белән дә киңәшләшә алмыйм. Чыгып барам шулай уйланып Югары Советтан. Каршыма Чаллы шәһәренең ул чагындагы мэры Юрий Петрушин килә. «Нәрсә булды сиңа, нинди борчуың бар?» – ди. «Хәл итәсе мәсьәләм бар, киңәшер кешем дә юк», – дим. Сөйләп биргәч: «Ризалык бирсәң, нәрсә югалтасың? Эшеңә кире кайта аласыңмы? Кайткан очракта да яңа тәҗрибә белән кайтачаксың», – ди.

Шулай итеп, иртән барып, ризалыгымны бирдем. Аннан соң трибунага чыгып, депутатлар алдында имтихан тоттым. Аларның сорауларына җаваплар бирдем. Дулкынланам, ә үзем сиздермәскә, ничек тә сер бирмәскә тырышам. Эшемә керешкәч, булдыра алырмынмы икән, дип, бер-ике көн елап та утырдым әле. Әмма бу сәяси дөнья, балавыз сыгып утырырга вакыт юк. Муеннан эшкә чумдым.

Ни генә димә, Татарстан Югары Советының беренче чакырылышы – ул тарихи парламент. Чоры да нык катлаулы иде бит. Шундый вакытта республика язмышы өчен җаваплылыкны үз өстеңә алу, минемчә, үзе бер батырлык булган ул. Узган гасырның 90 нчы еллар иҗтимагый-сәяси атмосферасын бүген бер сүз белән аңлатуы да кыен. Татарстан ул чагында үзенең икътисадый потенциалын, республиканың масштабын һәм мөмкинлеген күз алдында тотып, союз республикасы статусын алуны максат итеп куйды.

## «Син ялгыз түгел»

– Казанда уздырыла торган төрле фестивальләр, төрле күргәзмәләр, йә булмаса, илкүләм әһәмияткә ия халыкара форумнар... Ул чараларда һәрчак «Татарстан хатын-кызлары» иҗтимагый оешмасының исеме яңгырый. Ничек өлгерәсез барысына?

– Бер без генә оештырмыйбыз аларны. Һәрвакыт нindидер оешмалар белән берлектә башкарыла андый эшләр. Бөтендөнья татар хатын-кызларының «Ак калфак» иҗтимагый оешмасы, «Ак Барс яңарыш» хәйрия фонды, Казандагы «Әнием-Мама» оешмалары белән бергәләшеп

*Теләгеңә ирешүдә бер генә сәбәп тә эзләп азапланма. Синең сәләтеңә дәрәҗәң тәңгәл булырга тиеш!*

үткәрелгән бәйрәм-кичәләр турында әйтүем. Бергәләп эшләү яхшы нәтиҗә бирә. Без гел бер-беребезгә таяныч. Яныңдагы проблемаларны күрә-ишетә һәм иң мөһиме: вакытында шуларны хәл итә белергә кирәк. Бер генә мисал: сабыйларын бала тудыру йортларында калдырган яшь әниләргә кагыла ул. Мондый йөрәк әрнеткеч ямьсез күренешләр, кызганычка каршы, әледән-әле кабатланып тора. Сәбәбе билгеле: кызлар, алданып, бала тапканнан соң нишләргә белми. Ахыр чиктә ул баланы калдырып китә. Әни кеше ялгыз булган, эшсез калган очракта да шушы үкенечле юлны сайлый. Менә кайда проблема... Һәм аны безгә кичекмәстән хәл итәргә кирәк. Чаллы шәһәрендәге кебек бала тудыру йорты бусагасына «бәби-бокс»лар кую да мәсьәләне киеренкелątә генә төшә.

Уйлаштык та, «Син ялгыз түгел» дигән проект башлап җибәрдек. Шуның нигезендә Казандагы 18 нче шәһәр хастаханәсендә кая барып төртелергә белмәгән әниләр өчен ике палата оештырдык. Сигез урынлы. Белгечләр әйтүенә караганда, ана бәбие янында алты айлап яшәсә, ул инде аны беркайчан да ташлап китми. Без менә шуңа омтылабыз да. Әниләр балаларына ияләшсен, алардан да газиз җан иясе юк икәнлегенә

PRESSA.RU



төшенсен, дибез. Биредә әни кеше беренче көннән үк балага кирәкле бар әйбер белән тәэмин ителә. Аларны эшкә урнаштыру хәстәрен дә күрәбез. Ел дәвамында ике палатада 44 хатын-кыз булып чыккан. Шуның дүртесе генә баласын калдырган. Бер уйлаганда, 40 баланы ятимлектән коткардык дигән сүз бит бу.

Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Рөстәм Миңнеханов бу эштә безгә бик булыша. Гомумән, ул балалар язмышына кагылышлы һәр нәрсәгә шулай җитди карый, ярдәм итә. Киләчәктә, акча таба калсак, авыр хәлгә төшкән әниләр өчен махсус бина салдырырбыз, дип торабыз. Хатын-кызларны хәсрәтборчулар кочагында калдырмабыз. Алар ялгыз түгел.

*«Татарстан хатын-кызлары» иҗтимагый оешмасының максаты – хатын-кызларның мәнфәгатьләрен яклау.*

### «Әни бәлеше»

– Белүемчә, бу җәһәттән авыл җирләрендәге хатын-кыз оешмалары да кимен куймый...

– Шулай. Алар безгә үрнәк тә әле. Түбән Камадагы Эльвира Долотказина җитәкчелегендәге хатын-кызлар оешмасы башкарган эшләрне саный китсәң генә дә күпме сөенерлек мисаллар. «Авыл кызы» бәйгесен оештыручы да шулар. Хәрби частька барып, солдатларны «Әни бәлеше» белән сыйлаучылар да шул оешма вәкилләре. Бер генә бәйрәмнән, шәһәр күләмендә уздырыла торган бер генә чарадан да читтә калмый алар. Чаллыда исә Бөек Җиңүнең 70 еллыгы уңаеннан хатын-кызлар оешмасы сирень куаклары утыртып, шәһәрне чәчкәгә күмде. Мисаллар җитәрлек. Эшләрен халык күрә, халык бәяли. Шуның белән кыйммәтле дә ул! Бәлкем, алар тау күчердәй эшләр дә эшләмидер. Ләкин аның һәркайсы күңелгә үтеп керә, янәшәдә генә матурлык, яктылык, игелек барлыгын искә төшерә.

### Рухландыручы бәйрәм

– Бәйге дигәннән... Ел саен үткәрелә торган «Ел хатын-кызы. Ел ир-аты: хатын-кыз карашы» республика бәйгесе соңгы егерме ел эчендә иң популяр, иң дәрәҗәле бәйгеләрнең берсенә әверелде. Гүзәл затларыбыз аны көтеп ала.

– Хатын-кыз бит ул үзе кояш шикелле. Гаиләсе – балалары, ире аның җылысында назлана, аның иркә сүзләрендә коена. Алар – үзләре гел өметтән, шатлыктан торучы язның бер канаты. Без бу бәйрәмне махсус 8 Март көненә туры китереп эшләдек. Икеләтә бәйрәм булсын дидек.

Дөресен әйткәндә, асыл затларыбызның булдырмаган эше юк та. Бүген республикада 2 миллион хатын-кыз яши. Бу – халыкның 53 проценты дигән сүз. Хуҗалыкның нинди генә тармагында эшләсәләр дә, ирләрдән калышмый алар. Белемнәре дә ирләрнекеннән күпкә югары. Хезмәт белән мәшгуль хатын-кызларның 70 проценты – югары һәм урта һөнәри белемле.

Әлеге бәйге заман хатын-кызының яңа образын гәүдәләндерә. Башта бу чара районнарда уза. Аннары җиңүчеләрне, анда катнашучыларны Казанга җыябыз. Һәрьяклап үрнәкләрен, булдыклыларын олылыйбыз, исемнәрен республикага яңгыратабыз. Җиңүчеләр арасында күпме хатын-кыз шушы бәйгедән соң зур уңышларга иреште, дәрәҗәле урыннарга утырды. Тормышы тамырдан үзгәрде дип әйтәсе килә. Төп максатыбыз да шул – әниләрне, кызларны үстерү, күтәрү безнең. Бүгенге заман хатын-кызы үз урынын табарга тиеш. Әйе, хатын-кыз оешмаларының үзләренең проблемалары да юк түгел. Алдынгы карашлы, кулларында ут уйнаткан булдыклы хатын-кызлар белән эшләве, әлбәттә, күңелле. Әйтергә кирәк, үзенә бер горурлык та әле ул! Алар оешманың терәге, киңәшчесе... Мисалга, республиканың табиблар ассоциациясе президенты Ирина Питулова; төрле эшләрдә эшләсә дә, безнең белән араны бер дә өзмәгән Гүзәлия Әхмәдиева; Педагогика фәннәре докторы, Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, атказанган мәдәният хезмәткәре Роза Баһаутдинова; «Татэнергосбыт» ачык акционерлык җәмгыяте директорының персонал белән идарә итү буенча директор урынбасары Рәшидә Вәлиуллова; «Газпром трансгаз Казань» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьнең җәмәгатьчелек һәм массакүләм матбугат чаралары белән элемтә хезмәте җитәкчесе Гүзәлия Минкина кебек эшлекле ханымнарның исемнәрен китерергә мөмкин. Бер яктан караганда, гаилә, бала, эш проблемасы ул һаман искечә, һаман шул килеш кала бирә. Аннан арыну юллары элек тә шулай иде, хәзер дә шул ук. Икенче яктан, тормыш бу оешмаларга да яңалык, төзәтмәләр кертә. Безнең күп кенә яңа проектларыбыз бар. Әйтик, интернет аша бизнес оештыру. Бу максат гамәлгә ашсын өчен оешма, дәүләт, бизнесбердәмлек тарафыннан ниләр эшләп була, ничек ярдәм итәргә?! Бу сорауларга җавапны без табарга тиеш.

Берара Казанда «Татарстанның эшлекле хатын-кызлары» белән бергә «Хатын-кызлар хәрәкәте һәм бүгенге дөнья» дигән темага зур сөйләшү уздырган идек. Безнең тәҗрибәгә, ниһаять, күз салдылар. Ир белән хатын-кыз арасындагы тигезлек проблемасы безнең өчен күз күрмәгән, колак ишетмәгән әйбер түгел. Без инде моңа күптән күнеккән. Без 1917 елдан бирле тавыш бирү хокукына ия. Ә менә Европа илләре моңа 60 нчы елларда гына ирешә алган. Үзегез беләсез, бик катлаулы заманда яшибез. Кая карама – сугыш, бәла-каза... Сугыш барган илләрнең хатын-кызлар оешмалары кайда соң? Алар нишли?! Күрмиләрме алар балалар һәлак булганын, гаиләләр тар-мар килгәнен?! Украинадагы бәрелешләрдә күпме бала харап булды. Ул илләрнең җитәкчеләренә шундый сорауны бирсәң, белмәмешкә салышалар.

### Мөселман хатыннары

– Бүгенге заман хатын-кызы үз урынын табарга тиеш, дидегез... Нинди алар, ни белән мәшгуль?

– Ни белән мәшгуль булуы әллә ни мөһим түгел. Иң мөһиме – ул үзе сайлаган һөнәрен ничек итеп башкара бит. Үрнәкме, үзе артыннан ияртердәй көч бармы анда? Безнең хатыннар гаиләсенең генә түгел, иленең, яшәгән җиренең проблемаларын да хәл итә алырдай көчкә ия.

Былтыр Казанда бик җитди темага халыкара фәнни-гамәли конференция булып узды. БМОның мөселман хатын-кызлары хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкиле хатын-кызны җәберләү турында сөйләшик дигән тәкъдим белән чыкты. Мин каршы булдым. «Безнең хатыннар бөтенләй икенче. Алар беркайчан да гаилә, бала тәрбияләү белән генә чикләнмәде. Алар безгә илне идарә итәргә, дәүләтчелекне үстерүгә булыша», – дидем. Конференциянең темасын: «Бүгенге заман мөселман хатын-кызлары» дип төзәтергә тәкъдим иттем. Шулай эшләделәр дә. Нәтиҗәдә, хатын-кыз хокукларын саклау, алар мәнфәгатен кайгыртуга багышланган олы, эшлекле сөйләшүгә әверелде ул.

Көзгә таба Санкт-Петербург шәһәрендә «Евразия хатын-кызлары форумы» булачак. Анда хатын-кызлар белән эшләүдә олы тәҗрибәсе булган «Татарстан хатын-кызлары» иҗтимагый оешмасыннан да вәкилләр катнашачак. Мондый җыенга тикмәгә чакырмаслар: әйтер сүзләре, уртаклашыр тәҗрибәләре бар аларның...

Журналисттан дәүләт эшлеклесенә кадәр күтәрелгән Зилә Вәлиева Татарстанның һәм хатын-кыз кавеменең лаеклы вәкиле буларак танылды. Аның хезмәт вазыйфаларын һәм иҗтимагый эшен башкарганда яулаган абруе иң югары даирәләрдә катлаулы төеннәр чишкәндә дә ярдәм итә. Дөньяның атаклы музейчылары, зур сәнгатькәрләр, сәясәтчеләр, хәтта АКШның Дәүләт департаменты җитәкчесе Хиллари Клинтон да Татарстан вәкиле Зилә Вәлиева белән санлашты, иркен аралашты.

Зирәклек һәм тырышлык, фидакарьлек ябык капкаларны да ачтыра, халкыбызның дәрәҗәсен күтәрә.

Әңгәмәдәш –
Мәдинә АВЗАЛОВА.












## ИСТӘЛЕКЛӘРДӘН

– Югары Советка ул чагында бик күп мөрәҗәгатьләр, хатлар килә торган иде. Эшемне шуларны ачыклаудан башладым. Көн саен бер төркем депутатлар белән йә заводка эшчеләр янына, йә ерак бер районга авыл хезмәтчәннәре белән очрашуга чыгып китәбез дә дөньябызны онытып йөрибез. Халык белән аралашу, бер яктан, рәхәт, икенче яктан караганда, катлаулы да. Алар бездән сорауларына җавап көтә. Вәгъдә биреп котыла торган заман түгел. Һәр адымың – күз алдында. Хәзер дә искә төшкән саен уйлап куям: бик болгавыр чор булган бит ул. Хәтта шул хәлдә дә без дөрес юлны сайлый алганбыз. Бөтен эш ачыктан-ачык эшләнде бит. Сайлаучылар ни эшләп йөргәнебезне белеп-күреп торды. Бәлкем, шуңадыр да ил таралганда да безнең республика аягында нык торып калды. Мин моңа ул вакыттагы Президент Минтимер Шәймиев алып барган зирәк сәясәтнең нәтиҗәсе дип карыйм һәм шулай бәялим. Аның авыл кешесе, җир кешесе булуы, үз тырышлыгы белән муллыкка-иминлеккә юл ярып баруы, тормыш кыйммәтләрен тирәнтен аңлавы коткарып калды безне бәлаләрдән.

1990 елны Югары Советка меңнән артык кандидат арасыннан 250 депутат сайланды. Сайлау органнарында моңарчы беркайчан да шулкадәрле табибның, җәмәгатьче хатын-кызларның булганы юк иде әле. Аларга мөһимнән-мөһим эш йөкләнде: сүз бөтен җәмгыятьне, хакимият системасын тамырдан үзгәртеп кору турында бара иде бит. Атналар буена барган СССР халык депутатлары съезды утырышлары еш кына төн уртасына кадәр дәвам итте. Мондый вакытларда хатын-кыз депутатлар өйдә ач утырган балаларын, ирләрен искә төшерә башлый. Бервакыт Галина Старовойтова түзмәде, мөнбәргә чыкты да: «Хатын-кыз булдык дигәч тә... Әйдәгез, җиңнәрне сызганыйк!» – диде. Минемчә, сәясәттә хатын-кыз булырга тиеш! Бездә сугышучы илләр генералитеты түгел, республика парламенты!

Әйе, безгә һәр сүзне уйлап сөйләшергә, һәр адымны киңәшеп ясарга туры килде. Чөнки без ул чагында мөстәкыйль суларга, йөрергә, гамәлең өчен җавап бирергә өйрәндек. Күпләр, җитлеккән дәүләтләр мисалында, илнең бердәмлеген саклап калу өчен федерализмны ныгытуның мәгънәсенә тиз генә төшенеп тә җитә алмады. Әйтәсе килгәнем: Татарстан моделе суверенитет уены булмады. Ул чорда бик күп дәүләт программалары эшләнде һәм кабул ителде. Халыкны җимерек йортлардан өр-яңа фатирларга күчерү дә шул вакытларда башланды. Бу уңайдан Минтимер Шәриповичның: «Казанның төп халкы каршындагы бурычыбыз бу», – дигәнен хәтерлим. Төрлесе: башкарган эшләребез өчен куанган, борчылган, хәтта ки ниндидер бер курку биләп алган вакытлар да булгалады. Без һәрвакыт нәрсәгә омтылганыбызны белә идек. Кыен чакларда Фәрит Хәйруллович: «Заманыбызның язмышын хәл итәрдәй вакыйгаларда катнашуыгыз белән горурланачаксыз әле», – дип күңелне күтәреп җибәрә торган иде. Шулай килеп чыкты да...

PRESSA.RU



# КАЗАН. ЧЕМПИОНАТ. ДРАЙВ!!!



Эльмира
ЗАКИРОВА


## КАЗАН – СУ СПОРТЫ ТӨРЛӘРЕНЕҢ XVI ДӨНЬЯ ЧЕМПИОНАТЫ БАШКАЛАСЫ!















Күнелем белән шәһәребез кунаклары халәтендә калып карыйм. Самолет Казан җиренә төшеп килгәндә үк үзләрен яшел болын-кырлардан сәламләүче Итил исемле барс малае һәм Алсу исемле барс кызы, шәп кәеф бүләк итеп, елмайткандыр аларны. Аэропортта ук чәкчәк белән каршылап, шәһәребез кунакчыллыгын сиздергәндер. Матур юллар, күперләр, һәр тарафта – чәчәкләр... Казанның зәңгәр күзләре булып, кайдадыр яктырып ачылып киткән, юл уңаенда җылы карашын сирпеп калган, ерактан бер күренеп, бер югалып качышлы уйнап барган Идел, Казансу, Болак сулары, Кабан күлләре...

Кызыл футболкалы волонтерлар шәһәргә, чемпионатка кагылышлы теләсә нинди сорауга җавап бирергә әзер. Һәр төр ярышка аерым урыннар билгеләнгән: «Казан-Арена» стадионында йөзү һәм синхрон йөзү, Казансу елгасында ачык суда йөзү, хай-дайвинг, Су спорты төрләре сарае бассейнында суга сикерү, Су полосы аренасындагы ярышлар...

Күпләр синхрон йөзү ярышларын тамаша кылырга барган. Шулай булмыйни! Музыка ритмында суда төрле фигуралар ясый торган спорт төре булсын да! Икенче төрле аны «су балеты», «фигуралы йөзү», «нәфис йөзү» дип, ә синхрончыларның үзләрен «су кызлары» дип йөртәләр. Җитәкләшеп йөзүләр тынлы оркестр музыкасына башкарыла. Карап торуга җиңел күренсә дә, синхрон йөзү спортчы кызлардан күпне таләп итә: түземлелек, сыгылмалылык, нәфислек... Россия җыелма командасы баш тренеры Татьяна Покровская: «Чып-чын каторга бу! Көненә әллә ничә сәгать суда баштүбән тор әле!» – дип тикмәгә әйтмәгәндер инде. Тренировкалар көн саен унар сәгатькә сузыла. Матур костюмнар, махсус макияж – анысы инде башка тема. Синхрончыларның күз явын алырлык костюмын дизайнерлар иҗат итә. Аларның су костюмы балерина костюмыннан, примадонна киеменнән һич ким түгел! Россия һәм Европа чемпионы Лилия Низамова ул матурлыкның серен ача: «Су коену костюмы музыка уйнап торганда тегелә. Башта махсус рәсем сайлана, тегүче музыка тыңлап, костюмга шуны «төшерә», төрле ташлар белән бизи. Синхрончылар костюмына, мәсәлән, Сваровски ташлары чигелгән. Костюм күз явын алырлык булып ялтырап торырга, биектән сикергәндә елкылдап, матур күренеш барлыкка китерергә тиеш». Синхрончылар, гадәттә, өч төрле музыкага чыгыш ясый. Музыка чыгышка карап сайлана – классикадан башлап хеви-металл төренә кадәр. Эретелгән желатин ярдәмендә ясалган прическаларына исә су астында да берни булмый икән! Йөзү программасын башкарып чыгуга – биш минут, ә макияж салуга сәгатькә якын вакыт кирәк, диләр.

«Пилигрим» шоуны, әйдә, әкият-сәяхәт дип атыйк. Игорь Крутой командасы бу юлы да безне таң калдырырга, позитив энергиягә, хыял очышына, төсләр, яктылык балкышына күмәргә уйлаган. Күр, күпме илләр, шәһәрләр катнашкан бәйрәмдә! 10 мең кешелек зал әләмнәрне сәламли, спортчыларны алкышлый! Әйтерсең, Җир шары, бөтен дөнья сыйган «Татнефть-Арена»га! Артистлар, спортчылар белән бергә тамашачы да төп герой Пилигримга ияреп, әле океан төпләренә төшә, әле диңгез дулкыннарында чайкала. Хәтта волонтерлар да тельняшкалардан. Спектакльгә тирән фәлсәфи мәгънә салынган. Су – яшәү символы, зирәклек чыганагы. Боз мәйданы зу-ур бассейнга әверелгән. Синхрон йөзү осталары – суда, цирк гимнастлары – һавада, балет артистлары сәхнәдә могҗизалар күрсәтә. Чын тамаша башлана. Тамашачылар, ялгыз сәях җаннар булып, озын юлга кузгала. Ул юл Кабан күле турындагы риваятьләргә алып кереп китә, Казан ханы Ядегәр хәзинәләре яшерелгән күл төпләренә алып төшә. Көтелмәгән бәла-казалар сәяхәтчеләрне төрле яклап сыный, кешеләр каршылыкларны җиңәргә өйрәнәләр, сунын тормыш чыганагы



Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Рөстәм Миңнеханов Казан шәһәрендә су спорты төрләре буенча 2015 елгы XVI Дөнья чемпионаты һәм «Мастерс» категориясендә су спорты төрләре буенча XVI Дөнья чемпионаты ачылу уңаеннан Татарстан халкына мөрәҗәгать белән чыкты. Әлеге Чемпионатның спорт өлкәсендә 2015 елда иң әһәмиятле дөньякүләм чараларның берсе булуын билгеләп, «Бу көннәрдә без Россия спортчыларыннан һәм Россия җыелма командасы составындагы якташларыбыздан зур җиңүләр, спортта югары күрсәткечләргә ирешүләрен көтәбез», – диде ул.

Кызларыбыз да горурланырлык шул! Халыкара ярышларда җиңүләр яулыйлар. Олимпия, Дөнья, Европа чемпионнары булган спортчыларыбыз да байтак. Анастасия Давыдова, Анастасия Ермакова, Ольга Брусникина, Мария Киселева, Наталья Ищенко, Светлана Ромашкина, Эльвира Хәсәнова, Яна Мартынова – дөньякүләм легендалар. Әнә, Наталья Ищенко 19 нчы тапкыр Дөнья чемпионы булган, «алтын» яулаган!

Илнең баш тренеры Татьяна Покровская Татарстаныбызга, аның җитәкчеләренә, халкына менә нинди бәя бирде: «Искиткеч шәп шәһәр, ягымлы кешеләр, безгә карата шулкадәр җылы мөнәсәбәт!.. Кунакка чакыралар. Безнең командага аерым игътибар күрсәтәләр. Без андыйга күнеккәнмени?

Казан – чын мәгънәсендә спорт шәһәре! Трибуналарда – халык! Без бик шат!»

Россия Федерациясе Олимпия Комитеты башлыгы Александр Жуков исә: «Казан берничә мөһим ярышларны кабул итте инде, бу шәһәр Олимпия уеннарын да үткәрә алыр иде», – дип билгеләде.

PRESSA.RU



икәненә төшенәләр. Кабан күле төбенә яшерелгән хәзинәләр аша суның сер саклау үзлеге дә, кешеләрнең табигатькә каршы кылган хаталарын искә төшертеп, куе томан булып шомга салуы да – һәммәсе аерым вакыйга итеп күрсәтелә. Җиде эпизодның һәркайсы тамашачыны су стихиясенә, диңгез төбе матурлыкларына күмә. Тамашада кызыл җеп булып сузылган фикер: иң мөһиме – үзеңне югалтма!

«Татнефть-Арена»ның Президент ложасында Россия Президенты Владимир Путин булу тантанага, әлбәттә, аерым статус бирә!

«Илебез мондый турнирны беренче мәртәбә кабул итә, һәм без аны иң югары дәрәҗәдә үткәрү максатын куябыз! Турнирны әзерләүдә катнашучыларның барысына да рәхмәтлемен! Татарстан Республикасы җитәкчелеге керткән өлешне аерым билгеләп үтәм! Казанда спортны үстерүгә игътибар бирәләр. Дөнья беренчелеге уңышлы үтсен өчен уртак тырышлык белән барысы да эшләнде. Спортчылар үз осталыкларын тулысынча күрсәтер, ә тамашачылар, җанатарлар зур спорт бәйрәмендә катнашучылар булып китәр дип ышанам. Россиягә килүчеләр безнең халыкның кунакчыллыгын, киң күңеллелеген тойсын иде», – диде Владимир Путин үзенең котлау чыгышында. Турнирга әнә шулай старт бирелә!

...Казаныбызга әле кунаклар, әле спортчылар күзе белән карап, соңгы арада телдән дә төшмәгән урыннардан узам. Кремль, Казансу яр буе, FINA паркы, Бауман урамы, сувенирлар сата торган кибетләр, мәчетләр... Ә салют искиткеч иде! Ул балкыш! Ул төсләр! Ленин, Киров дамбаларыннан караганда бөтенләй әкияттәге сыман күренә! Ышанасызмы, бу көннәрдә бөтенесе Казанга гашыйк иде! Казан бөтен кыйтгаларны, халыкларны якынайтты, берләштерде. Медальләр иң көчлеләргә, иң лаеклыларга эләкте. Рәхмәт сиңа, спорт! Чемпионат көннәре елның иң якты бизәге, халыкара вакыйгасы булып күңелләргә кереп калсын!

**Чемпионатның бер кыйпылчыгы, нәни бер «тамчысы» булуым белән чиксез бәхетлемен!!!**



# КАЗАНСУДА – КЫЗЫЛ ҖИЛКӘН

Ул үзен «ВКонтакте»-да «сихерче» дип язып куйган әнә. Серен болай аңлата: «Сихерче ул мистик образ. Тормышымда чынлап та шундый хәлләр булгалап тора: бер нәрсә турында уйлап кына куясың – нәкъ шулай килеп тә чыга! Мәсәлән, «Рубин» матчында миңа өч тапкыр Татарстан гимнын җырларга туры килде – өчесендә дә «Рубин» җиңде! «Голос» проектында да конкурстан узуны бик нык теләп йокларга яттым. Төшемдә коридор буйлап үтүемне, сәхнәгә чыгуымны, софитлар яктыртуын һәм... миңа бер кресло борылуын күрдем. Өндә дә шулай булды! Уйлар материальләшә...»

Татарстан Республикасының атказанган артисты, Беренче каналдагы «Голос» проекты финалисты, Универсиада-2013 һәм Су спорты төрләренең Дөнья чемпионаты-2015 илчесе... Болар бар да Эльмира Кәлимуллина турында. Без аны актив спортчы, шахматчы, музыкаль спектакльдә уйнаучы актриса (Константин Хабенский куйган «Поколение Маугли»да Багира роле!), чемпионат дәресләрен алып баручы укытучы, автоледи, дизайнер-модельер итеп тә кабул итәбез хәзер. Түбән Камада мәктәптә укыган елларында рәсем ясарга яратканын, юридик лицейда укыганда милиция формасыннан йөргәнен, абыйсы Илдардан каратэ алымнарын өйрәнгәнен, көрәшнең сугышчан алымнарын куллана белгәнен, криминалистиканы шәп үзләштергәнен искә төшерсәк... Кызык кыз бу Эльмира! Китаплар укырга, кинолар карарга, велосипедта йөрергә ярата, парашюттан сикерергә хыяллана... «Тагын кайсы якларыңны күрми калдык икән?» – дигән соравыма ул: «Мин әле биергә дә яратам. «Йолдызлар белән бию» тамашасында катнаша алсам – бик бәхетле булыр идем!» – дип җавап бирәчәк соңрак.




Кемнәрдер аны Одри Хепбернга охшата, ә үзенә Шадэ, Кармен образына керү ошый. «Рубин» җанатарлары аны матчларда безнең гимнны шәп итеп башкарганы өчен ярата. Үзе дә «Рубин» фанаты – матчларда Эльмираны һәрвакыт Көнбатыш трибунаның 6 нчы секторында күрәләр.

Инстаграмга фотолар элэргә, Фейсбукта күп өндәүләр куеп язарга, һәр вакыйгага ихлас мөнәсәбәтен белдерергә ярата. Әйдә, Твиттердагы соңгы язмаларына күз йөгертик.

«Иҗатымның башлангыч чорында сәхнәгә чыгарга курка идем:) Куркуны адреналинга әйләндереп, ләззәт алам хәзер!!!»

«Мәскәүдә чиләкләп яңгыр коя, диләр! Ә безнең Казанда – кояш!!!»

«Көнем чәчәкле иртәдән башланды!!! ГУМдагы чәчәкләр фестивале көн буена җитәрлек кәеф бүләк итте!!!»

«Шахматта «цугцванг» – бернинди дә хәрәкәт ясамау – иң файдалы йөреш икән...»

«Футбол дип үлеп китәм! «Рубин»–«Барселона» матчында тамак карлыкканчы кычкырып, яраткан командама көч биреп утырганым бар! Стадиондагы энергетика һәм эмоцияләр, җанатарлар, яраткан командаң уены – бу инде телевизор каршында утырып кына карау түгел!»

«Ура!!! «Рубин» – чемпион!!!»

«Менә хәзер, шушы минутларда Россия 1 телеканалында Су спорты төрләре буенча чемпионатның Ачылу тантанасы туры эфирда күрсәтелә!!!»

«Искиткеч булды!!! Дөньякүләм дәрәҗәдәге шоу өчен режиссер Сечековка һәм аның командасына рәхмәт!!! Костюмерларга, гримерларга! Музыкантларга аерым рәхмәт! ТР хөкүмәтенә, шәһәр хакимиятенә! Безнең Президент Рөстәм Миңнехановка! Һәм, әлбәттә, Чемпионатны Казанда үткәрүгә ышаныч белдергән РФ Президенты Владимир Путинга!»

«Музыка, тамаша үзе мине әйтеп аңлаталмаслык эмоцияләр белән баетты! Су, тормыш музыкасына искиткеч сәяхәт булды ул!»

«Мин дөньякүләм вакыйганың бер кыйпылчыгы булдым!!! Бөтен дөнья миңа төбәлгән!!!»

Хәзер инде үзе белән иркенләп сөйләшсәк тә ярыйдыр.

– Су спорты төрләре буенча Дөнья чемпионаты илчесе булуың турында сөйлә әле, Эльмира.

– Универсиада тәмамланып, бер ай да узмады, Испаниядә, Барселона шәһәрендә Су спорты төрләре чемпионаты башланды. Эстафетаны Казан кабул итәргә тиеш иде. Барселонада Чемпионатны ябу һәм Чемпионат әләмен Казанга тапшыру тантанасында мин дә катнаштым. Чемпионат илчесе буларак максатым – Дөнья чемпионатын, су спорты төрләрен, Казаныбызны популярлаштыру булды. Күптөрле чаралар, концертлар, очрашулар... Спорт проектлары дирекциясе белән мәктәпләрдә балалар өчен дәресләр үткәрдек. Миңа укытучы ролен башкару да бик ошады!

Дөнья чемпионаты бөтен кыйтгалардан иң көчле спортчыларны җыя, аны телевизор аша гына да 4 миллиардка якын кеше карый! Бу яктан Дөнья чемпионаты Универсиададан күпкә дәрәҗәлерәк.

– Синең хакта: «Дөнья чемпионаты символын – космостан әйләнеп кайткан «тере су»ны саклаучы» дип тә әйтәләр...

– Чемпионатка әзерлек чорында Казансу елгасы суы капсулада космоска, халыкара космос станциясенә җибәрелде. 169 көн узганнан соң ул, космос энергиясен үзенә алып, кире Җиргә әйләнеп кайтты. Космонавтлар шәһәре «Звездный»да экипаж аны миңа тапшырды. Капсуланы Казанга алып кайтканда бу тылсымлы су безнең спортчыларга уңышлар китерсен, аларга космик тизлек бирсен иде дип теләдем.

– «Пилигрим» тамашасында син башкарган җыр тәэсирендә зал эйфория кичерде. Тавышың, җырның сүзләре, мәгънәсе, үзең, килешле кызыл күлмәгең – аны җилкәнгә тыңләделәр хәтта!

– Җырның сүзләре дә, моң да

*Кеше башка берәүдән түгел, кичәге «мин»еннән яхшырак булсын.*

минем халәтемә бик тә туры килә! Томан тарала, айлы төн, меңләгән йолдызлар кабынган, гашыйклар биюе... Романтика!

– Спортның кайсы төре синеке? Ә су спорты төрләренең кайсын сайлар идең?

– Нәфис гимнастика матурлыгы белән әсир итә. Су спорты төрләреннән синхрон йөзүне һәм суга сикерүне карарга яратам. Ләкин профессиональ рәвештә шөгыльләнер өчен күп көч һәм вакыт кирәк.

– Тормыш шигарең нинди?

– Алар минем икәү: «Хыяллар тормышка аша!», «Үз көчеңә ышанырга кирәк!»

– Син үзең үк җиңү символы бугай, Эльмира... Теләк-хыялларың материальләшә бара. Россия җыелма командасы җиңсен өчен ничек җан атасың?

– Чыгышларын карап, җанымтәнем белән аларга җиңү теләп утырам. Аларның иң яхшылар икәненә чын күңелдән ышанам.

– Синең аерым бер җиңү «рецептың» бармы?

– Үз-үзеңә ышанырга, үзлегеңнән үсәргә кирәк. Бүгенге Эльмира кичәге Эльмирадан бер карышка гына булса да яхшырак булырга тиеш. Шундый диалектика булса, уңыш киләчәк!

Эльмира ЗАКИРОВА


PRESSA.RU












# КАЗАН БАКЧАЛАРЫ



Асия
ЮНЫСОВА

БАКЧАЛАР УТЫРТУ – КЕШЕЛӘРНЕҢ КИЛӘЧӘК БУЫННАР ХАКЫНА КЫЛГАН ИҢ ИГЕЛЕКЛЕ ГАМӘЛЕ. БҮГЕН УТЫРТКАН АГАЧЛАР УРМАН БУЛГАНЧЫ АДӘМ БАЛАСЫНЫҢ ГОМЕРЕ ИНДЕ УЗГАН БУЛА.

Татар халкының гомере урман белән. Бу бергәлек бик борынгы заманнардан ук килә. Әле безнең халык Идел буена килеп урнашканчы ук тайга урманнарына «урман» дигән икенче атаманы кушып калдырган. Анда хәзер яшәүчеләр калын, кара ылыслы урманны шулай дип йөртәләр. Урманнарына сыенып исән калган халык урманны сердәше, иптәше, моңдашы, көрәштәше, сакчысы дип санаган. Әле менә урманчылар турында язу нияте белән йөргәндә дә күңелемнән шагыйрь Харрас Әюповның шигырь юллары китми: «Агач башлары шаулыйдыр җилдәнме, давылданмы...», «Көз түгел, урман өсләтеп гомерләр узып бара...» Урманнары сирәгәя башлагач, кешеләр, бигрәк тә гамьле җаннар, уйлы җаннар, каенга кайгысын сөйләгән, миләшкә сарылган, имәнгә сөялгән, усак белән бергә уйчанланган, зелпеләргә, зирекләргә сокланган, зифалыкны наратка тиңләгән. Кеше дигәнең урманга рухи азык кына түгел, тамак ягын кайгыртып та барган. Белгән ул Урман дустының аны буш итмәсен, нәүмиз калдырмасын. Чикләвекләр сыйлаган аны, юкәләр киендергән... Ә агачлар – карамалар, өянкеләр ничәмә-ничә гашыйкның серен үзенә алган! Ничәмә-ничә шигырьгә, җырга илһам биргән алар! Барыбызны да озатып калган да, каршы алган да алар! Чыннан да, паралелль яшибез икән лә без, мәңге янәшә икән.

Шушы арада Казанның Урицкий исемендәге бакчасында үсеп утырган 300 яшьлек талны кискәннәр дигән хәбәр шәһәр кешеләрен сискәндереп куйды. Кемгә тигән, кемне рәнҗеткән соң өч гасырны имин кичкән, Санкт-Петербург каласының яшьтәше булган бу өянке? Таллар, өянкеләр татар җанын аңлый торган агачлар алар. Үземнең дә балачагым, әнием итәгендә утырган кебек, өянке кунач асында узды. Барыбыз да сыя идек аның куенына.

Петербург телгә килгәч, инде Россия флотын Казан яны, Алабуга тирәсе урманнары күтәргәнен дә искә төшерик. Бишбалта – кораблар төзүчеләр бистәсе дә бездә һәм Питерда гына бар. Ә менә урман тарткан кешеләрнең авыр хезмәтенә атап чыгарылган «Лашман бәете» фәкать бездә генә!

Агач утырту мөнәсәбәте илә башланган сүзем менә кайларга алып чыкты. Югыйсә хикәятем гел дә гел ямьле булырга тиеш иде. Чөнки 2015 ел Татарстанда «Бакчалар һәм парклар елы» дип игълан ителде. Бу гаҗәеп дөрес һәм игелекле гамәлнең башы, минемчә, 2005 елга барып тоташа. Дөрес, нурлы Казаныбыз матур-матур бакчалары белән элек тә мактана алган. Фукс бакчасы, Эрмитаж бакчасы, Черек күл паркы, Горький исемендәге үзәк ял паркы инде зур тарихлы, истәлекләргә төренгән бакчалар рәтендә. Тик менә яңа дәвергә башкалабыз – зурайган, киңәйгән Казан һаман да борынгы бакчалары белән генә керергә тиеш түгел иде бит инде.

2005 елны хәтерлим. Биш ярым гектарлы җирдә «Миллениум» паркы, ягъни Казанның 1000 еллыгына багышланган бакча утыртыласы билгеле булды. 26 август көне иде. Тантана уңаеннан Россия Дәүләт Советының Казанда узачак утырышына бөтен илдән килгән төбәк башлыклары үзәк аллея буйлап зәңгәр чыршылар утырттылар. Биробиджаннан килгән җитәкче белән икәү утырткан идек тавышка чыдам талымсыз бер зәңгәр чыршыны. Димәк, Казан каласы узган мең еллык юлның символы булган ул аллеяда бездән дә бер агач калды. Сиксән яшьләренә ул чыршы егет булып җитешер. Бу парктагы каеннар, юкәләр, каштаннар, миләшләр аңа көнләшеп карарлар. Көнләшмәслекмени! Яфраклы агачлар инде ак яулыклы әбиләр булып килгәндә ул һаман яшь ләбаса.

*Урман белән иңгә-иң яшәү, язмышыңны аңа тиңләп, үлчәп карау бер бездә генә. «Кара урман» җыры белән дәверләрне кичкән халык ла без.*

Менә тагын Казан яңа бакчалар утыртып куана. Шәһәрдә 25 парк һәм скверны яшәртү, яңарту өчен республика бюджетыннан түгәрәк санлы сумма бүленде. Ниятләр зурдан. «Истанбул паркы» кебек иркен һавалы яңа бакчалар белән беррәттән «Ак чәчәкләр» дигән паркның да ял итүчеләр иңнәренә язын алмагач чәчәкләре, көзен өрәңге яфраклары кояр көннәре ерак түгел. Бу шатлыклы көннәрне якынайту өчен шәһәр халкы үзе дә өмәләре белән ярдәмләшә бит. Бакчасы булган урында сулыгы да кирәк. Кабан күлендә су трамвайлары, җилкәнле көймәләр йөзә (Кабан күлен төзекләндерү өчен 25 миллион сумга якын акча каралган дип беләм) башлагач, дүрт катер ары-бире йөреп торган Казансу елгасы буйлап матур аллеялар сузылгач, тагын бер сөенербез әле.

Безнең халык шулай бит ул – бер сөенечен ике итәргә, биш итәргә ярата. Казакъ туганнарыбыз башкалаларын Алматыдан Астанага – япан кырга күчереп салгач, иң беренчеләрдән булып безнең урманчыларыбыз барып җитте. Бер дә бардылар, ике дә... Яңа башкала гүзәл калага әйләнсен өчен күпме бәхәсләр куерды анда. Кайсы агачның бу табигатькә ярашасын, тамыр җибәрәсен, киләчәк буыннарга хезмәт итәсен тәгаен белгән кеше – Россиянең атказанган урманчысы, фән докторы Харис Мусин кебек белгечләр сүзе барыбер өстен чыкты. Вагон-вагон килгән яшь үсентеләр ят туфракта ныгып китә алды. Чөнки аларны Татарстан туфрагыннан аермыйча, махсус савытларга утыртып илттеләр. Озын гомерле булырга тиешле зәңгәр чыршылар Астана табигатен дә яраттылар. Шулай итеп, Казакъстан башкаласы татарларның күңел җылысына төренде.

Астана безнең урманчыларның олы сәясәткә беренче зур өлеше булгандыр. Хәзер инде зәңгәр чыршы-

Фото: Артем Дугин

PRESSA.RU





Министр Алмас Нәзиров белән министр урынбасары Харис Мусин Татарстан урманнарын бергәләп күтәрәләр.

ларның кардәшләре Үзбәкстанда да үсә. Тирән мәгънәле гамәлләр бигрәк тә Наил Мәһдиев урман министры булган заманда киң колач алды. Гамәлләрнең һәркайсы турында зурлап язарлык. Әйтик, салкын җилле бер көндә Волгоград янындагы Мамай курганының иң югары ноктасына татар егетләре менгереп утыртып куйган зәңгәр чыршы шул туфракта ятып калган татар ир-егетләренә тагын бер һәйкәл булып басты.

*Сталинград өчен сугыш барган урыннарда да бакча-урман калдырды безнекеләр.*

Әстерхан каласында куелган бөек Тукаебыз һәйкәле дә хәзер кардәшләр җылысын – туган ягыннан аны җилләрдән ышыкларга дип килгән агачлар яклавын тоеп басып тора. «Эх, Җаек шәһәрендә Тукай яшәгән бина янына да агачлар утыртып кайтырга иде бит әле. Ул йорт тирәли алабута, әрекмән куерган. Тукай исемен ташландык итәргә хакыбыз юк. Без бу изге бурычны кемгәдер ышанып тапшыра да алмыйбыз. Хәзерге министрыбыз Алмас Нәзиров үзе дә Тукай якташы лабаса. Сизгер күңелле кеше», – дип, борчуынмы, ниятенме әйтеп салды Урман министры урынбасары Харис Мусин. Димәк, бу эш тиздән башкарылыр.

Ничек кенә өлгерерләр икән дип уйлыйм. Әле бер ел элек кенә Кырымга барып, Бакчасарайда «Казан бакчасы» утыртып кайтканнар иде. Ул бит бардың да кайттың гына түгел. Бакча буласы урынны һәр җәһәттән – урынын, суын, туфрагын, бәреп искән җилләрен чамаларга кирәк. Аннары гына теге махсус савытларга хәстәрләп утыртылган үсентеләр озын юлга кузгала. Бер ел эчендә Татарстан ярдәме белән Бакчасарай төбәгендәге 13 авылга су китерелде. Кайда су – анда бакча. Меңләгән агач үсентесе кирәк иде. Казан шәһәр яны урманчылыгыннан төрле токымдагы 17240 төп агач үсентесе китте. Урманчылар үзләре барып, аларны хасиятләп утыртып та кайттылар. Шулай итеп, Кырым ярымутравында илләреннән нахакка куылган гөнаһсызлар истәлегенә һәйкәл-бакча пәйда булды. Бу да сәясәт. Тынычлык, дуслык, татулык урнаштыруга юнәлтелгән сәясәт! Татарстан олы сәясәткә шул рәвешле – бакчалары белән керә.

Һәр уңай эшне үзеңдә сынап карау алдатмый ул. Әйтик, 2010 елның көзендә Татарстан урман министрлыгы «Бердәм агач утырту көне» игълан итеп, бөтен халыкны изге гамәлгә чакыргач, бу матур башлангыч «агачы» тамыр җибәрә алыр микән дип икеләнүчеләр дә булгандыр. Китте! Хәзер Президентлар да көрәк тотып чыга. Бу хәрәкәт Рәсәйкүләм колач алды. Илләр, халыклар белән аралашканда әллә нинди матур фикерләр туа ул. Әле менә сентябрь аенде Харис әфәнде Көньяк Африка Республикасына Халыкара конгресска җыена икән. Аңа ияреп Татарстанга папайялар, агавалар кайтмас димә! Узган гасырның 60 нчы елларында нигез салынган уникаль питомникта булыр инде аларның урыны. Ул питомник болай да оҗмах бакчасы мисалында. Анда экзотик агачлар гына түгел, тирәкләрнең дистәләгән, талларның йөзләгән төре үсә. Ә сиреньнәр соң! Япон розалары соң! Баланнар соң! Безнеке кебек тә, түгел дә... Бу гаҗәеп урынның Казан янында гына икәнен дә әйтсәмме! Әйе, әйе, Матюшинода гына ул. Казан шәһәр яны урман хуҗалыгына караган питомник бу.

Мин агач төрләрен санаган арада 54 гектарлы питомникның хуҗасы Ленар Касыймов икенче төрле исәп-хисап кора. «Йөз топольдән тагын ун меңне утыртам мин». Бу җөмләне аңларга кирәк. Яхшы кызлар үстергән йортка яучылар өзелмәгән кебек, Питомникка да эзне суытмыйлар. Барысына да сыналган, әйбәт токымлы үсентеләр кирәк. Үсенте хәстәрләү эше исә ел буена дәвам итә торган мәшәкать икән. «Җиткерер хәл юк, – ди Ленар. – Хәзер бит, әнә, янында бакчасы утыртылмаган булса, балалар бакчаларын комиссия кабул итми икән. Гозерләнеп безгә киләләр. «Скверлар елы...» программасын да бер яклы гына аңлаучылар бар. Ул бит әле җиргә плитә түшәдең дә, фонтан җибәрдең генә түгел. Бакча бакча булсын, рәхәт, җиләс урынга әйләнсен, анда кошлар сайрасын өчен аның саф күләгә бирерлек агачлары булу шарт. Ә менә бакчаларга бүленгән акча күбрәк фонтаннарга кереп бетә. Шуннан соң бездән хәйрия өмет итәләр. Имеш, агач үзе дә үсә бит инде ул, бушка гына төяп җибәрегез сәнә!»

Бушның кадере юк. Аннары тияре куелган хезмәтеңә бәрабәр булырга тиештер инде ул. Ә хезмәт дигәне... «Болайрак ул, – инде Шәһәр яны урман хуҗалыгы башлыгы Фарил Галиәхмәтов үзе ачыклык кертәсе итә. – Агачларның орлыгын көздән җыябыз. Әйтик, нарат күркәләрен кагып, орлык туплана. Аны кышын кырык көн карда чыныктырабыз.

Төрле капларга салынган орлык февраль аенда кар көрте белән күмелә. Тычканнан саклыйбыз. Кар астыннан чыккач, үстерә торган махсус стимулятор салынган суда унике сәгать чылатабыз. Аннары янәдән киптерәбез. Чәчкеч белән чәчәбез...»

Нарат, чыршы чәчелгән ул түтәлләр кишер түтәлләре кебек икән. Ылыслылар 0,7 гектарда чәчелә. Каштан, миләш, камырлык (дүләнә), сәрби, барбарис, гөлҗимеш кебек яфраклы куаклар тагын 0,5 гектарда утыртыла. 600 данә юкә, йөз данә каен (төп димим, боларга төп булырга бик озак әле) үсеп утыра инде. Ә менә питомникны яшәтү өчен бик күп агачны бөредән, чыбыктан үрчетергә кирәк. Кыш буе нибарысы дүрт кеше чыбыкларны ишәйтү, тернәкләндерү белән мәшгуль. Йөздән артык товарлыклы агач үсентесе исемлегендә иң күп өлешне, әлбәттә, ылыслылар алып тора. Әнә 15 мең карагай кәлшәсе, 15 мең нарат, 15 мең чыршы кәлшәсе, «балалар бакчасыннан» «мәктәпкә» – зуррак үсентеләр түтәленә күчерелгән инде.

Аларның буй җиткергәнен көтеп торучылар байтак. Читкә китә торганнарының буе өч метрга җитәргә тиеш икән. Ә моның өчен 15 ел үсәргә кирәк! Менә шундый арифметика. «Казан бакчалары» менә шушылай ясала. Урман үстерүчеләр сабыр да, бик тырыш та булырга тиеш икән ләбаса. Һәм бик саф күңелле дә...

Урман тирәсендә очраклы кешеләргә урын юк бугай. Һәрхәлдә, кем белән генә сөйләшсәм дә, бу кешенең юлы – туры «урман юлы» булып чыкты. Мин белгәндә өченче кеше министр вазыйфасында. Алар барысы да югары махсус белемле, урман сәнәгатенең этапларын фидакарь үткән, урманчыдан дәүләт эшлеклесенә кадәр күтәрелгән кешеләр. Әйтик, минем өчен яңа урманчы Фарил Фоат улының тормыш юлын гына барлыйк. Озын түгел әле ул, әмма тайпылышсыз. Кукмара районының Тырыш авылы егете бер генә ел заводта эшләп карый да гөмбәләре, чикләвекләре, утыны, печәне белән балачактан таныш урман сукмагына төшә. Йошкар-Ола техник университетында укып, урман инженеры дипломына ия булуга, «Кама» урман хуҗалыгына килә. Урман караучы, урман белгече вазыйфаларыннан хезмәт юлын башлаган егет хәзер инде, әнә, Шәһәр яны урманчылыгының директоры. Шәһәребезне төреп алган урманнарда янгыннар чыкмауга сөенеп, ял итүчеләрнең урманнарны чүпләвенә көенеп, көннең генә түгел, фасылларның узганын сизмичә яши. Аның сүзләрен лозунг итеп эләрлек: «Урманда тәртип кирәк!»

«Тәртип кирәк»кә балачактан күнектерү өчендер инде Шәһәр яны урман хуҗалыгы каршында «Мәктәп урманчылыгы» оештырып җибәргәннәр. Аның җитәкчесе кара күзле Ләйсән Хәйруллина. «Төрле ярышлар уздыра-уздыра урманны танырга өйрәтәбез», – ди чибәркәй.

Тырышлык бушка китми. Әле кайчан гына урманнар кими дип көенә идек, хәзер республикабызның яшел юрганы киңәя барганга сөенәбез.



PRESSA.RU



– Мин яңа көн тууын бик яратам, – ди ул. – Бүгенге көнгә планнарыңны барлауга кадәр рәхәт: кемне күрергә, нәрсәгә өлгерергә... Гомумән, бөтен нәрсәнең башланганын яратам. Хәрәкәтне! Тизлекне! Күңеле белән гел шулай алга, яңа иртәләргә, яңа үрләргә ашыкса, ашкынса да: «Үткәннәргә борылып карап әледән-әле нәтиҗә ясый торган гадәтем бар, – ди. – Моны һичшиксез эшләргә кирәк: бәлки, нәрсәнедер оныткандыбыздыр, хата ясагандыбыздыр, бәлки, уйламыйча әйтеп, кемнеңдер хәтерен калдыргандыбыздыр...» Беренче карашка ул бик йомшак, нечкә күңелле булып күренә, әмма аның белән иңгә-иң куеп эшләүчеләр белә: бу ханымдагы ныклык күпләрне сокландырырлык! Сүзем – Әлмәт шәһәре һәм районы башлыгы урынбасары, Әлмәт муниципаль районы Советы рәисе урынбасары Нәҗия Мисбах кызы ХӘЙДӘРОВА турында.



Гөлнур САФИУЛЛИНА

# ТОРМЫШ ЯЗГАН КАГЫЙДӘЛӘР

### «Мин булдырырга тиеш!»

Нәдер урта мәктәбен ул алтын медальгә тәмамлый. Документларын Казан дәүләт университетының тарих факультетына тапшыра. Укытучыларының: «Безнең Нәҗия мәктәпкә кире кайтырга тиеш инде ул», – дип гел әйтеп торулары эзсез узмый... 472 нче группага – бөтен Россиядән җыелган медалистлардан гына торган эксперименталь төркемгә эләгә. Ул да «алтын»лы, әмма татар мәктәбен тәмамлап килгән авыл кызы... Ничекләр итеп булган белемеңне аудитория алдында күрсәтеп бирергә, ничек үз-үзеңне җиңәргә?

*«Башкалар булдырганны нигә мин булдырмаска тиеш?!»* Гомер буе аны озатып барачак, максатларына ирешергә ярдәм итәчәк бу таләп-кагыйдәне үзенә-үзе шул чагында куя ул. («Мин һәрвакыт үземнең сәләтемә караганда билгеле бер баскычка югарырак күтәрелүне максат итеп яшәдем. Гомумән, кешенең теләкләре һәрчак зурдан, ә максатлары күп булырга тиеш».) Китапханәнең уку залыннан ял көннәрендә дә китеп тормаучы студентларның берсенә әйләнә. Группадашлары да ярдәмгә килә: әйе, алар барысы да көчле, белемле, әмма семинарларда: «Әзерләндең бит, кулыңны күтәр!» – дип,

терсәк белән аңа төртәләр. Тел дигән киртә шулай җиңелә.

Әлмәт районының Кәләй авылына алар – ике яшь белгеч – 1984 елны кайталар. Кулларында – яшь тә сигез айлык кызлары Алсу. Нәҗияне бик куанып мәктәпкә эшкә алалар, тарих дәресләре бирәләр. Рус мәктәбенә! 145 нче Кәләй урта мәктәбе Куйбышев тимер юл челтәренә карый. Мәктәпнең абруе зур, укытучылары көчле, укучылар саны күп.

– Халык бик җылы каршы алды безне. Иртән торып чыксаң, баскычка кемдер йә гладиолус, йә кашкарыйлар куеп киткән була иде. Ай ярым эшләүгә кызым авырып китте. Шул вакыт бер төркем укучылар килеп керде. Кайсы утын кертә (и-и, чи утын белән тилмерә идем инде!), кайсы мичкә яга, кемдер суга китте, чәй куеп җибәрде... Мин Кәләйдә зур тормыш мәктәбе уздым. «Алар Казанда укып кайткан», – дип, халык киңәштабышка йөри башлады: олысы да, кечесе дә. Гел онытмыйм, беркөнне кичке сигездә бер укучым килеп керде. «Үги әтием мине якын итми, ул әнине генә ярата. Мин өйдән китәм. Бүген генә сездә куныйм әле», – ди. Икәү утырып чәйләр эчтек, төнге унбергә кадәр сөйләштек. Аннан... мин аны өенә озатып куйдым. Башка көнне әнисе белән очрашып, җайлап кына сөйләштем... Маша юрист булды, әниләре янына гел кайтып йөри.

Күңелгә язылган кагыйдәләр Кәләйдә тагын бергә арта: *«Кеше хәлен аңлар өчен үзеңне аның урынына куеп кара»*. Классны яңа уку елына әзерлиләр – Нәҗия әтиәниләр белән бергә идән буйый, тәрәзә юа. Укучылары өмәгә чыга – ул эш киеменнән тагын алар арасында. Хөрмәт шулай казаныла. Ул сыйныф җитәкчесе булган класс тугызынчыны тәмамлаган елны, 1 Май бәйрәменә әти-әниләр җыелып килләр дә: «Балалар алга таба монда укыса-укымаса да, класс бүлмәсендә ремонт ясарга телибез. Бу – бездән сезгә бүләк», – дип шаккатыралар. Хезмәтенә бәя кебек тә яңгырый бу сүзләр.

1996 елны Кәләй мәктәбен Әлмәт җирлегенә күчерәләр. Озакламый мәктәпкә фронталь тикшерү килеп төшә. Нәҗиянең кайгылы вакытлары – әнисен җирләгән чагы. Үзен күрсәтү өчен махсус нидер эшләми дә кебек: дәресләре моңарчы ничек үтсә, шулай дәвам итә. Мәгариф идарәсенә чакырып алулары: «Сез безгә ошадыгыз. Методист булып эшләргә теләгегез юкмы?» – дип сораулары шуңа да гел көтелмәгән хәбәр булып яңгырый. «Башкалар булдырганны нигә мин булдырмаска тиеш?!» – дип уйлый да, ризалаша.

– Диләрә Әхмәтова, Илдар Баһманов кебек яшь, кыю, идеяләре ташып торган акыллы җитәкчеләр белән эшләдем. Өч елдан беренче урынбасар итеп куйдылар. XIX гасырда мәгариф системасы иң консерватив, үзгәрешләргә бирешмәгән, фундаменталь белемнәр бирә торган система булган. Безнең өлешкә XX гасырның азагы эләкте. Бу вакытта мәгариф өлкәсе тоташ реформалардан гына торган сыман иде. Үзгәрешләр туксанынчы еллардан соң башланды. Оптимизация дигән яңа термин барлыкка килде. Бала саны шәһәр җирендә сыйныфта – 25, авылда 14 балага тулмаса, андый классларны берләштерү яисә тарату, нормативка туры килмәгән мәктәпләрне кыскарту, ябу мәсьәләләре – без шул чорны, шул дулкынны уздык. Һәм аларның һәрберсе балалар, укытучылар язмышы белән бәйле иде бит!

2007 елдан башлап Нәҗия Хәйдәрова район мәгариф бүлеген җитәкли. Милли мәсьәләләр буенча шактый эшләр башкарыла ул елларда Әлмәттә. Татар мәктәпләрен, татар телле группаларны саклап калалар. Күп районнарда, оптимизация дип, ашыгып-ашыгып башлангыч мәктәпләргә кадәр ябалар. Ә Әлмәттә җитәкчеләр ул юлдан китми – башлангыч мәктәпләрне ябуны алар хәтта көн кадагына да куймыйлар. Авылларның киләчәге турында сүз бара бит: мәктәп бетә икән, авылның да гомере озак калмый. Соңлабрак булса да, бу мәсьәләгә кире кайттылар хәзер: «Һәр җирлектә башлангыч мәктәп булырга тиеш», – диләр. Тик ябуы җиңел, ә ишекләрне кабат ачуы... Нәҗия Мисбах кызының бу яктан күңеле тыныч, барлык атааналар алдында да йөзе ак: Әлмәт районында башлангыч сыйныфта укучыларның берсе дә, күрше авыл мәктәбенә укырга бару өчен салкын автобуска чыгып утырмады.

## *Сынауларны узып, язмышларны җиңгәннәргә сокланам.*

Көчле урынбасарлар туплана – бер команда булып эшлиләр. Мәгарифтән башка тормышны күз алдына китермәгәндә – яңа тәкъдим. Бу юлы да яңалыкка таба икеләнмичә атларга тагын шул: «Мин булдырырга тиеш!» – дию булыша.

Бүгенге вазыйфалары депутатлар корпусы эшен оештыру белән бәйле аның: федераль яки республика дәрәҗәсендә законнарга нинди үзгәреш кертелсә дә, ул урындагы законнарда да көне-сәгате белән чагылыш табарга тиеш. Әйе, монда барысы да җитди: законнар, нормативлар, сессия, комиссияләр, референдум, сайлаулар... Барлыгы 332 мандат аларда. Күбесе – шәһәр һәм районның төрле өлкәләре өчен җаваплы зур-зур җитәкчеләр, нефтьчеләр – эш кешеләре. Алар куйган таләпләр буенча эшләп, күтәргән мәсьәләләрен тирәнтен өйрәнеп, үзеңнең сәләтле икәнеңне эшең белән исбатлый алганда гына сине кабул итә торган шәхесләр. Нәҗия Мисбах кызының җитәкче буларак үз-үзенә куйган беренче таләбе – нинди аудитория алдына чыксаң да, һәрвакыт әзерлекле булу. Аннан – нидер хәл итә алмасаң, тыңлап кына китүдән ни мәгънә?! Депутат мандатына ия булу – халык алдында зур җаваплылык дигән сүз ул. Аңа ышаныч белдергән Баграж-Никольское авылы халкының да моң-зарлары бихисап: кечкенә авыл, халык саны аз, эш юк... Кечкенә генә үзгәрешне дә шуңа зур итеп кабул итәләр. Ярым җимерек бинага урнашкан элемтә бүлеген мәктәпнең бер почмагына ремонт ясап шунда күчерүне дә, фельдшерлык бүлеген төзекләндерү өчен акча бүленеп бирелүне дә, автобус көтү өчен тукталыш урыны ясап куюны да...

PRESSA.RU



– «Үзеңнән өстә торган җитәкченең йөзенә кызыллык китермәскә» – без шулай тәрбияләнгән. Шулай эшлибез. Әлмәт – ул сәләтле кешеләр җирлеге. Безнең җитәкчеләрнең һәрберсенең монда калдырган эзе, шәһәрне үстерүгә керткән үз өлеше бар. Мин бу урында көчле ихтыярлы, таләпчән, тәҗрибәле җитәкче – Мәҗит Хаҗип улы Салихов кулы астында эшли башладым. Остазларыма бик рәхмәтлемен! Бүгенге башлыгыбыз Айрат Ринат улы Хәйруллин да киң карашлы, идеяле, зур мөмкинлекләргә ия шәхес. Без аңа зур өметләр баглыйбыз. Ә бүген мин билгән урында моңа кадәр һәрвакыт хатын-кызлар утырды: Гүзәлия Әхмәдиева, Мәхәббәт Гарифуллина... «Ир-атка бу вазыйфада, мөгаен, җиңелрәк булыр иде», – дип шуңа да уйлаганым юктыр. Куйган бурычлар хәл ителә, максатларга ирешелә. *«Башкаларны хөрмәт иткәндә, халык белән эшләүнең авырлыгы юк аның...»* Күңелгә язылган кагыйдәләрнең соңгысы түгел әле бу.

*Үз хәләтеңнән риза булу – тукталып калу дигән сүз.*

### «Яхшы кешеләр күбрәк!»

– Безнең арттан барыгыз... Ул-бу булса, туктарбыз, шуннан аңларсыз...

Алексеевское–Казан арасы. «Ашыгыч ярдәм» машинасын күңелең, уйларың, ялвару-теләкләрең белән алдан бар көчеңә «тартып», арттан «этеп» барганда, чакрымнар гомер озынлыгы булып тоелу гаҗәп түгелдер. Табиблар утырган машина тизлеген аз гына акрынайтса да, йөрәк аңны җуяр дәрәҗәдә кысыла башлый: «Өлгерсәк иде! Өлгерә генә күрсәк иде...»

Кече кызлары Розаның әтисе һәм апасы белем алган Казан дәүләт финанс һәм икътисад университетын тәмамлап, диплом алу тантанасыннан кайтканда юл фаҗигасенә юлыга алар. Ире һәм ике кызы... Розаны урыныннан кузгатырга ярамый булып чыга, аны Алексеевскоеда калдыралар, ә Алсуны «Ашыгыч ярдәм» Казанга алып китә. Икесенең дә хәле соң чиктә авыр, кызларын чит кулларда ялгыз калдырырга теләмәгән әни кеше исә берәү генә. Йөрәк тә бер...

– Казаннан Роза янына Алексеевскоега кайттым. Хәсрәтле чагым бит инде – тормыш туктаган кебек. Палатага озын буйлы бер егет килеп керде. «Хәйдәрова кирәк миңа», – ди. «Азат Хафизов сезнең укучыгызмы? Без аның белән бергә хезмәт иттек, ул шалтыратты миңа... Шушында, район үзәгендә генә яшим, хәзер сезне үземә алып кайтып китәм, ял итәрсез», – ди. Югалып калдым хәтта, исемен дә хәтерләп калмаганмын... Әллә никадәр көчтәнәч алып килгән. Бер белмәгән, күрмәгән кеше бит! Аннан Розаны Әлмәткә күчердек. Мин кызларымның икесе арасында бәргәләнәм. Казаннан Әлмәткә кайтсам: «Нәҗия апа, сез ял итегез, безнең монда, күрәсезме, график төзелгән», – диләр. Карыйм, исемлектә мин белгән кешеләр түгел... Бөтен Нәдер, Әлмәт безгә ярдәмгә купты ул чак. Гаиләбезне район белән аякка бастырдылар. *«Дөньяда яхшы җаннар күбрәк»,* дигән уй шул чакта тагын да ныгыды. Кешеләргә ничек рәхмәтле булмыйм, аларны ничек яратмыйм, ди, мин?!. Кем белән генә аралашсам да, моңарчы таныш булмаган кешедән дә аның матур якларын, яхшы сыйфатларын эзлим. Һәм табам! Үземнең бу сыйфатым миңа бик ошый. Тормышның кырыс вакытларында, егыла язып калганда, алга атларга ярдәм итә ул. Тормыш барыбер матур, кешеләр барыбер яхшырак!

Әйе, гаиләбез зур сынау кичте ул чакта. Әтиләренә бигрәк тә авыр булды, чөнки руль аның кулында иде. Инсаф үзе турында онытты, сынган кабыргалары турында уйламады да. Безнең телдә-уйда бер генә теләк иде: «Кызлар аякка бассын!» Шөкер, барысы да артта калды! Матур туйлар ясап, кызларыбызны кияүгә бирдек.
Өч оныкка – Айсылу, Салих, Ансарга сөенеп туялмаган көнебез бүген. Сынаулар эзсез генә узмый, тормышка, аның кыйммәтләренә карашны да үзгәртә. Шушы хәлләрдән соң ирем дә, кызларым да намазга басты, хаҗ сәфәре кылдылар. Кияүләр дә биш вакыт намазлы. Без инде ирем белән бер-беребезне сүзсез дә аңлар яшьтә. Өйдә, аның янәшәсендә булган мизгелләр җаныма шуңа аеруча рәхәттер...

### «Мин шигырь яратам...»

*«Кырыслык нечкә күңелле булырга комачауламый»,* – ди ул. Нәҗия Мисбах кызы өчен бу да – кагыйдә. Аның эш кәгазьләре арасында Клара Булатова, Фәнис Яруллин, Энҗе Мөэминованың шигырь китаплары күренеп калса – гаҗәпләнергә кирәкми.

– Шигырь укырга ярату, бәлки, ул тормышка битараф түгелләрнең аерым сыйфатыдыр? Үсештән туктаса, яшәүдән дә туктый кеше. Үз-үзенә, тышкы кыяфәтенә, уйларына, сөйләменә, якыннарына, табигатькә карата битараф булу шикләндерә торган фал. Күзаллавың алтмышта да утыздагы кебек кала икән, бу инде дөрес түгел. Җитәкче кеше, әлбәттә, кырыс булырга тиеш. Эш урыны үз таләпләрен куймый калмый. Ә нечкә күңеллелек... Бу сыйфатның үземә кайдан килгәнен дә беләм. Мин – гади авыл кызы. Без өч бала, мин – төпчеге. Әтием гомер буе шофер булып эшләде, сугыш кичкән кеше. Әни белән яшь аермалары алты яшь иде. Мин кечкенәдән әтинең әнигә булган җылы карашын сизеп үстем. Ярата иде ул аны! Әни дә яраткандыр, әмма әтинеке ныграк сизелә иде шул. Чаңгы шуып кайтып кергәндә әти белән әнинең икәү өйдә өчпочмак пешергәннәрен хәтерлим. Әти бәрәңге әрчи, әни камыр баса... Искиткеч җылы мөнәсәбәтләр! Әни гомер буе исәнлеккә туймады. Без кечкенәдән: «Берүк исән генә булсын!» – дип, аның өчен гел куркып, аны саклап, яратып үстек. 50 яшендә йөрәгенә операция ясаттык. Шуннан соң да әнине 16 ел яшәтә алдык. Аңардан соң әти 4 кенә ел торды, әнинең китүен, юклыгын бик авыр кичерде. Менә болар барысы да күңелне нечкәрткәндер...

Ә кагыйдәләр... Артта еллар күбрәк калган саен, алар күңелгә языла, өстәлә генә бара.

## ҖӘМГЫЯТЬ



**■ Татарстан Республикасы Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Рөстәм Миңнеханов һәм Бөтенроссия дәүләт телерадиокомпаниясе генераль директоры Олег Добродеев ДТРКның яңа студиясе белән танышты. Хәзер республика халкы «Татарстан» ДТРК программаларын югарырак сыйфатта карый ала. Сыйфатлы санлы сигнал тапшыру өчен кирәкле җиһазлар белән тәэмин итү федераль максатчан программа кысаларында тормышка ашырылган. Рөстәм Миңнеханов яңа студияне югары бәяләде, сыйфатлы эшләү өчен бөтен шартлар да булдырылган дип билгеләп үтте.**

**■ Мирный бистәсендәге Каенлыкта Казан Сабан туе узды. Анда 70 меңнән артык кеше катнашты. Хөрмәтле кунаклар арасында Спортның су төрләре буенча Дөнья чемпионатында катнашучылар, Евразия җирле хакимиятләре конгрессы делегатлары бар иде. Мәйданда урнашкан милли утарлар зонасында казанлылар һәм башкала кунаклары республикада яшәүче халыкларның традицияләре, мәдәнияте, көнкүреше белән танышты.**

**■ Халыкара «Казан» ат спорты комплексында «Бүгенге заман хатын-кызының икътисадый, социаль һәм мәдәни активлыгы — Татарстан Республикасы дәүләт сәясәтенең аерылгысыз өлеше» дигән темага ТР эшлекле хатын-кызларының III Форумы эшен башлый. Мәртәбәле кунаклар арасында Татар морзалар мәҗлесенең шура әгъзасы, морза кызы Нәфисә Акчурина да бар. ТР Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Рөстәм Миңнеханов форум эшендә катнашыр дип көтелә. Чараны оештыручылар: «Татарстан эшлекле хатын-кызлары» төбәк иҗтимагый оешмасы, «Татарстан хатын-кызлары» төбәк иҗтимагый оешмасы, «Сөембикә» журналы.**

## МӘГАРИФ

■ Болгарда II Халыкара Кыр археологиясе мәктәбе эшли башлады. Анда Россиянең һәм чит илләрнең иң эре фәнни үзәкләреннән күренекле галимнәр һәм яшь тикшеренүчеләр катнаша. Быел әлеге мәктәп Евразия халыкларының тарихи-мәдәни мирасын өйрәнү һәм саклап калуда дөнья фәнендәге иң яңа казанышларны гамәлгә кертү максатыннан оештырылган. Борынгы металлургия, металл эшкәртү, палеоантропология, трасология, керамика тарихы, археологик пыяла – шушы юнәлешләрдә секцияләр эшли.

## МӘДӘНИЯТ

■ Мәскәүдә Казанның танылган «Тасма» фототөркеме күргәзмәсе эшли башлады. Күргәзмә «Тарих объектив белән язылa. Объектив безгә карый» проектының бер өлеше булып тора. Экспозициядә йөздән артык фотосурәт урнаштырылган.

■ Казанда ТР Милли музееның 120 еллыгына багышланган Халыкара музейлар форумы узачак. Россиянекеләр генә түгел, якын һәм ерак чит ил белгечләренең дә катнашырга теләк белдерүе форумның әһәмияте турында сөйли. Музейларның үсеш перспективалары, регионнар икътисадында музейларның роле, эшкә яңача якын килү алымнары турында зур сөйләшү булачак. Пленар утырышта бүгенге музейлар үсеше өчен әһәмиятле актуаль проблемалар күтәрелəчәк. Форумда катнашучыларны секция утырышлары, түгәрәк өстәлләр, семинарлар, Горький укулары, Болгар дәүләт тарихи-архитектура музей-тыюлыгы, Зөя утравы музееның яңа экспозицияләре, «Яңарыш» республика фонды эшчәнлеге белән танышу кебек кызыклы чаралар көтә.

## КОТЛЫЙБЫЗ



**■ 2014—2015 ел нәтиҗәләре буенча Татарстанда Муса Җәлил исемендәге премия ияләре билгеле булды. Алар арасында — композитор Эльмир Низамов; шагыйрә, журналыбыз авторы Луиза Янсуар; язучы Рөстәм Галиуллин; КДМУ ассистенты Александр Буховец; «Идел» Яшьләр үзәге.**

## СПОРТ

**■ Казанда су спорты төрләре буенча XVI Дөнья чемпионаты узды. Анда 190 илдән 5400 дән артык спортчы, шул исәптән 1161 Россия Федерациясе спортчысы көч сынашты. Татарстан башкаласындагы су бәйрәмен бөтен Җир шарында 4,5 миллиардтан артык кеше телевизор экраннарыннан карап барды. Спортчылар 75 комплект медаль өчен ярышты. Ярышлар спортның 6 су төре: йөзү, ачык суда йөзү, суга сикерү, хай-дайвинг, синхрон йөзү, су полосы буенча уздырылды. Спорт сөючеләр аларны Су спорты сараенда, «Буревестник», «Оргсинтез», «КСК КАИ «Олимп» бассейннарында, «Казан-Арена» стадионында, Казансу елгасында тамаша кылды.**



PRESSA.RU





# ИДЕЛДӘН – ЕНИСЕЙГА КАДӘР



Фәнзилә МОСТАФИНА

## ТУК-ТУК, ТУК-ТУК, ТУК-ТУК... ӨЧ ТӘҮЛЕКТӘН АРТЫК РЕЛЬСЛАР ӨСТЕНДӘ ТИРБӘЛГӘННӘН СОҢ, БЕР МӘЛНЕ ТУКЫЛДАГАН ТАВЫШ ТЫНДЫ. НИҺАЯТЬ, КРАСНОЯРСК ҖИРЕНӘ АЯК БАСАБЫЗ.

**Казан елап озатып калган иде, ә монда – кояш. Рәхәт! Монысы әле яңадан җирдә басып тору, кояшның җылысын тою сөенече. Шәһәрдә өч көн йөргәч, салкын сулы Енисейда аякны чылатып, Такмак тавына күтәрелгәч, милләттәшләребез белән күрешеп сөйләшкәч, күңелне куанычның башкасы – зуррагы биләп алачак.**







Фото: Алексей Наумов һәм Алисә Сабирова

### *Саумы, Кызыл яр!*

Красноярск краеның тарихы 1934 елның 7 декабреннән башлана. Аңарчы Себернең үзәк һәм көнчыгыш өлешләрендәге җирләр Енисей губерниясе дип йөртелгән. Красноярск шәһәрен беренче тапкыр күрүгә, күз алдында шундый картина туа: мәгърур таулар, горур тайга, көмеш сулы елга куенына урнашкан таш кала. Башыңны уңга борасың – замана белән бер аяктан атларга тырышучы шәһәр ыгы-зыгысы, машина һәм кешеләр ташкыны. Караш буй җитмәслек биек йортларны, XIX гасыр корылмалары белән чиратлашып утырган заманча биналарны колачлый. Боларның барысыннан да арысаң, башыңны сулга бору да җитә: анда – таулар тынычлыгы, Енисей сабырлыгы, кыялар көче. Анда – табигать үзе.

Енисей, крайның буеннан-буена үтеп, төньяктагы Кар диңгезенә коя. «Диңгезнең шулай якын булуы шактый комачаулый безгә: елга кышын да катмый, шул сәбәпле климатыбыз бик үзенчәлекле, бөтен кешенең дә сәламәтлегенә ярамый», – ди Красноярск халкы. Ә Енисейны яраталар. Шулай дип кычкырып йөрмәсәләр дә, аңлашыла. Елга атамасын шигырьләренә, җырларына кушалар. Красноярск турындагы риваять-легендаларда да төп каһарман – Енисей. Борын-борын заманнарда Себердә сихерче Енисей патша хакимлек иткән. Кызлары күп булса да, Базаиха белән Лалетина атлыларын аеруча яраткан ул. Аларны кияүгә бирер чак җиткәч, Енисей тирә-яктагы шаһзадәләрне үз янына чакырткан. Беренче булып патша хөкеменә кенәз Такмак килгән. Олы кыз беренче булып кияүгә чыга, шуңа күрә Такмакның кәләше Базаиха булырга тиеш. Ошатмаган киребеткән Базаиханы кияү. Тыныч һәм сабыр Лалетинага күзе төшкән аның. Кыз да егетнең хисләренә җавап биргән. Тик бу турыда Енисейга әйткәч, аның җен ачуы чыккан. Ярсуына түзә алмыйча, Такмак кенәзне һәм аның ярдәмчеләрен таш кыяларга, ә кызларын елгаларга әйләндергән. Булдык без ул Такмак тавында. Тауның башыннан шәһәр уч төбендәгедәй күренә. Ә кыяларга тияр-тимәс орынып ике елга агып ята: Базаиха белән Лалетина.

Бүген Красноярск краенда татарлар сан ягыннан урыслар һәм украиннардан гына калышып, өченче урында бара. Губернатор Виктор Толоконский белдергәнчә, төбәктә барлыгы 34 меңнән күбрәк милләттәшебез гомер кичерә. Алты милли-мәдәни татар автономиясе теркәлгән: Красноярск, Лесосибирск, Норильск, Шәрип шәһәрләрендә. Татарларның күпчелеге Столыпин реформасыннан һәм Идел буендагы ачлыктан качып, Себергә килеп урнашкан. Бер ише – сәяси репрессия корбаннары. Авылларыавыллары белән чыгып китүчеләр дә булган. Төпләнеп калган урыннарын да туган авыллары исеме белән атаган, шул рәвешле кендек каннары тамган җиргә якынрак булырга тырышкан милләттәшләребез. Шунысы да бар: монда авыллар – бер генә милләтле. Һәм алар бер-берсеннән шактый еракта урнашкан. Әйтик, Красноярскидан 200 чакрымда – чеп-чи татар авылы. Аннан тагын 150 ләп чакрым ары узсаң, чуаш авылына керәсең.

Татарларны хөрмәт итәләр монда. Тырыш халык дип беләләр. «Казанда татарча сөйләшергә оялып, халык урыслаша башлаганда да без телебезне җуймадык. Рәхәтләнеп ана телебездә сөйләшә идек – кырын караучы да, авыр сүз әйтүче дә булмады, кыерсытмадылар», – диләр Красноярск татарлары. Шәһәр мэры Әдһәм Акбулатовның да татар булуы белән горурланалар. Менә быел югары дәрәҗәдә федераль Сабантуй уздырып та милләтебезнең данын еракка тараттылар. Россиянең 36 төбәгеннән татарлар килгән иде анда.

2013 елда Казанда Җәйге универсиада гөрләгән булса, 2019 елда әлеге эстафетаны Красноярск кабул итәргә җыена. Уеннарның кышкысы узачак биредә. Әзерлек эшләре хәзердән үк башланган инде: яңа корылмалар төзелә, юллар яңартыла, шәһәр төзекләндерелә. «Сездәге үзгәрешләрнең бер өлеше генә булса да кертелсен иде бездә», – ди Красноярск халкы. Уеннарның югары дәрәҗәдә узачагына, аңарчы шәһәрнең йөзе дә яңарачагына ышана алар. Югыйсә хәзердән үк 2019 елда кунакка килергә чакырып куймаслар иде.

*Крайдагы татар салаларын барлыйбыз: Тимершык, Икшермә, Ошма...*

### *Ут кебек Люция*

«Ут кебек берәр татарны табып бирегез әле миңа!» Шулай дигәч, без журналистларны озата йөргән волонтер кыз Наташа горур тавыш белән: «Беләсезме, миндә дә татар каны ага бит», – дип куйды. Әбисенә кадәрге буыннары татар булган икән. Тик аннан соң кан алмашу киткән. Наташа да үзен татар тамырлы урыс кызы дип йөри, татарча белми.

Волонтер кыз, «ут кебек татар» дип, бер туташ янына алып килде. «Менә. Яшьлегенә карамагыз, бик акыллы ул, татарча да әйбәт белә», – диде дә китеп тә барды. Люция Гатина белән шулай таныштык.

Лесосибирск татарлары турында, милләтләре өчен үлеп торалар, дип ишеткән бар иде. Люция дә шул шәһәрдән булып чыкты. Хәзерге вакытта Красноярскидагы Себер федераль университетында укый. Икътисад буенча диссертациясен төгәлләп йөргән көннәре.

Татар гаиләсендә үсеп, кечкенәдән ана телендә сөйләшсә дә, милләт тормышында катнашырга уйлап та карамаган Люция. Лесосибирскида тыныч кына икътисад фәнен үзләштереп йөргән. Кем белә, бер очрак ярдәмгә килмәсә, милли җанлы булуын, бәлки, кыз үзе дә белми калыр иде.

«Татар кызы» бәйгесендә катнашырга тәкъдим ясыйлар аңа. Әлеге ярыш Люциягә башка бер киңлеккә

PRESSA.RU





«Казанга сәлам әйтегез!» – дип озатты безне Люция. Һәм Татарстанда танышкан дусларының исемнәрен санап китте. Барысы да милли җанлы яшьләр – Люциянең үзе кебек үк, милләте белән горурланып яши торган егет-кызлар.

чыгарга, татарлыгына башка яктан карарга булыша. Кыз туган шәһәрендәге милли иҗтимагый оешма эшчәнлегендә катнаша башлый. Озакламый аны Казанга – Татар яшьләре форумына җибәрәләр. Люция форумнан үзгәреп кайта. «Татарларның нинди көчле, бердәм булуын күрдем. Казаннан читтә дә милләтемне саклап калуга үз өлешемне кертәсем килде», – ди ул. Красноярскига килеп укый башлагач, Люция җирле милли оешма белән дуслаша, шул ук вакытта Лесосибирскидагы оешма белән дә араны өзми.

*Әнинең әманәтен үтәдем – күзләре күрмәве турында Касыйм абыйга бер сүз дә әйтмәдем. Мәхәббәт сукырая димени?!*

«Сез шундый матур сөйләшәсез – җырлаган кебек». Люция сүзләре бу. Аның соравы буенча теге яки бу сүзне үзебезчә көйләп (Люция биргән билгеләмә!), берничә тапкыр кабатлыйбыз, кайсыдыр сүзне тәрҗемә итеп күрсәтәбез. Ул үзе дә татарча чиста сөйләшә. «Әби исән вакытта телне яхшырак белә идем кебек. Аның янына авылга кайткач, татарча гына сөйләштек – әбием урысча белми иде. Ул татарча әллә нинди колак ишетмәгән сүзләр әйтә, ә энем Ришат белән мин кызыксынып өйрәнә идек», – дип искә алды Люция.

Кыска гына вакыт эчендә Казанда дүрт тапкыр булырга өлгергән инде ул. «Ә укып бетергәч безгә килергә теләк юкмы?» – дим, әңгәмәдәшемнең бүген-иртәгә аспирантура тәмамлаячагын истә тотып. «Мин Казанны яраттым. Эш булса, нишләп әле яшәп карамаска, ди?» – Башка төрле җавап көтмәгән дә идем Люциядән.

### *Себер киткән мәхәббәт*

71 яшьлек Гәүһәрниса апа Әсватуллина: «Сезгә нәрсә турында сөйлим икән: мәхәббәт хакындамы, әллә башкасынмы?» – дип башлады сүзен. Билгеле инде, мәхәббәт турында! Аякларны бөкләп, яшел чирәмгә утырдык. Янәшәдә Гәүһәрниса апаның балалары, оныклары кайнаша, Сабан туе мәйданыннан татарча җыр агыла. Әңгәмәдәшем, шул көйгә изрәп, хикәятен башлый.

– Минем әни 1903 елда Буа районы Әлки авылында туган. Ә 1921 елда, 18 яше тулгач, ерак Себергә китеп барырга мәҗбүр булган. Ачлыктан качып, ул елларда күпләр күченеп киткән бит. Бабай белән әби дә, дүрт балаларын ияртеп, бәхет эзләп чит җиргә юл тоткан. Туган җирләрендә калсалар да булыр иде. Тик әниемә апасының уллыкка алган малаеның күзе төшкән. Бик чибәр булган шул әнием. «Сез туганнар, ике туганның арасын бозасыз», – дип, гашыйкларны аерганнар. Касыйм абый әни утырган арба күздән югалганчы карап калган.

Красноярск краена килеп урнаша алар. Чибәр Зәйнәпбану (Гәүһәрниса апаның әнисе була инде) Мамадыштан күченеп килгән татар егетен үзенә яр итә. Тик гомере буе яшьлек мәхәббәтен – Касыймын сагынып яши. Ана белән кыз арасында сер буламыни – менә Зәйнәпбану да кызларына күңелен бушата торган булган.

– Әни Татарстанны бик сагынды. Һәр куакның, һәр үсемлекнең исемен әйтеп сөйләр иде. Тәтәм (Красноярскида апа димиләр, тәтә дип дәшәләр) белән икебез йотлыгып тыңлыйбыз, – ди Гәүһәрниса апа.

Әнисенең хыялын кызы тормышка ашыра: 1982 елда тота да тормыш иптәше белән Татарстанга чыгып китә. Ул вакытта инде күзләре күрми башлаган Зәйнәпбану карчык: «Касыйм бабаң янына кер, күчтәнәчемне бир, тик күзләрем күрмәвен генә әйтмә», – дип озата кызын.

– Касыйм абый Буа районының Яңа Чәчкап авылында яши икән. Өен эзләп таптык. Бик ямьле вакыт – июнь ае бу. Канәферләр чәчәк аткан. Ачык тәрәзәдән кечкенә генә өй эченә чәчкәләрнең хуш исе тулган. Кердек, исәнләштек, дога кылдык. «Кем буласыз соң?» – ди Касыйм абый. Тәрәзәгә кояш төшкән иде, шуның яктысына килеп бастым. Ул да минем каршыма килде. «Касыйм абый, 1921 елны апрель башында арбага утыртып кемне озатып калдың?» – дим. Бабайның төсе үзгәрде, агарды, иреннәре, сакалы дерелди башлады. Күзләремә карады да: «Зәйнәпбануым, кайттыңмыни?» – дип, мине кочаклап алды. (Гәүһәрниса апа гүя яңадан шул көнгә кайтты – Касыйм бабай роленә кереп, мине кысып кочаклап алды. Тән буйлап «кырмыскалар» йөгерешкәне сизелде.) 60 елдан соң миндә әнине күрде ул. Кочаклады да калтырап еларга тотынды, аңа кушылып мин елыйм, безгә карап ирем үкси. Менә нинди мәхәббәт тә була икән!

Тынычлангач, бергәләп чәй эчтек. Касыйм абый өзми-куймый: «Мин гомер буе Зәйнәпбану киткән юлга карап гомер иттем, кайтыр дип көттем – кайттыңмыни?» – дип кабатлады.



■ Губернатор тапшырган чәчәк бәйләменә йөзен яшереп, Катифә апа гади генә итеп тормыш шигарен әйтә дә бирә: «Акча артыннан да кумадым, мактау сүзләре дә көтмәдем. Милләтем генә яшәсен – шунысы иң зур бүләк».

Әнисенең туган нигезенә дә керә Гәүһәрниса апа. Чит-ят кешеләр яңа йорт салып чыкса да, Хәсәнҗан бабасы салган нигезгә тимәгән булалар. Әңгәмәдәшемнең күзендә яшь бөртекләре күренә: «Ул ташларны бик озак сыпырып утырдым – җылысын әнигә алып кайтып җиткерергә кирәк иде...»

Гәүһәрниса апа ире Шамил белән өч бала тәрбияләп үстергән. Бүген сигез оныклары һәм бер туруннарының бәхетенә куанып гомер итәләр. «Татарстанны бик сагынам. Кан тартмаса да, җан тарта икән», – ди Гәүһәрниса апа һәм өстәп куя: «Сине дә сагынырмын инде...»

### *«Милләтем генә яшәсен!»*

Мин «Сөембикә» журналыннан, дип әйтүем булды, чираттагы әңгәмәдәшем Катифә апа Закураева үз кызыдай кочып ук алды. «Гомер буе алдырган «Сөембикә»м бит ул!» Ерак Себердә бу сүзне ишетүнең ничек рәхәт икәнен белсәгез! «Себердә торсак та, без татарча укыдык. Шуңа күрә урыс китапларына, урыс матбугатына күңелем ятмый. Миңа «Сөембикә», «Казан утлары» булсын», – дип тә өстәсәләр...

Әңгәмәдәшем үзе Красноярск краеның Долгий авылында туып-үскән. Әби-бабасы исә Мамадыш районы Тәкәнеш авылыннан. Катифә апа Лесосибирск шәһәрендә татар оешмасын барлыкка китерүчеләрнең берсе дә әле. «Мин мәдәният хезмәткәре булып эшләдем. Мәдәният йорты директоры Мәхмүт абыйның: «Әйдәгез, татарларны җыйыйк әле», – дип аптыратып бетерә идем», – дип искә ала ул. Ә авылдан Лесосибирскига күчеп яши башлагач, Катифә апа автобазага өлкән диспетчер булып урнаша. Шулай да кешеләрне оештырып йөртү сәләте гел кирәк булып тора аңа.

Катифә апаның җиде бертуганы да татар гаиләләре корган. Ә ул үзе, бөтен барлыгы белән татарым дип яшәүче милли җанлы кыз, тормыш иптәше итеп кабарда егетен сайлаган. «Клубта эшләгән чагым. Алар безнең авылга эшкә килделәр. Кичен клубка да чыгалар, безгә дә сүз каталар бит инде. Үземнең очраша торган егетем имтиханнар тапшырып йөри. Ә бу кабарда егете бер көнне озата кайтты. Шулай бер озатты, ике озатты бу мине. Уйламаганда-көтмәгәндә кавышып та куйдык. Бөтен авылга каршы килеп, чит милләт кешесенә тормышка чыктым», – дип көлә Катифә апа. Диннәре бер булгач, яшәү авыр булмаган. Югыйсә 43 ел үрнәк гаилә булып яши дә алмаслар иде. Кызлары Роза белән Фатыймага Катифә апа кечкенәдән татар телен өйрәтеп үстергән, ә алар, үскәч, әтиләрен өйрәткәннәр.

Ә менә кияүләре урыс икән. «Шулай булса да, кызларым өйләрендә татар мохите булдырды. Оныкларга Ваня-Маня дип кушасы булмагыз, дип алдан ук әйтеп куйдым. Каршы килмәде кияүләр. Хәер, миңа каршы килеп булмый да торгандыр. Оныкларыма кечкенәдән татарча өйрәттем. «Әлхәм», «Кәүсәр», «Нәс», «Фәләк» сүрәләрен дә яттан беләләр. Оныгым сигез яшендә җидешәр йөз тәһлил әйтә торган иде!» – дип елмая әңгәмәдәшем. Күзләрендә – сөенеч һәм горурлык.

Катифә апа 1991 елда Казанда булып киткән. Тагын җыена. «Сөембикә» редакциясен, «Яңа гасыр» телеканалын үз күзләрем белән күрәсем килә ди. Казан белән Себердә яшәүче татарларның аермасы турында сорашам. «Сезнең якларда хатын-кызлар зиратларга кереп йөри. Ә бездә – юк. Сездә татары, урысы, марие, чуашы бергә тора, ә бездә һәр милләт аерым авыл булып яши. Укытучы яки зоотехник татар авылына килсә, кыска гына вакыт эчендә татарга әйләнеп тә куя», – ди Катифә апа.

*Авылларда, Лесосибирск шәһәрендә мәчетләр эшләп торуын да сөенеп телгә алды ул.*

«Авылымны бик яратам. Халкымны яратам. Машина белән авылыма кайтканда: «Тау башында кала бер кала, ул кала Долгий дип атала», – дип җырлап барам. Гомер буе милләтем дип яшәдем, калган гомеремне дә шул юлдан барырга язсын», – ди Катифә апа. Красноярск крае губернаторы Виктор Толоконский «Рәхмәт хаты» да тапшырды аңа. Юкка түгел: 25 ел буе авылларда һәм Лесосибирскиның үзендә Сабантуйлары уздыруда башлап йөргән, милли гореф-гадәтләрне саклап калу юнәлешендә зур эш башкарган кеше ул Катифә апа».

**P. S.** Красноярск татарлары эстафетаны Түбән Новгородтагы милләттәшләребезгә тапшырды. Татарстан Президенты вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Рөстәм Миңнеханов карары нигезендә, киләсе елга федераль Сабан туе шунда узачак. Бөтен дөнья татарларының җыелу урыны үзгәрсә дә, максаты үзгәрми – гореф-гадәтләрне күрсәтү аша милләтне җиһанга таныту.

Казан–Красноярск–Казан.

PRESSA.RU









# ТАЛПЫНГАН КОШ ОЧМЫЙ КАЛМАС

## БИШ МЕҢ СӘГАТЬ! КҮКТӘ УЛ ӘНӘ ШУНЫҢ КАДӘР ВАКЫТ ҮТКӘРГӘН!



Нәзифә
КӘРИМОВА

**Югары пилотаж буенча дөньяның абсолют чемпионы, СССРның атказанган спорт мастеры, Дөнья чемпионатларында халыкара категорияле судья (1984, 1986, 1990), Дөнья чемпионы (1984, 1986, 1990), Европа чемпионы (1985, 1987), социалистик илләр арасындагы Халыкара очучылар бәйгесендә абсолют җиңүче (1985, 1988), Австралия кубогы бәйгесендә абсолют җиңүче (1996)... Болар бар да очучы татар кызы Халидә МАКАГОНОВАның уңышлары! 1984–2009 еллар арасында Жуковскийда, Тушинода, АКШта, Берлинда, Англиядә, Исландиядә, Португалиядә, Австралиядә узган авиашоуларда ул югары очу осталыгын күрсәтә. Йөздән артык авиация курсанты әзерли. Авиациядә эшләгән елларында егермедән артык төрдәге очкычта һәм боралакларда очарга өйрәнә. Россия авиаспорты федерациясенең генераль секретаре һәм очучы белгечлегенә ия булган хатын-кызларның «Авиатрисса» клубы президенты вазыйфаларын башкарган Халидә Макагонова бүген дә зур иҗтимагый эш алып бара.**

Халидә ханым Макагонова белән без Мәскәүдә, Татарстанның вәкаләтле вәкиллегендә танышкан идек. Аннан соң мин аны Фуат Мансуровка һәйкәл ачканда очраттым. Ә «Татарстан якташлары» оешмасын тәкъдим итү кичәсендә без инде күптәнге танышлар кебек сөйләшеп киттек. Әңгәмәдәшемнең Россия авиация спорты тарихында шактый билгеле шәхес булуын белү мине шаккаттырды гына дисәм аз булыр... Очучы татар хатын-кызы дигәч, без бит Мәгубә Сыртланованы гына искә төшерәбез!

Халидә ханымның әтисе Хөсәен абый Түбән Новгород өлкәсенең Мәдәнә авылында туган, әнисе Хәнифә апа – Чөмбәли кызы. Алар Мәскәүгә сугыштан соң күчеп килгәннәр. Халидә ханым инде Мәскәүдә туган. Гаиләдә алар биш туган: өч ир-малай (Рафик, Рәис, Харис) һәм ике кыз. (Халидәнең Хәсәнә исемле сеңлесе дә бар).

Халидә үз тиңнәреннән бернәрсә белән дә аерылып тормаган, гади мәктәп баласы булган дисәм... Ул балачактан күкләр турында хыялланган, очкычлар, очучылар хакында китаплар укырга яраткан.

Мәскәү – зур кала, әмма балалар шөгыльләнә торган очучылар мәктәбен ул үзе эзләп таба. Соңыннан аэроклубның самолетлар бүлегенә юл тота. Беренче килүендә аны кабул итмиләр. Ләкин бер елдан соң аэроклуб ишекләрен ул кабат ачып керә һәм кире кагарга урын калдырмаслык итеп: «Сез мине былтыр кабул итмәгән идегез. Быел менә тагын килдем. Ләкин бу юлы инде борылып китмәячәкмен, мин сездә очачакмын!» – ди. Алга таба Халидә үзенең «барыбер очарга тиеш» булуын исбатлый да.

Халидәнең балачагы, җәйләре әтисенең һәм әнисенең туган ягында, авылда – әбиләре янында уза. «Җиде яшемдә мәктәпкә барырга дип мине авылдан алып килделәр, – дип искә төшерә ул. – Бер авыз сүз русча аңламаганымны белгәч, беренче сентябрь алдыннан әнинең: «И Ходаем, ничекләр укырсың икән?» – дип хафаланганын хәтерлим».

– Шулай да «очучы булам» дигән ныклы карарга кайчан килдегез? Әти-әниләрегез моны ничек кабул итте?

– Әти белән әнигә башта белгертмәдем. Белгәч, әни бик нык кайгырды инде. «Очучы булам» дигән хыял күңелемдә, әйткәнемчә, 10 яшьләр тирәсендә үк бөреләнде. Заманы да шундый иде аның. Юрий Гагарин очышыннан соң безнең ил зур күтәренкелек белән авиацияне өйрәнә, үзләштерә башлады. ДОСААФ түгәрәкләрендә шөгыльләнгән яшьләргә самолет яки вертолетта, парашютта, планерларда очу – барысына да юл ачык иде. Без ул вакытта җиңүләргә омтылып яшәдек, тормышта үз урыныбызны табарга тырыштык.

– Беренче очышыгыз исегездәме?

– Беренче очыш... Ул минем чираттагы авыр имтиханнарымның берсе иде. Андагы хис-кичерешләр... Алар «ничек кенә булса да ялгышмаска, барысын да дөрес эшләргә» дигән курку катыш җаваплылыктан торгандыр. Мин ул вакытта прибордагы күрсәткечләрдән башка берни күрмәдем. Ә очу белән бәйле гаҗәеп рәхәт халәтне, шатлыкны беренче тапкыр үзем генә, инструкторсыз очканда гына кичердем.

Әле аңа кадәр дә очулар булды бит. Беренче тапкыр һавага күтәрелгәндә бары тик... ике метр гына очтым. Агач планер иде ул. Без аны «брошка» дип йөртә идек. Көннәр буе аэроклубта ята идем. Чиратлап очабыз. Чират көткән арада бер-беребезгә ярдәм итәбез – парашютларны очуга әзерлибез. Үземне һавага күтәрелергә чакырганчы кырыклап парашютны очышка әзерләгәнмен, төргәнмендер. Шулхәтле көттем очу минутларын! Парашютсыз да очарга әзер идем. Шунысын да әйтергә кирәк: очучылар парашют алып очарга бик яратмый. Ләкин кагыйдә буенча ул, һичшиксез, үтәлергә тиеш. Хәтта алар инде югары пилотаж белән шөгыльләнсәләр дә.

– Шулай да җиргә югарыдан, күктән карау, очкыч белән идарә итү нинди тәэсирләр уята?

– Җирдәге проблемалар җирдә кала... Атлап йөргәндә күрә алмаган матурлыклар, киңлекләр ачыла. Дөньяның яңадан-яңа матурлыкларын күрү шатлыгын бернәрсә белән дә чагыштырып булмый. Кырыйдан гына болытлар йөзеп уза – кулыңны гына суз...

*«Очучы булачакмын!» – дигән карарны ул инде ун яшендә үк кабул иткән.*

– Сезнең эштә иң авыры нәрсә?

– Үз-үзеңне җиңү! Кайчагында үз-үземә: «Нәрсәгә кирәк инде бу сиңа? Бу тиклем авыр тренировкалар, гәүдәгә күтәрә алмаслык басым ясау...» – дия идем. Бөтен халәтем бу авырлыкларга каршы килә: баштүбән асылынып тору, канны башка куу, аннары аякларга төшерүне һич кабул итми. Кан тамырларына көч килеп, кан савулар да булды... Тик күнегүләрнең бер рәхәтен тапмасам да, ташламадым – үҗәт, үзсүзле идем. Ә осталык вакыт белән киләдер... Күңелдә ышаныч туганчы, самолетны үземә буйсындырганчы, очканда хөрлек хисен тойганчы күптөрле авырлыклар узарга туры килде әле. Ләкин соңрак кичерәчәк тойгылар боларның барысын да онытты.

Бездә иң мөһиме – дисциплина һәм теория. Күккә юлым ДОСААФның аэроклубыннан башланды бит минем: анда безгә төпле белем бирделәр. Мәскәү авиация институтында укыган вакытта да аэроклубта алган белемнәр бик ярдәм итте, миңа анда уку авыр булмады.

– Ни генә дисәгез дә, күккә күтәрелгәч, очучыга һәрдаим куркыныч яный... Һәрхәлдә, миңа шулай тоела.

– Безнең инструкцияләрдә «очышта гадәттән тыш хәл» («особый случай полета») дип аталган маддә дә бар. Очучылар арасында «ул кагыйдәләр кан белән язылган» дигән гыйбарә йөри... Булды, андый очраклар

PRESSA.RU





да булгалады... Əмма минем сакчы фəрештəм бардыр дип уйлыйм – исəн-имин калдым. Бервакыт Дөнья чемпионатына əзерлəнəбез шулай. Чемпионат бер квадратта уза, ə тренировкалар икенче – безгə таныш булмаган квадрат өстендə үтə. (Чит иллəрдə узган чемпионатларда кайсы квадратта очыш ясаячагыңны белмисең.) Югары пилотажның əле бер, əле икенче фигурасын ясап оча торгач, онытылып киткəнмен, карасам, очкычта ягулык беткəн! Очкыч аланына барып җитмəячəгемне шунда ук аңладым, чөнки алда авыллар, Идел... Башка юл юк: үзем тренировка ясаган квадрат өстенə утырырга булдым. Шассиларны чыгармыйча... Ходай саклады – очкычка да, үземə дə зарар килмəде.

*Үзара да, гаилəдə дə, кешелəр белəн мөнəсəбəттə дə вакчыллык дигəн нəрсə юк очучыларда.*

– Очышка ничек əзерлəнə идегез? Бөтен очучыларга кагылган кагыйдəлəр турында сорамыйм...

– Очышлар булган көнне өйдəн гел: «Якыннарым исəн-сау булсын», – дип телəк телəп чыгып китə идем. Һавага күтəрелер алдыннан, бер аулак почмак табып, күктə башкарачак программаны күз алдыма китереп, башымнан кичерəм... Барысын да җир өстендə бер кат барлау миңа бик ярдəм итə иде.

Очмый башлавыма инде менə ике ел була. Хəзер тренерлык хезмəтен башкарам. Халыкара «Авиатрисса» оешмасы президенты буларак та эшлəрем шактый – өлгер генə.

– Якыннарым дидегез... Ирегез белəн кайда таныштыгыз? Гомумəн, гаилəгез турында да сөйлəгез əле.

– Без аның белəн аэроклубта таныштык. Ул самолетларны сынаучы-очучы. Əле һаман да шул эшендə. Кайнанам, заманында, аның өчен бик борчылып: «Əйтеп кара əле үзенə, очмасын иде», – дип тə үтенгəн иде... Улыбыз безнең юлдан китмəде, лəкин ул да очкычларны үзлəштерде, оча ала. Безнең дүрт оныгыбыз бар. Хəзер инде күбрəк алар белəн буласым килə. Үзем тренировка, бəйгелəрдə йөреп, улымның үсүен күрми дə калдым. Кайнанама бик рəхмəтлемен – ул иң беренче ярдəмчем булды.

– Сайлаган һөнəре кешенең холык-фигылен тəэсир ясамый калмый, дилəр...

– Əйе, шулайдыр. Без, мəсəлəн, очучылар гел икенче кешелəр. Ниндидер бер үзенчəлек бар бездə. Аңлата да алмыйм моны... Җирдəн аерылып, күктə булуның йогынтысы тими калмыйдыр ул. Очу мине күп нəрсəгə өйрəтте. Тормышның кадерен аңларга, аның кирəкле, мөһим ягын дөрес күрə, бəяли белергə дип əйтимме... Вак-төяктəн арынырга, аларга игътибар итмəскə. Югалтулардан соң алган гыйбрəт, сабак бу. Ə югалтулар күп булды... Бергə янəшə эшлəгəн, бергə очкан иптəшлəрне, дусларны югалту... Бик авыр хəл ул. Һавадагы дусларыңа җирдəн торып берничек тə ярдəм итə алмыйсың. Ул оча, югары пилотаж фигураларын ясый һəм кинəт... очкычның канатлары салынып төшə, очкыч җиргə кадала... Ничек ярдəм итəргə ул вакытта? Күз алдымда күпме кеше шулай һəлак булды. Без моны техник якның артта калуы, аның пилотаж фигуралары өчен кирəкле дəрəҗəдə эшкəртелмəве белəн аңлата идек. Чөнки очкыч конструкциялəре кирəгенчə эшлəнмəгəн, өйрəнелмəгəн иде. Очканда барыбыз да бертигез: кем исəн-имин җиргə төшеп утыра, кем һəлак була – ул турыда беркем дə алдан белми бит. Шуның өчен тормышта мөһим əйберлəрне бəяли белергə өйрəндек тə.

– Татарстанның Мəскəүдəге даими вəкиллегеннəн, Сезне эзлəп табып, «Татарстан якташлары» оешмасына чакыруын ничек кабул иттегез? Тарихи Ватаныбызда булырга туры килгəне бармы?

– Казанда булганым бар. Дөрес, бер генə тапкыр. В. Гризодубова, П. Осипенко, М. Раскова очып, үткəн Мəскəү–Ерак Көнчыгыш маршрутын кабатлап (1938 елда алар 26 сəгать 29 минут бертуктамый очып, рекорд куялар), əлеге вакыйганың 60 еллыгы уңаеннан Американың очучы хатын-кызлары белəн шул маршрут буенча очыш оештырып, үзем дə анда пилот буларак катнашкан идем. Безгə ул чакта Казанда тукталырга туры килде. Ə Татарстанның даими вəкиллеге мине үзлəренə чакыргач, бик сөендем. Үземне зур бер гаилə кешесе итеп хис иттем... Онытылып барган милли хислəр яңарды. Татар булганым белəн бик горурланам. Шунысын да əйтергə кирəк, «татар» дип үземне кимсеткəн очракларны хəтерлəмим.

– Сез бəхетлеме?

– Əлбəттə! Тик менə вакыт кына шулхəтле тиз уза, əйтерсең, ул да оча! Гомер бик кыска! Күп нəрсəлəргə өлгереп булмый. Мин хəзер һəрбер көнемнең, һəр минутымның кадерен белеп яшим.

Мəскəү.



# ТЕРЕКӨМЕШ

**Сез ничектер, мин үзем бүгенге яшьләргә кызыгам. Нинди кыюлар, тәвәккәлләр! Кызыклы идеяләр белән яшиләр, чит телләр беләләр, илләр гизәләр. Шул ук вакытта нәсел тамырлары, әби-бабадан калган гореф-гадәтләр дә кызык аларга. Санкт-Петербургта яшәүче Рената Байтемирова да шул кавемнән. Әле үзен күреп белгәнче үк, «терекөмеш» дигән аты килеп ирешкән Рената белән безне Бөтендөнья татар хатын-кызларының III форумы таныштырды.**

Рената Ленинград өлкәсендә яшәүче татарларга яхшы ук таныш. Оста оештыручы дигән даны бар аның. Зур вакыйгаларның уртасында кайнарга ярата ул. Узган ел Мәскәүдә узган Беренче Бөтенроссия «Татар кызы-2014» конкурсы хәтерегездә микән? Россиянең төрле төбәкләреннән егерме кыз финалга чыккан иде. Бу кызларны финалга әзерләүче куратор-остаз итеп Ренатаны чакыралар. Егерме кызны хәлиткеч көнгә кадәр берберсе белән тәмам дуслаштырып бетерә ул. Югыйсә үзара көндәш бит алар! Җиңүче таҗы да тик берсенә генә булачак. Татар халкы киң күңелле, сабыр – әллә шулмы, әллә башкамы – бар да тыныч кына уза. Ул кызлар белән дуслыклары әле бүген дә дәвам итә, телефон кенәгәләрендә кураторларының номеры «мамуля» дип теркәлгән.

Татар кызы булу да ошый Ренатага. «Сез рус кызы түгелме әллә?» – дип сорасалар, башын тагын да югарырак чөеп, бит уртасындагы мәхәббәт чокырларын тагын да мәхәббәтлерәк итеп: «Мин – татар кызы!» – дип әйтергә ярата ул. Аларның нәсел кушаматы: «Казан». Бабалары Казан төбәгеннән. Татарлыгы җанында Ренатаның. Үзе яшәгән тирәлектә татар рухын ныгыту өчен бар көчен куя ул. Сөйләшүен яхшы сөйләшсә дә, әлегә татарча укуы гына чамалырак менә. Шулай да тырыша ул, сүзлеккә карый-карый булса да укый. Дөнья әдәбиятын бел дә, үз халкыңныкын белмә, имеш. Инде моннан соң тагын да тырышыр. Рухландыручысы татар егете булгач соң! «Диапазон» вокаль-эстрада студиясен җитәкләгән ире Динар Байтемиров белән быел аларның күн туйлары. Кавышуларына өч ел. Санкт-Петербургта консерватория тәмамлаган Динар – татар җырчысы. Аның белән табышулары – таң яралганда теләгән теләкләренең тормышка ашуы. Үз тиңен табып, гаилә кору уе башына кергән көннән алып, Аллаһы Тәгаләдән үзенә насыйп татар егете белән таныштыруын сорый Рената. Дус кызлары көлә генә: «Санкт-Петербургта сиңа дигән татар егете калмагандыр да инде. Эзләү чикләрен киңәйтергә кирәк». Билгеле, аларга карап кына, өметен өзми ул. Һәм... морадына ирешә. Булачак ире белән юллары «Казан» бию ансамбле концертында кисешә аларның.

Динар – Әстерханнан, Сөембикә ханбикәнең туган туфрагыннан. 2012 елда «Татар моңы» Халыкара телевизион конкурсының җиңүчесе. Гомумән, 2012 ел уңышлы була аның өчен – Россия Федерациясе хөкүмәтенең грантын отып, яшүсмерләр һәм балалар өчен «Диапазон» вокаль-эстрада студиясен ача, «Җырлагыз» дип аталган альбомын яздыра.

Рената һәрвакыт Динары янында. Кая карасаң да, бергә алар. Бергә концертлар оештыралар, бәйрәмнәр алып баралар. Санк-Петербург Сабантуйлары да алардан башка гына узмый. Хыялый Ренатаның башында идеяләр туып кына тора, тормышка ашырып кына өлгерт.

Менә шундый бәхетле яшь гаилә! «Гаиләмне офыктагы рәшә кебек ниндидер бер карьерага алыштырам-мы соң?» «Ак калфак» оешмасының Петербург бүлекчәсе җитәкчесе; татар яшьләре берлеге әйдаманы; «Нева фәрештәсе» хәйриячелек җәмгыятенең хокук һәм икътисад мәсьәләләре белгече, ревизор; Гатчина шәһәрендәге «Юлдаш» татар-башкорт җәмгыяте активисты; Гатчина шәһәрендә узган Рәшит Нәҗметдинов исемендәге Бөтенроссия шахмат фестивале проектының җитәкчесе булган Рената әйтә моны. Шахмат, дигәннән, ул үзе дә корольләр уены белән мавыга. Хәтта өченче разряды да бар. Ни әйтәсең, булганнан бар да була инде. Менә шундый алар татар яшьләре!

Лилия ГӘРӘЕВА

PRESSA.RU



**Державин бакчасы Казанның хәзерге Ирек мәйданында – Дворяннар мәҗлесе (Дворянское собрание) бинасы каршында урнашкан була. Совет чорында ул бинаны Офицерлар йорты дип йөрттеләр. Хәзер анда – «Казан Ратушасы» урнашкан.**





# ДЕРЖАВИН БАКЧАСЫ

1870 елның 3 июлендә шушы бина каршындагы буш урынга моңа кадәр Император университеты ишегалдында торган шагыйрь Гавриил Державин һәйкәлен күчерәләр. Һәйкәлне күчерү вакыйгасы турында «Казанские губернские ведомости» газетасында болай дип язып калдырылган: «27 июньдә әзерлек эшләре башланды, ә 3 июльдә һәйкәл үзенең яңа урынына сөйрәтелде. Сөйрәтелде дибез, чөнки аны арбага салып та илтмәделәр, күтәреп тә түгел, ә нәкъ менә бауга җигелгән халык һәйкәлне алты сәгать буена сөйрәде». Бакчаның тарихы да шушы һәйкәлне күчергәннән соң башлана.













1871–1872 елларда һәйкәл тирәли агачлар утыртыла, сквер булдырыла. Соңрак ул бик матур бакчага әверелә. Татарлар телендә «Бакыр бабай бакчасы» дип атап йөртелгән Державин бакчасын Николай скверыннан (хәзерге Ленин бакчасы) Уң Черек күл (хәзер Дзержинск урамы), Кече Лецкая урамнары гына аерып торган. Бакчаның Театр мәйданына караган төп капкасына таш баскычлар алып менгән. Бакча үзе челтәрле агач рәшәткә белән әйләндереп алынган булган.

Кичләрен бакчага затлы байгуралар җыелырга яраткан. Бакча эчендә көмеш сулы фонтан бәреп торган, тәмле сулар һәм кымыз сату өчен пыяла гөмбәзле беседкасы булган. 1890 елда Казанда уздырылган Халыкара күргәзмә өчен бакча эчендә биек павильон төзелгән. Ресторан ачылган.




1931 елда Державин һәйкәле шәһәр хакимияте карары белән урыныннан алына һәм юк ителә. Һәйкәл белән бергә бакчаның да язмышы хәл ителә. 1933 елда аның урынына Муса Җәлил исемендәге татар дәүләт опера һәм балет академия театры бинасы төзелә башлый. Бакыр бабай бакчасы бүгенге көндә истәлекләрдә һәм шул чордан сакланып калган фотосурәтләрдә генә яши.

Сәхифәне Татарстан Милли музееның матбугат үзәге хезмәткәре Ленар НӘГЫЙМОВ алып бара. Фотолар: Татарстан Республикасының Милли музей фондыннан.

PRESSA.RU



Туфан Миңнуллин... Халкыбыз өчен кадерле бу олуг зат турында күпме генә сөйләсәк тә, аны ачып бетереп булмастыр сыман. Күренекле драматург, мәртәбәле шәхес, дәүләт һәм җәмәгать эшлеклесе, халык язучысы, милләтебезнең талантлы улы... Шулай да ул безнең өчен, барыннан да бигрәк, сабый холыклы чын кеше. Кирәк икән – давылдай гайрәтле, кайчагында – фәлсәфи, күп вакыт – шаян, еш кына – хыялый... Һәм һәрвакыт ихлас!
Без аның драма әсәрләрен карап, кабатланмас геройларына сокландык. Кыска хикәяләрендәге авыл кешеләрен үз итеп яраттык. «Туфан абый ни әйтер?» – дип, парламент мөнбәреннән милләт, халык, туган тел язмышын кайгыртып ясаган кайнар чыгышларын көтеп алып тыңладык.
Туфан абый олы драматург кына түгел, олы шагыйрь дә булган икән ләбаса! Робагыйлары гына укып карагыз! Аның шаянлыгы, җор теле, Әлмәндәре кебек тапкырлыгы, егетлеге ачыла да куя. Бөтен барлыгы, холкы-фигыле белән шагыйрь ул болай да!
Бу көннәрдә бөтен татар халкы, сагынып, Туфанын искә төшерә, олуг әдипнең 80 еллык юбилеен билгеләп үтә. Ул безнең күңелләребездә һаман шулай тапкыр һәм тәвәккәл, горур һәм гаярь калыр. Бәгырьдән чыккан сүзләре киләчәк буыннарга васыять булып барыр.



Туфан
МИҢНУЛЛИН

# ӘЙТЕЛМӘГӘН СҮЗЛӘР КАЛА...

* * *
Карап торам. Карап-карап
туймый торам,
Соклануддан сүз кушарга
кыймый торам.
Язмыш сине көнче ирдән
саклый күрсен –
Чибәрлегең көн дә тотып
кыйный торган.

* * *
Җүләр, димсең? Җүләр булгач,
җүләр инде,
Җүләр кеше җүләрләрчә көлә инде.
Минем сине яратканны Казан түгел,
Мәскәү белән Токио да белә инде.

* * *
Ачуланма мине, карчык, тиргәмә дә,
Минем өчен нервы бозып
чирләмә дә.
Яшьлегемнең яшьтәшләре
мине бутый –
Туфан абый, син яшь әле, дияләр дә.

* * *
Бу дөньяда кимлегеңне белдертәләр,
Елаталар, кирәк икән көлдертәләр.
Әнә, кара: атка камыт кидергәндә,
Аның башын ничек итеп идертәләр.

* * *
Яңа яуган кар өстендә эзләр кала,
Аерылганда, әйтелмәгән сүзләр кала.
Бар да үтә, бар да кала...
Иң авыры –
Мөлдерәмә өмет тулы күзләр кала.

* * *
Керфекләрең –
зәңгәр күлнең камышыдыр,
Танышуларның дәвамы –
кавышудыр,
Кавышуларның ахыры – гомер буе
«Син – елан!» – дип,
«Ә син – эт!» – дип ярышудыр.

* * *
Пар табыла шашып-шашып
сөйгәннәргә:
Таһир-Зөһрә, Фәрһат-Ширин,
Мәҗнүн-Ләйлә...
Әй, Матурым, шушы бөек исемлеккә
Туфан абый һәм Син булып
керик мәллә?

* * *
Карт түгел мин һәм
картаймам мәңгегә.
Ышандырып нәрсә әйтим
дәлилгә? –
Галиябану әби булмый һичкайчан,
Бабай диеп эндәшмиләр Хәлилгә.

* * *
Үтте язым, җәем, җитте инде
көзләр...
Бу сүзләрне шуның өчен язам,
кызлар:
Туфан абый, зинһар өчен,
картайма, дип,
Берегезнең, бәлки,
бераз күңле сызлар.

* * *
Хастаханә. Тәрәзәсе урам якта.
Карыйм шуннан
күңел төшеп киткән чакта –
Көн озыны тыз-быз чапкан
ханымнарның
Хет берәрсе уйлый микән
минем хакта?!

* * *
Син кыз чакта,
мин дә әле егет чакта,
Куып тотып үпкән чакта теге чатта,
Истән чыккан,
ни дип әйткән идең миңа,
Шул турыда язып җибәр әле хатка.

* * *
Ап-ак карлар явып үткән үзәннәргә,
Ак төс иңгән без табынган
гүзәлләргә...
Сокланып һәм моңсуланып
карап торам
Бабай диеп үзәгемне өзгәннәргә.

* * *
Сандугачны кем өйрәткән
җыр җырларга?
Чәчәкләрне кемнәр сипкән
болыннарга?
Зинһар өчен, ат буласын
белгертмәгез
Болыннарда уйнаклаган колыннарга.

* * *
Үтте кызлар: «Исәнмесез, бабай!» –
диеп,
Артларыннан карап калдым,
башым иеп.
Шунда кинәт, арандагы
яшь айгырдай,
Егет чагым кешнәп куйды,
башын чөеп.

* * *
Карап торам: чәчләреңә
бәсләр кунган,
Күзләреңнең каралыгы
шактый уңган.
Булды инде, җитте инде, тыел инде,
Ал намазлык, менә дисбе,
әнә комган...

* * *
Беләм инде, сиңа кызык
миннән көлү,
Миңа кызык – синең үртәгәнне белү.
Шулай инде, дорогая, нишләтәсең,
Картлык плюс яшьлек
һәрчак равно нулю.

* * *
Мәхәббәт ул нәрсә димсең?
Хикмәттер ул –
Бал ягылган ике телем икмәктер ул:
Бер мизгелдә балын
ялап бетергәчтен,
Ипи кимереп
икәү гомер итмәктер ул.

* * *
Салкын кышта яз башлана,
имештер...
Елның башы яз булырга тиештер –
Уйный кояш, яшәрә җан,
кайный дәрт –
Матур кызлар судан кайтып
килештер.

* * *
Кайдан алдың кашларыңның
кыйгачлыгын,
Кемнәр бирде күзләреңнең
көләчлеген?
Ходай димсең? Рәхмәт аңа!
Ләкин нигә,
Нигә миңа биргән
Мәҗнүн иләслеген?

* * *
Ах, Гүзәлем, биетмәче кашларыңны.
Күрмисеңме мәхәббәттән
шашканымны?
Йә, әйт, нишлим?
Кашларыңны канат итеп,
Очып китеп
упкыннарга ташланыйммы?

* * *
Күпме синең карашыңда серлелек,
Самимилек һәм дә әллә кемлелек!
Күзләреңә бер карасам, имәнәм,
Бер карасам, йөрәк тибә сөрлегеп.

* * *
Күзләреңдә яшең мөлдер-
мөлдерәмә –
Тамам, тамам, тамам, диеп
мөлдерәнә.
Кызганам да үзем сине,
сокланам да –
Син гүзәлсең хәтта шушы
хәлеңдә дә.

* * *
Күрегез, күр, атлап түгел,
йөзеп бара.
Сокланулы карашларны сөзеп бара,
Миңа да бер күзен сирпеп
карап алды,
Шул чагында «аһ!» димичә
түзеп кара.

* * *
Йә, нишлибез? Син – түрә,
мин түрә түгел,
Мин – бер гидай,
син үзеңә күрә түгел.
Мин шул инде – җыен юк-бар
сөйләп йөрим,
Ләкин синең дә сүзләрең сүрә түгел.

* * *
Яши-яши, киттем инде картаеп та,
Ара-тирә мәс булдым һәм аек та...
Шуны белдем: әдәбият дәрьясында
Бүре, кәҗә һәм кәбестә бер каекта.

* * *
Алсу, дымсу иреннәрең бөрелгән,
Назлы, татлы сүзләр тама телеңнән...
Бүтәннәрнең барысын да онытып,
Сине генә мактап язам бүгеннән.

* * *
Мичкә – пүлән, самавырга
шакмак кирәк,
Бии-бии җырлар өчен такмак кирәк.
Албастылар, җен-пәриләр
туй иткәндә,
Афәрин дип хуплар өчен
ахмак кирәк.

* * *
Шундый җыр бар: бер битең ал,
бер битең гөл.
Синең менә һәр ягың да
бербөтендер:
Йөзең кара, эчең кара, эшең кара,
Һай-һай, бырат,
яшәүләре бик читендер.

* * *
Туп типкәндә, аяк белән
уйнау яхшы,
«Гол! Гол!» диеп сызгыру һәм
чинау яхшы.
Ни кызганыч, аяк белән
уйлап булмый,
Ни әйтсәң дә, башың белән
уйлау яхшы.

* * *
Акчаң күпме? Юк-юк, әйтмә,
белеп торам.
Күп икәнен белгән килеш
көлеп торам.
Телисеңме, кешеләргә әйтер өчен
Син фәкыйрьгә бер җылы сүз
биреп торам.

* * *
Төшемдә мин таш гасырга
кайтып килдем,
Кыргыйларга шигырьләрем
укып йөрдем.
Шигыреңне ташка уеп яз, диделәр.
Шагыйрьлекнең ни икәнен
шунда белдем.

PRESSA.RU







Рифә РАХМАН

# ТОЛЫМ

(хикәя)

Ания толымнарын үреп күкрәгенә салды да көзгегә якынрак килде. Кашлары калын түгелме, битенә бетчә-мазар чыкмаганмы дип тикшеренүе иде. Юк, барысы да элеккечә. Ания – чибәрнең-чибәре! Ания – гүзәлнең-гүзәле! Мәктәптә «Озын толым» ярышында катнашса, һичшиксез, беренче урын алыр иде дә, әти-әнисе буй-сын, чәч ярышларын өнәми – ата-бабада булган эш түгел, акыл белән ярышырга кирәк ди. Бәлки, дөрес тә уйлыйлардыр. Нәрсәгә әле, шушы чибәрлегеңне кеше бәясенә куеп, үзеңә күз тидерергә?! Ания үз бәясен үзе бик яхшы белә. Белмәс иде, авылның иң булган, иң акыллы егетләре барысы да аның артыннан чаба.

Тозлы Суда никадәр егет булсын, ул егетләр никадәр яхшы булсын, Ания аларның берсенә дә карамаячак! Аларга кызның эшкә уңганлыгы кирәк, авылда калуы кирәк, ә аның шәһәргә китәсе, табибә буласы килә! Ул бу уйны кечкенә чагыннан ук күңеленә беркетте. Шулай бервакыт Ак кәҗәләре абзар ишеген төртеп ачкан да ишегалдына чыккан, барысы да җәйге өйдә чәй эчеп ятканда, өй баскычына тезеп куелган табаклардан карлыганнарны ашый башлаган. Ания күрде дә, йөгереп барып, кәҗә башын тыккан табакны тартып алыйм дигән иде, теге мур кыргыры очлы мөгезе белән кызны бер якка чөеп тә атты! Чөюе бер хәл, иң беренче селтәнүендә кәҗә мөгезе кызның күзләренә кереп киткәндәй булды. Аниянең бите буйлап кан агып төште, бөтен дөнья караңгыланып калгандай булды, куллары, күлмәге канга манчылып бетте.

– Кызны харап итте, – диде әтисе.

– И балакаем, бу җәйге эсседә медпункты да ябык бит аның, – дип чәбәләнде әнисе. – Кайларга гына йөгерим дә, кемнәргә барып егылыйм?!

Ания, гомерлек сукыр калдым, дип уйлап, сыкрап кына еларга тотынды. Әллә ул елаганга, әллә аптыраштан, сөйләшү тукталды. Зур капка күгәннәренең ыңгырашканы ишетелде.

– Әти?! Син мондамы? – дип сорады Ания.

– Монда. Ир башым белән югалып калдым бит, кызым. Әниең, мәтәлә-кадала, Валя апаңнарга йөгерде, мотоциклларында хәзер төшәрбез дә җитәрбез, диде. Борчылма, фельдшер өендәдер, кырга механизаторлар озаткан вакыты түгел, – дип тынычландыра-тынычландыра, әтисе Анияне җайлап утыртты, юеш чүпрәк белән битен, кулларын сөрткәндәй итте.

Абыйсы белән әтисе Ак кәҗәне сүгеп-типкәләп диярлек абзарга илтеп яптылар булса кирәк. Ул тиз генә кире керергә теләмәдеме, кап-кара булып тулышып пешкән карлыганнарның тәмен яхшы татыгач ирәйгән идеме – абзар тирәсендә аның саен: «әйдә-әйдә», «керкер», «нәрсә карап каттың», кебек сүзләр белән кәҗәне куалаганнары ишетелеп торды.

– Кара инде мур кыргырын, нинди акыллы мал да тамак дигәндә аңгырая икән, шулай эшлиләрме соң? Ярар, кызым, түз, түз, хәзер Валя апаң да төшеп җитәр, – дип тынычландырырга тырышты әтисе.
Ания барыбер елавында иде.

Аны бу минутта иң борчыганы – кеше арасына чыгарлык кыяфәтен югалту, гомерлек гариплек... Бар егетне аһ иттергән матурлыгыннан нәрсә кала инде хәзер? Аның артыннан кем йөрер? Кыз һаман шул турыда уйлады.

Әтисе Ания янына килеп утырды:

– Елама инде, кызым, кул-аягың исән-сау, әле күзең дә зыянсыздыр, бар да яхшы гына үтәр.

– Сезгә әйтергә рәхәт, – дип үрсәләнде Ания. – Урамга чыгарлыгым калмаса, бөтен кеше бармак төртеп көлә торган булса?!

– Исәнлегем булсын, диген, кызым, исәнлегем... Яра төзәлер, чибәрлек – уза торган нәрсә...

Кешене эше белән бәяләгән, тышкы матурлыкка исе китмәгән әтисенә сөйләүнең мәгънәсе юк, дип уйлады кыз. Кайчакларда Ания, иркәләнеп, әтисеннән:

– Әтием, мин матурмы? – дип сораштыргалый иде.

– Миңа яшь кызларның барысы да матур, үземнеке булгач, син бигрәк тә, – ди әтисе. – Синең бит толымнарың гына да ни тора! Әниеңнең дә яшь чагында чәчләре калын, озын иде...

Толымнарыңның матурлыгы, имеш. Күзләрең күрмәсә, ул толымнар матурлыгыннан ни нәрсә?! Ул чагында йөз чибәрлеге дә берни түгел! Кайтамы инде әнисе?!

Бәхетенә, фельдшер апа өйдә булып чыккан, шул арада эш урынына төшеп тә җиткән. Ул хәсрәте йөрәгенә ябышкан ананың үзен дә җитәкләп медпунктка алып керде, тынычландырды, дару каптырды, су эчерде дә Аниянең укмашкан кан эчендәге күзләрен чистартырга, шул канны җебетергә тотынды. Күз кабакларының авыртуына чыдарлык булмаса да, Ания түзде, елаудан туктады, фельдшер нинди нәтиҗә чыгарыр дип көтте.

Бераздан, Валя апасы шешенке кабакларын тарткалагандай иткәч, бер күзенә ниндидер яктылык сирпелеп алгандай булды да яңадан юкка чыкты, икенчесе сызык кына ачылды.

– Борчылма, акыллым, мөгез бер күз кабагыңны гына тишкән. Күзеңне кан баскан, син шуңа күрмисең, – диде Валя апасы. – Икенче күзең бераз күгәргән-шешенгән генә, анысы артык яраланмаган да, читкә егылганда берәр нәрсәгә бәрелгәнсеңдер.

Ерактан килеп авылларында калган, татарча да сөйләшергә өйрәнгән Валя апасына Ания гел табибларга караган кебек карады. Бу юлы да йомшак телле, йомшак куллы фельдшерның әйткәненә ышанасы килде.

– Шулаен шулайдыр да, бернәрсә күрми-и-м, Валя апа-а-а... – диде ул, тагын үкси башлап. – Бөтен җире канга тулмагандыр ла ул күзне-е-ең?

– Шулай, дим ич, акыллым, шулай дим ич. Иртәгә, әбәт җитәрәк, медпунктка тагын төшәрмен, тагын чистартырмын. Шунда тәмам ачыкланыр. Кырда эшнең кызган вакыты, машинасын кайдан табасың да кемне районга җибәрәсең? Миңа ышансаң, иртәгәгә кадәр тыныч кына көт.

– Аллага шөкерләр итәрлек эшләр бу. И Ходаем, алга таба рәхмәтеңнән ташлама, – алгы бүлмәдә әнисенең шул рәвешчә өзлексез сөйләнгәне ишетелә иде.

Дарулап чистарткач, җәрәхәткә лейкопластырь ябыштыргач, фельдшер тагын бер кат тынычландырды:

– Күзләреңнең исәнлегенә әллә ышанмыйсың да инде?.. Кабаклары шешкән, шуңа күрә син аларны әле күпмедер ача алмый йөрерсең. Икенчесенә салкын әйберме, суыткычта катырган бозмы куеп торырга кирәк. Бер-ике көннән рәтләнеп китәчәк. Пычрак кертмә, авырта-кычыта дип, кулың белән кагыла күрмә!

Ания атна буе «кәҗәләр батыры» булып йөрде. Кая барса, кем күрсә, аннан шул вакыйга турында сорады. Дөрес, ул урамга артык күп чыгарга тырышмады, сыңар күз белән абынмый йөрүе дә кыен иде. Мәктәптә укулар башланганчы, Ак кәҗә тишкән күз кабагы сәламәтләнде, хәтта җәрәхәте дә бер эз калдырмыйча гына йомылды, алай да иртәнгә эренли иде әле.

Баштарак, әллә кызларын тынычландыру өчен, әллә ихластан: «инде картайды да, сөт тә аз бирә, акылы да киткәнгә охшый, бу елдан калдырмыйбыз», – дигән булсалар да, соңыннан Ак кәҗәне кызгандылар. Әтиәнисе, Аниянең күңелен күрер өченме, кәҗәне орышкандай итсә дә, сакалбай һаман яраткан маллары булып калды. Тора-бара кәҗәгә кызның да үпкәсе узды. Ә менә бер нәрсә нык кереп калды күңеленә.

Әле медпунктның тышкы катындагы утыргычта Аллага шөкерләр укыганда: «Әнисе, әле дә ярый урак вакытында өйдә туры килдең, Валя. Шәһәрдә яшәсәң, ашыгыч ярдәм машинасын гына чакырасы да кана, монда авылда, югалып каласың, кемгә килеп егылырга белмисең», – дип сөйләнгәләгән иде. Шул сүз һич исеннән чыкмады. Инде ул, югары сыйныфларда укыса да, табибә булып уйнавын, курчакларын дәваларга, аларга ак халат, хач төшерелгән яулыклар тегүен ташламады. Әти-әнисе чирләп китсә дә, дару эчерткәләп, температураларын үлчәштергәләп йөргән була иде.

Бала чактан күңеленә узган хыял Аниядә сигезенче сыйныфта укыганда да бетмәде. Тугызынчыга күрше Югары Авылга җәяү йөреп укырга кирәк иде, иң яхшысы хәзер үк Казанга китим дә фельдшерлыкка укыйм, аннан институтка да керүе җиңел булыр дип, ул июль башларында, документларын шунда тапшырып кайтты. Мәктәпне «бишкә» генә бетергән иде, имтиханнар биреп торасы да булмады, шул көнне үк, керде дигән пичәтле кәгазь тотып, әле тагын чакыру килер, монысы болай гына, мәктәп өчен генә, дигән вәгъдәләр алып, авылга кайтып та төште.

PRESSA.RU





Ания артыннан йөргән малайлар арасында күңеленә ятмаган Югары Авыл егете дә бар иде. Буйга тәбәнәк, сүзгә шома бу егет барысыннан да ябышкаграк булып чыкты, кичләрен клубта бер алдына, бер артына төште. Тозлы Суда дуслары күп идеме, әллә барыбер Аниянең аңа карамасын белделәрме, авылның иң чибәр кызы артыннан йөри дип, күрше авыл егетенә бәйләнүче табылмады.

Ания авылдан чыгып китсә, һичберсен ошатмаган егет кисәкләренең, чынлыкта, үзе белән мәктәптә укып йөргән бала-чагаларның да, әле яңа гына хәрби хезмәттән кайтканнарның да барысыннан котылачак иде һәм котылды да шикелле. Бәрәңге алулар тәмамланып, Казанга кайткач, Анияләр төркеменә, яхшы эшләгәнсез, дип, бер-ике көн ял бирделәр. Вакытны әрәм итәсе килмәде, төнгә каршы поездга утырып, ул Тозлы Суга юл тотты.

Менә кузгалам-менә кузгалам дип торган поездның вагонына көчкә эләгеп, бердәнбер буш калган урынга килеп тукталса, каршысында – Габидулла утырып тормасынмы?! Унынчы сыйныфны бу елда тәмамлаган егет Казан авыл хуҗалыгы институтына укырга кергән икән. «Исемнәренә кадәр яратмыйм, үзе кебек иске, борынгы, – дип уйлады кыз. – Озын исемле булганчы, озын буйлы гына булсачы!»

Аниянең болай бер дә кешедән, бигрәк тә иптәшләреннән көлә торган гадәте юк, әмма дә артыннан кайсыдыр озатып кайтса, аны шунда ук алмаштырып куйгандай була. Кызда мыскыллыйсы килү, үртәшү теләге уяна. Ничә еллар дус булып йөргән берәр малай, матур сүзләр сөйләштерә, яратам, ошатам, ди башласа, кыз шунда ук бу «бәхетсезне» дошманнар исемлегенә теркәп тә куя. Егетләрнең читтән гашыйклыгына ирәя үзе. Әмма башкалар кебек ундүрт-унбиш яшьтән үк пар сайларга ашыкмый.

Үртим дисәң, сәбәп тә кирәк түгел, ә табыйм дисәң, табыла. Йә, әйт, бу Габидулладан нинди яманлык күргән инде ул, ә?! Узган ел туган көненә җибәргән бүләген кич клубта үзенә китереп тоттырды. Танцыга чакырырга каршысына килеп баскан иде, икенче берәү белән биим мин, дип, кинәттән торды да китеп барды. Каешлы уенында да каешны Габидуллага шәпләп төшерергә тырышты, җәза сайларга кирәк булганда, ул эшли алмастайны сорады. Сарык тавышлары чыгарып кына җырлый алуын белгәнгә, егет бер-бер уенда отылдымы, әйдә аны җырлатабыз, ул яхшы җырлый, җырласын, җырласын, дип кычкырырга тотына иде.

Габидулла, Ания артыннан чапкан башкалар кебек үк, боларга түзде, дәшмәде, чөнки үлеп гашыйк иде. Бүген дә кызның үз каршысына килеп туктавына, җитмәсә, авыр сумкаларын поездның өске киштәләренә урнаштыруын үтенүенә ул бик нык сөенде. Инде училищеда укып йөргән Ания акылга утыргандыр, үзе белән кешечә сөйләшеп кайтыр дип өметләнде. Чыннан да, кеше арасында сер бирмәде кыз, егетнең әңгәмәләренә катнашып, яңгыратып көлеп, юл буе шаярып-шатланып кайтты.

Радиодан тиздән Кукмарага якынлашканны хәбәр иттеләр. Кондуктор ханым да, билеты шунда алынганнарны бер кат барлап, һәрберсенең исләренә төшереп чыкты.

– Син Кукмарага кайтасыңмыни? – дип сорады, кызның киемнәренә үрелгәнен күргән егет. Алар авылына автобус Нократ Аланы аша йөри иде.

– Әйе шул, соң бит инде, апаларымда кунам. Ә син?

– Минем районда фатир төшәрлек кешем юк. Нократ Аланы вокзалында утырып чыгармын да беренче автобус белән авылга кайтып китәрмен дип уйлаган идем.

– Ә-ә, алай икән. Ярый, хуш.

– Юк инде, кызый, хушлашмый тор, мин төнге белдә Кукмарада үзеңне генә төшереп калдыраммы? Җитмәсә, апаларга барам, дисең. Вокзалда калсаң да, күпме йортсыз-җирсез, эчкече белән төн уздырачаксың. Урам буйлап ялгызыңны ничә чакрым төшермим дә төшермим инде!

– Кем миңа тисен?! Шушының кадәр сумкам барында. Күтәреп алам да тондырам, яныма гына килсеннәр! – дип батырайды Ания.

– Синнән булыр! Тик барыбер ялгызыңны төшермим булгач, төшермим, апаңнарга кадәр озата барам! – дип үз сүзендә торды Габидулла да.

Габидулланың озатырга алынуы бер дә начарга булмады. Урамда бик суык, төннәр салкынайткан, ә Аниянең өстендә бик юка иде. Габидулла аның муенына үзенең җылы шарфын урады. Җитмәсә, сумкалары да авыр. Авылда эшләп үскән Габидуллада көч күп икән: «эһ» тә итми, Аниянең йөген эләктереп алды да үзенеке белән бергә тотып, тиз-тиз атлап та китте.

Кукмараның үзәк урамы озын да соң! Төшә-төшә сөйләргә сүз дә җитмәс кебек тоелган иде, табылды үзе.

– Беләсеңме, мин сиңа ни өчен гашыйк булдым? – дип сорады Габидулла кыздан. – Белмисең шул. Толымнарың өчен! Апам толымнарына охшаган алар. Укырга кергәч, беренче аенда ук кистереп кайтты. Толымын үзенә тоттырып җибәргәннәр. Менә нинди прическалы булдым, дип, шат тавыш белән өйгә килеп кергән иде, соңыннан, кич клубка җыенганда моңсуланды. Чәчен алай тарап карады, болай – җаен тапмады, ошатмады. Аннан трюмо алдында торган толымнарын кулына алды да үкереп елап җибәрде... Синеке кебек үк матур иде апамның толымнары! Сиңдәгедәй бөдрәләнеп торган чигә чәчләре! Ул яңадан озын толым үстермәде... Укырга кердем, дип, кистермә яме, Ания! Үкенергә калмасын! Апа килеп утыргач, чәч кисүче кыз да: «Әллә тимибез генәме соң? Бигрәк калын толымнар бит!» – дип сокланган булган...

Ания чәчен кистерергә уйламый да иде. Теләсә дә, әтисе барыбер рөхсәт итмәячәк аңа. Алар авылында чәче кыска кызлар бер-ике генә. Абыйсы да гел әйтә тора: йөрсәң, озын толымлы кыз белән йөр икән ул!

Чәч кисү уе көтмәгәндә-нитмәгәндә Аниянең башына керде дә утырды: Габидулла үзе дә, гыйбрәтле сүзләре дә онытылды. Иртәгә үк парикмахерга барам, әтиләргә генә шалтыратып әйтәм дә, үзем әтидән шүрләсәм,

җизнәмнән шалтыраттырырмын әле, дип уйлап, кыз ашыгыбрак атлый башлады.

«Хезмәт даны» редакциясенең тоник ут яндырылган тәрәзәләре дә, каршысында гөлт итеп утырган элеватор да, колонналы Мәдәният йорты да артта калды. Озак та үтмәде, алар Почта урамыннан күтәрелеп, апалары яшәгән Эшчеләр тыкрыгына да җиттеләр. Егет авыр сумканы кызга сузды. Капка келәсен күтәреп, тимер тавышы ишетелүгә, йорттан җизнәсе килеп тә чыкты. Ул Анияне шундый сагынган иде, сумкасы-ние белән күтәреп алды да, балдыз-балдызым, дип такмаклый-такмаклый, чоланга узды. Апасы да студентканы сагынып көткән: төн дип тормаган, тәмле аш пешергән, чәен кайнаткан. Ания өстәл артыннан кузгалып киткәндә генә, кинәт Габидулланы исенә төшерде:

– Җизни, мине бер егет озатып кайткан иде, рәхмәт тә әйтмәгәнмен, хушлашмаганмын да...

– Нишләп алай эшләдең инде? Төне дә бик суык. Вокзаллары да ягылмый бит әле аның. Дәшәсең калган үзебезгә. Мин дә соң! Әйтәм җирле, капка төбендә ниндидер егет басып тора иде. Караңгыда сине озата килгән кеше дип уйламадым да, күрше малае дип торам.

Аниягә бик оят булып китте, күзләрен төн буе йокы алмады. Түшәмгә карап уяу килеш ятты. Җизнәсен күрүгә Габидулланы исеннән чыгарган кыз, йокламыйча, бигрәк тә уйда яткач, Габидулла аркасында туган чәч кистерү теләген иртәнгәчә онытмады. Тагын егетләргә усаллыгы, үчлелеге кабынды: әле генә Габидулла каршысында үзен гаепле санаган кыз, болай чәчләремә генә гашыйк булгач, артымнан йөрүдән туктар, кистерәм дә атам, дигән булып ирәйде. Ул бит сиңа гашыйк мин, димәде, чәчләреңне яратам, диде.

Гомер көтмәгән иде, әтисе авырлык белән булса да, ризалык бирде: авылдан икәнлеген күрсәтеп, тасма белән толымнарга үрелгән чәч инде төшкә киселгән, Ания шәһәр чибәркәенә әверелгән иде.


Габидулла бу кайтуында да, аннан соң да Ания янына дип төшмәде, кайчакта Авыл хуҗалыгы институтында укыган студентлар артыннан сәламнәрен генә ирештергәләде.

Шулай бервакыт, әлеге дә баягы Казаннан кайткан чагында, вагонга Арчада бер төркем егетләр килеп керде. Алар да Арчага кадәр пассажир поездында кайтканнар да, хәзер, Ания кебек, өч вагонлы «катык поезды»на күчеп утырганнар икән.

Араларында берсе, егетләрне җырлатып, гармун тартып кайтканы, ял итәргә дип туктагач, Аниягә сүз катты:

– Минем сезне беркайчан да күргәнем юк, әмма нигәдер таныйм шикелле, – диде. – Әһә! Белдем! Сез – Ания! Ә юк. Алай дисәң, толымнарыгыз озын булырга тиеш. Габидулла шулай дип сөйләгән иде... Ә менә күзләрегез, буй-сыныгыз, бигрәк тә чыңлап торган матур тавышыгыз нәкъ ул тасвирлаганча! Әллә сез Аниянең бер-бер туганымы? Плащыгызга кадәр – Аниянеке!

– Шулайдыр инде... – дип көлгәндәй итте кыз, эченнән моңа бик аптырап. Аннан исенә төште: көзен,



Рәсем: Наталья Васильева

PRESSA.RU





Габидулла аны апаларына озата барганда, ул шушы плащтан иде. Хәзер менә матур яз ае. Ул тагын шул ук плащка күчкән! Муенында Габидулла бүләк иткән мохер шарфы гына юк!

– Дустыгызның сөйләве буенча да кешене таныгач, сез тикшерүчегә укыйсыз мәллә? – дип төрттерде кыз. – Шерлок Холмс, хи-хи...

– Юк. Авыл хуҗалыгы институтында. Габидулла белән бер төркемдә. Ничек танымаска, ул кыш буе сезнең хакта гына сөйләгәч. Инде менә үзем дә аның кебек сезне сөйләп аңгыраермын шикелле. Тәбрис абыеңны онытып бетермә, үскәнем! Без синең кебек Нократ Аланында төшмибез, тагын да ерагракка китәбез! Әмма бер сезнең якларга барып чыгам әле мин!

Егетләр, тәмәке тартып кергәч, тагын җырлашып-уйнашып бардылар, әмма Тәбриснең күзе хәзер гел кызда иде. Ания үз станциясендә төшеп калды, Тәбрис аны тамбурга кадәр чыгарды да артыннан:

– Чистай мишәре булам мин, адресыңны да бирмәдең, Казанда таба алмасам, барыбер бер авылыгызга килеп чыгам! – дип кычкырып калган булды.

Тәбрис кызга ошады, чөнки үтә чибәр иде. Андый егетләрнең кызлары күп була аның, дип уйлады Ания, һәм үз-үзенә Тәбрис турында башына уй кертмәскә сүз бирде. Поездда очраткан кешегә ышансаң... Җитмәсә, җырлый... Гармунда уйный... Андый егетләр авылда да үз дәрәҗәләрен белеп кенә кыз сайлый... Таба да ташлый, таба да ташлый... Гармунчыга кызлар белән йөрү яңа көй өйрәнү кебек кенә ул. Отып шомартса, икенчесен өйрәнәсе килә...

Вакытлар узгач, Тәбрис белән алар әле тагын шул ук «катык поезды»нда очраштылар. Аниянең инде йөргән егете бар иде, ул күңелен яңадан кузгатып җибәрмәскә тырышты. Әллә ни сөйләшер сүзләр табылмады, чөнки кирәгә ук, Анияне сискәндереп, Тәбрис Габидулланың вафат булганлыгын әйтте.

Сүз ялганмады да ялганмады. Күбрәк Тәбрис сөйләде. Туктап-көтеп торганнан соң, әле бу теманы, әле икенчесен башлап карады – Ания кушылмады. Егет Габидулла турында сүзгә әйләнде дә кайтты, әйләнде дә кайтты:

– Син дип өйләнмәде дә инде Габидулла. Яныңа яңадан барып чыгарга йөрәге җитмәде үзенең. Мин дә ахмак, толымнарыңны кисеп атканыңны әйтеп ташладым... Ул бик яраткач, дустыма хыянәт итмим дип, үзем дә сине эзләп табасы итмәдем. Юкса... үлеп гашыйк булган идем, Ания!

Уфылдаулы, ухылдаулы сөйләшү булып истә калды Тәбрис белән соңгы очрашу Ания күңелендә. Нәрсә генә сөйләсәң дә, тыңласаң да, барыбер сүз сүз инде ул, кылган гамәлләрең булмагач... Егет кабат шулай әллә нишләтеп җибәрер дип һич тә уйламаган иде Ания...

Поезддан төшеп барганда, Тәбрис, кыз белән һич югы битләреннән үбеп, кочагына алып хушлашасы урынга:

– Син толымнарыңны яңадан үстермәгәнсең икән. Кызганыч, – дип, тамбур стенасына сөялгән килеш кенә, күзләрен тутырып моңсу карап торды. – Габидулла гел шулар турында сөйли иде. Шулар турында сөйли иде дә апасын искә ала иде...

Ания, кушылып, бу юлы да бер сүз әйтмәде. Бу турыда сөйләшү өзелгәнгә сөенеп, поезд туктаганчы ук, ишекне ачып, перронга сикереп төште. Борылып кул да болгамады, автобус тукталышына йөгерде.

Бу вакыйгалар тора-бара бөтенләй онытылган булыр иде. Көннәрнең берендә Ания үзе эшләп йөргән шифаханәдә бер егет белән таныштЫ. Буй-сынын әйтәсеңме, матур итеп таралган чәчләренме, затлы күлмәк-галстукларынмы... – барысы да урынында, барысы да килешле. Егетнең дә егете инде менә!

Ания аны бер күрүдә ошатты. Алар төшке ашны ашарга – ашханәгә, сирәк булса да киноларга бергәләп йөри башладылар. Шулай бервакыт Морис, утлар сүндерелгәнне, фильм башланганны көтеп утырганда, кесәсеннән ниндидер гәҗит кисәге тартып чыгарды да андагы рәсемне Ания белән чагыштырырга тотынды.

– Син дисәм, толымнарың юк. Элегрәк шушы рәсемгә гашыйк булгач, газетадан кисеп алып, костюмымның түш кесәсенә тыккан идем, кем белән танышсам да, гел шундагы рәсем белән чагыштырам. Андагы кызга охшаган кешегә генә өйләнәм дип сүз бирдем.

Ания аптырады. Чәчне үстереп була, мин үзем дә сиңа гашыйк, дип әйтмәде. Ул Морисның үтенүен көтте, ул егетнең тагын да матуррак сүзләр сөйләгәнен көтте...

Морис белән алар аннан соң да очраштыргаладылар, әмма аралашулары ни сәбәпледер дуслыктан ерак китмәде. Дуслар булып кына калсалар да, Ания күңелендә егеткә карата мәхәббәт хисләре бөреләнгән иде шул. Көннәрнең берендә Морис аның бүлмәсенә икенче бер фото тотып керде:

– Ания, теге рәсемдәге кызны таптым бит мин тәки!

Тышлары саргаеп беткән «Идел» альманахында Аниянең яшьлек рәсеме иде. Аның шигырьләре белән чыккан номерны Мориска дусты биргән икән.

– Әйбәт булган, – диде Ания боек кына. – Инде кешесен генә табасың калган.

– Шигыре дә булгач, исеме дә булгач, тапмыйммы соң?!

Яшьлек әсәрләрен Ания бөтенләй ят исем астында бастырган, ә хәзер шигырь язудан да туктаган иде.

– Бу рәсемдә мәктәп баласы лабаса! – диде кыз. – Син аны күрсәң дә танымаячаксың!

– Булмагае! Ничек танымыйм, ди?! Бу шомырт күзләрнеме?! Бу чигә бөдрәләренме?! Әйе, ул үскәндер! Институт бетергәндер! Синең кебек бер-бер җирдә эшләп йөридер! Бүген үк минеке булыр димим ич! Табам дигәч, барыбер табам инде мин аны!

Ания моңсуланды. Күңел күзең күрмәсә, маңгай күзең бернигә дә тормый шул. Анияне ярата алырлык булса, бу хәлләрнең асылын аңламас идемени Морис?! Икенче көнне Ания эштән китәргә гариза бирде.

Шул толымнар аркасында ул икенче тапкыр күзе төшкән егетне югалтты... Горурлыкны җиңеп, үзенең рәсемдәге кыз икәнлеген әйтергә дә булгандыр югыйсә... Аниянең бөтен матурлыгы толымда гына идемени соң?!



## «АЛЛАНЫ БЕР ДИП БЕЛСӘҢ...» – КЕМГӘДЕР ГОЗЕРЛӘНЕП МӨРӘҖӘГАТЬ ИТКӘНДӘ ЕШ КЫНА СҮЗНЕ ШУННАН – АЛЛА СҮЗЕННӘН БАШЛЫЙЛАР...

Асия
ЮНЫСОВА

# АЛЛА – БЕР УЛ!

«Алла – бер ул!» Бу җөмләне исә үзләрен аклар яисә гамәлләренең хаклыгына ышандырыр өчен әйтәләр бугай. Әйе, күп вакыт безгә Күкләр шаһитлыгы да кирәк.

Табиб килгәнне көтеп утырабыз. Чиратта без икәү генә. Төрлесен сөйләшәбез. Шунда ничектер сүз чәч кистерү темасына килеп чыкты. «Чәчемне кистереп кенә ташлар идем, безнең динебез кушмый», – диде әңгәмәдәшем. Русча гәпләшә башлаган идек. Милләтен белмим әле. Алай да татар булырга тиеш дип уйлыйм. «Ислам динендә чәч кистерүгә карата ниндидер тыю бармыни?» – дип сорап куйдым. «Ислам динендә түгел, безнең диндә». Минем аптыраулы карашымны тотып алып: «Христиан динендә мин», – дип өстәде. «Ирегез урыс кешесеме, әллә үзегез керәшенме? – дип, иплә кенә сораштырам. Бөтен килеш-килбәте, башындагы ак яулыгы белән үзебезнең кешегә охшап торган хатынның христиан динендә булуын ничектер кабул итә алмый утырам.

Югары математик белемгә ия бу хатын элек институтта компьютерлар белән эшләгән икән. Анысын да сөйләштек. Димәк, чи надан бер кеше түгел. Ул минем күңелемнән җавап эзләп утыруымны чамалап, миңа ярдәм итәргә булды: «Тормышта бик авыр хәлдә калдым мин. Әллә психикам какшаган иде, әллә чыннан да бер-бер шаукым булды. Миңа өйдә кемдер бар кебек тоела башлады. Ялгыз калырга куркам. Шуннан әллә өйдә азан әйттереп карыйм микән дигән уй башыма керде. Дөрес



сизендегез. Мин керәшен түгел, ирем дә мөселман кешесе иде. Тик аны кинәт кенә югалттым. Балам булмады. Көтмәгәндә тома ялгыз калу мине таянычсыз итте дә инде. Ниятемне башкару уе белән мәчеткә киттем. Мулла минем белән сөйләшеп тә тормады. Икенче мәчеткә бардым, өченчесенә... Каңгырып йөрдем шулай. Өйгә килеп азан әйтергә риза үзләре, тик әйбәт кенә аш табыны, шәп кенә гонорар (сәдака) кирәк булырын аңлаталар. Өйдән җеннәр качыру бәя тора икән. Ә минем бик тә бетеренгән чагым иде. Шунда миңа бер абыстай киңәш бирде: «Чиркәүгә барып кара син. Җен кудыру эшләрен алар әйбәт башкаралар», – диде. Бардым. Батюшка минем белән шундый ипле, шундый җайлы сөйләште. Аның яныннан тынычланып кайтып киттем. Өйгә килеп ырымнарын башкардылар. Әҗер өчен бер йомырка бирсәң дә җитә, диделәр. Шуннан соң, җаным уйнаган саен, чиркәүгә бара торган булып киттем. Аннары үзем теләп христиан динен кабул иттем. Боженькамны бик яратам мин. Елга бер тапкыр Эстониядәге монастырьда ял итеп кайтам. Рәхәт була миңа анда. Алла бер лә инде ул».

«Алай икән, – дидем. – Әниең, әбиең ни дигән булырлар иде икән синең бу гамәлеңә? Үлгәч, кайсы зиратка ятарга уйлыйсың?» – дип тә өстәдем. Соңгы соравым бераз каушатты кебек аны.

Инде бу сөйләшү онытыла төшкән иде. Телевизордан Алсу Сафинаның катнаш никахларга карата мөнәсәбәте хакындагы фикерләрен тыңлагач, тагын борчылып куйдым. Нигә соң без татарлар дин кебек изге нәрсәдә дә умырткасыз соң? Менә ун ел инде Алсу никахында бик бәхетле икән. Аның яһүд ире – Ян Абрамов кызның кулын сорарга килгәч, татарча җөмлә әйтеп, татар гаиләсенең ихтирамын, ышанычын казана алган, үзен яраттырган. Алсу үзе: «Мин мөселманмын, мөселман тәрбиясе алдым, – дип өздереп әйтте дә, – ә минем балаларым әтиләре динендә булырлар. Без бит, татар хатын-кызлары, ирләребездән узмаска тиеш», – диебрәк өстәп куйды.

Хуп, мөселман диненә тугры калган өчен дә рәхмәт аңа. Тик нигә ул хәзердән үк кызлары өчен хәл итеп куйган? Израильдә түгел бит яшәүләре. Хәер, анда баланың милләтен анасыныкы белән теркиләр. Мөгаен, динен дәдер. Аннан бит әле тагын вөҗдан ирекенә дигән төшенчә бар. Алла бер дә ул, дин башка! Шул динне тоткан милләт башка!

PRESSA.RU



МӘДИНӘ МАЛИКОВА... КҮРЕНЕКЛЕ ЯЗУЧЫ. РОМАННАР ОСТАСЫ. ЖУРНАЛИСТ. ҖӘМӘГАТЬ ЭШЛЕКЛЕСЕ. ҺӘМ, ӘЛБӘТТӘ, НЕЧКӘ ТОЕМЛЫ, ЗИРӘК АКЫЛЛЫ, ЙӨГЕРЕК ФИКЕРЛЕ БУЛГАН ХАТЫН-КЫЗ. БҮГЕН АҢА – 80! ҮЗЕ ҺАМАН ЯШЬ, МАТУР, ЕГӘРЛЕ. СОКЛАНАБЫЗ. ЯРАТАБЫЗ. КОТЛЫЙБЫЗ!

Мәдинә
МАЛИКОВА

# «ЯШЬЛЕК МИҢА ӨЧ МӘРТӘБӘ КИЛДЕ»






дәм баласының күңеле канатлы, гомер юлы исә сикәлтәле-кантарлы. Күкләргә күтәрелгәндәй очынган вакытлар да, абынып егылып борынны канаткан чаклар да була. Бик бәхетле дип саналган кешеләрнең дә гомере тоташ шатлык-сөенечләргә генә уралып узмый.

Тормышта нәрсә күбрәк: сөенечләреме, көенечләреме?.. Бу, әлбәттә, тәкъдиреңә ни язылган булуга бәйледер. Әмма кешенең үзеннән дә күп нәрсә тора. Иң беренче чиратта, аның яшьлегендә дөрес юл сайлавына бәйледер бу. Нинди эшкә аеруча сәләтле икәнеңне аңлап, күңелеңә ятышлы һөнәр сайлап алу мөһим.

– Тәпи йөри башлаганчы ук телең =ачылды, – дигән иде миңа әнкәем. – Сәке түрендә бертуктаусыз тәтелдәп утыра идең.

Киләчәктә тел тегермәне тартып тамак туйдырачагым шул чагымнан ук беленгәндер, күрәсең. Әмма мин әдәбиятка шактый соңарып килдем. Ник алай булгандыр, үзем дә аңламыйм. Башлангыч классларда ук шигырьләр язып, аларны сәхнәдән укый идем, мәктәпнең стена газетасын чыгаруда башлап йөри идем югыйсә. Хәтта пьеса да язып карадым.

Педагогия училищесында, институтта укыганда музыка коралларында – скрипкада, мандолинада, пианинода, аккордеонда уйнарга өйрәндем. Кичәләр үткәргәндә бик актив булдым, спектакльләр куйганда катнаштым. Парашюттан сикерү түгәрәгенә йөрдем, хәтта бер тапкыр сикердем дә. Шахмат уйнарга ярата идем, институтның чемпионы булдым.

Редакциягә юлны Казан педагогика институтының өченче курсында укыганда гына таптым. «Яшь сталинчы» газетасында беренче мәкаләм басылып чыкканнан соң мин инде Матбугат йортына эземне суытмадым. Диплом алгач, «Чаян» журналында биш ел корректор булып эшләдем, аннары мине «Азат хатын» журналына әдәби хезмәткәр итеп эшкә чакырдылар.

Язу сәләтенә ия булган татар хатын-кызы өчен моннан да яхшы урын дөньяда юк. Газеталарда, нәшриятта эш тыгыз, журнал исә айга бер генә чыга, язар алдыннан ныклап фикер тупларга, язганыңны кат-кат төзәтергә вакыт бар. Без анда дүрт иҗади хезмәткәр идек: җаваплы секретарь Марс Шабаев (соңрак аның урынына Габдулла Шәрәфетдинов килде) һәм өч хатын-кыз: Диләра Зөбәерова, Кояш Тимбикова һәм мин. Бауман урамындагы атаклы Матбугат йортының икенче катындагы ике бүлмәдә утырабыз, Язучылар берлеге идарәсенә юл безнең турдан уза. Ишегебез гадәттә ачык тора, идарәгә килгән-киткән олы язучылар тукталып сәлам бирәләр, күп очракта кереп, сөйләшеп утыралар. Ниләр язуыбыз белән кызыксыналар, кулъязмаларыбызны бик теләп укырга алыналар, фикерләрен әйтәләр.

Әдәбиятта беренче адымнарын атларга омтылган яшь каләм иясе өчен бик зур мәктәп иде бу!

Беренче елларны күләмле әдәби әсәрләр язу турында хыялланырга батырчылык итми идем әле. Бу хакта миңа редакторыбыз Асия Фәридовна Хәсәнова әйтте: «Мин сине язучы булырсың дип уйлыйм», – диде.

Ул безнең редакциянең Язучылар берлеге белән бер партия оешмасында торуына да ирешә. Тукай исемендәге клубта уза торган җыелышларда исемнәре мәктәп дәреслекләреннән укып күңелгә сеңеп калган шәхесләр белән янәшә утыра, трибунадан чыгышлар ясый идек.

Журнал Татарстанныкы гына булып саналса да, Асия Фәридовна аны дөнья мәйданына чыгаруны максат итеп куйды. Һәм без моңа ирештек тә. Ул дүрт йөз мең данә тираж белән басылып чыга һәм татарлар яши торган һәр төбәккә барып җитә иде. Татарлар зур тарихлы, дәүләтле, уңган, батыр, акыллы, дус халык – без менә шушы хакыйкатьне укучыларыбызга сеңдерү өчен тырыштык. Чын күңелемнән ышанам: ул елларда бу журнал милләтебезне туплауга зур өлеш кертте.

Ул чакта әле интернет юк, телевидение яралып кына килә, радионың да радиусы бәләкәй. Мондый шартларда җырчыларыбызның, артистларыбызның фидакарь хезмәте бәяләп бетергесез булды, әлбәттә. Әмма алар да ерак төбәкләргә теләгәнчә еш бара алмыйлар иде.

*Ибраһим Гази, Атилла Расих, Мирсәй Әмир, Аяз Гыйләҗев, Гариф Ахунов биргән киңәшләрне һаман исемдә тотам.*

Журнал исә ай саен килә! Милләттәшләребезгә тарихи ватаннан яңа хәбәрләр китерә. Иң сөенечлесе: яңа җырларның сүзләрен генә түгел, ноталарын алып килә. Татар өчен милли җыр-моң туган тел белән янәшә йөри бит ул. Милләттәшләр төрле кыйтгаларда концертлар куйганда яңа җырларны безнең журналдан алалар. Калфаклы сандугачыбыз Сара апа Садыйкованың гына да күпме җырлары халкыбызга нәкъ менә безнең журнал аша барып ирешә!

Милләтебезнең йөзен билгели торган һәммә сыйфатлары турында мәгълүмат бирелә иде журналда.

Халкыбызның каймагы – күренекле шәхесләре турында да... Дан казанган батырлар, зур ачышлар ясаган галимнәр, табиблар, әсәрләре халыкның мәхәббәтен казанган язучылар, композиторлар, рәссамнар, танылган артистлар. Күпме яшь талантлар беренче булып безнең журнал аша танылды!

Хәзерге белән чагыштырганда юка гына иде журналыбыз, сары гәзит кәгазендә басыла иде. Әмма йөз меңнәрчә укучыларыбыз өчен җан азыгы иде ул.

Фән докторлары исеменә лаек булган татар хатын-кызларын барладык, күбесе белән тыгыз элемтә урнаштырдык. Минем үзем өчен арадан берсе – медицина фәннәре докторы, профессор Зәйнәп Нәҗип кызы Якубова бик якын кешегә әверелде. Үз өлкәсендә исеме бөтен СССРга гына түгел, хәтта чит илләргә дә мәгълүм шәхес иде ул. Совет хатын-кызлары комитеты әгъзасы. Аның янында мин үземне бик кечкенә кебек хис итә

PRESSA.RU



идем. Ә ул мине үзенә тиң күргәндәй сөйләшә! Берзаман аның хакында «Советская женщина» журналында мәкалә чыгарырга планлаштырдылар. Аны Мәскәүнең үзеннән килгән журналист язды. Аның язганнарын танышу өчен алдан Зәйнәп апага җибәргәннәр, ул исә укып чыккан да, редакторга: «Бу язма миңа ошамады, минем хакта Мәдинә Маликова язсын», – дип хат җибәргән. Аның теләген үтәмәделәр, әлбәттә, әмма минем өчен бу сүз орден алганнан дәрәҗәлерәк тоелды.

– Мәдинә, роман яз син, вакыйгаларын мин сөйләрмен, – диде ул берзаман. Мием түнеп китте дисәм дә, арттыру булмастыр. Чөнки хикәяләрем, повестьларым басылып килсә дә, роман язу турында хыялланмый идем.

Эшкә тотындык без. Әледән-әле очрашабыз, ул сөйли, мин күңелемә сеңдереп барам...

Роман 1983 елда «Казан утлары» журналында «Ак давылда тал бөресе» дигән исем астында, бер елдан соң «Шәфкать» исеме белән китап булып басылып чыкты. Аның татар телендә хатын-кыз язучы язган беренче роман икәнлеген мин соңрак кына белдем.

*Әдәби иҗат өлкәсендә дә елдан-ел үсә килдем кебек. Әледән-әле күләмле әсәрләрем чыгып тора, пьесаларым театр сәхнәләрендә уйнала.*

Бу хәл мине тирән уйга да салды. Ничек инде ул алай? Халкыбызда талантлы кызларга беркайчан да кытлык булмаган бит! Минем әнкәем, мәсәлән, шигырь чыгарырга ифрат оста иде. Хәзерге вакытта яшь талантларны барлаганда кызларның күплеге күзгә ташлана. Ни сәбәптән моңарчы бер татар хатын-кызы да күләмле әсәр язарга алынмаган?

Шушы сорауга җавап эзләп, мин үткәннәргә борылып карадым, әби-әниләребезнең яшәешен күзалларга тырыштым. Совет власте хатын-кызларны ирләр белән тигез хокуклы дип игълан иткән итүен. Әмма табигатьнең үз законнары, хөкүмәт куша дип кенә алар үзгәрми. Сәламәт хатын ел аралаш буйга уза. Бездән алдагы чорларда йөклелектән саклану-котылу чаралары булмаган. Хатын кеше гомере буе йә көмәнле йөргән, йә бала имезгән. Балаларының күбесе үлгән. Андый ананы ир-ат белән бертигез санап буламыни?

Бервакыт мин Әмирхан абый Еникидән: «Яшь талантларның күпчелеге кызлар, ә язучылар берлегендә алар уннан бер генә. Нишләп алай икән?» – дип сораган идем. «Кияүгә чыгалар да югалалар», – дип җавап бирде ул. Тәнкыйтьче Фәрваз Миңнуллин «Кояш күпере» исемле повестемны укып чыккач: «Хатын-кызга яшәү, ир-ат белән чагыштырганда, күпкә катлаулырак икән», – дигән иде. Аңарчы ул бу хакта уйлап та карамаган!

Хәер, ирләрнең кайсы гына моны уйлап баш катыра икән? Күңеле белән ул үзенең хатын-кыздан өстенлеген һәрдаим тоеп яши. Табигать аның буен озынрак, беләген көчлерәк итеп яраткан. Әмма акыл, зиһен үткенлеге, хисләр тирәнлеге һәм кайнарлыгы ягыннан аларның хатын-кыздан өстенлеге исбат ителмәгән әле.

Зәйнәп Якубова кебек талантлы, киң карашлы табибларның тырышлыгы белән безнең буынга баланы тансык булганда гына табарга һәм сәламәт үстерергә, нәтиҗәдә хатын-кызларга үз талантларын ачарга мөмкинлек туды. Бәхетемә, минем гомер шушы чорга туры килде. Менә нилектән «Шәфкать» – хатын-кыз каләме белән иҗат ителгән беренче роман булган да!

«Азат хатын» журналы хатын-кызларның иҗатта ирләрдән һич тә калышмаганын исбат итте. Без һәммәсеннән уздырдык – тиражыбыз татар матбугатында иң зурысы иде. Хезмәтебез югары бәяләнде дә: миңа, башка каләмдәшләрем белән беррәттән, журналистларның Хөсәен Ямашев исемендәге бүләге, Татарстанның һәм Россиянең атказанган мәдәният хезмәткәре дигән мактаулы исемнәр бирелде.

Гомеремнең чәчәк атып, җимешләнгән чоры журналның иң данлы чагына туры килде. Хәзер инде ул вакытларда бергә эшләгән язучылардан бер мин генә исән калдым. Хезмәттәшләремнең арабыздан киткәненә шактый еллар узды – урыннары җәннәттә булсын.

...Журналда мин егерме өч ел эшләдем.

Килде бер көн, яраткан эшемнән китәргә мәҗбүр булдым. Кудылар дип әйтә алмыйм, әмма нык гарьләндерделәр. Матбугат белән җитәкчелек итүче бер яшь кеше: «Хатын-кыз коллективын кулда тоту өчен ир кеше кирәк!» – дип йөземә бәреп әйтте. Әгәр минем урында ир кеше булса, аны Язучылар берлеге яклап чыккан булыр иде. Ләкин анда да миңа шул ук сүзләрне кабатладылар: хатын-кызлар белән ир кеше җитәкчелек итәргә тиеш. Кайсы яхшы эш урынына сайлаганда, син ир затыннан, шуңа күрә эшкә алмыйбыз, дип әйтәләр икән?

Пенсия яшем дә җитмәгән килеш, мин өйгә кайтып утырдым. Күп тә үтмәде, илдә зур үзгәрешләр башланды, авыр еллар килде, әдәби әсәрләр язып тамак туйдыру мөмкинлеге бетте. Өлкән каләмдәшләрем мисалында күреп тора идем: иҗади байлыклары арткан саен, аларның абруе да югарырак күтәрелә, әдәби бүләкләре, язучы буларак мактаулы исемнәре арта. Мин исә бу яктан караганда буш кул калганмын булып чыкты. Киресенчә, китте чигенү, артка тәгәрәү: Язучылар берлегендә идарә әгъзасы идем, аннан төшеп калдым. Әдәби журналның редакция әгъзасы идем – аннан сыздылар. Проза секциясенең җитәкчесе идем – үземә әйтеп тә тормыйча гына урыныма башка берәүне – билгеле инде ирләр затыннан – куйдылар.

Мин боларны бик авыр кичердем. Яшем өлкәнәеп килгәндә, яшьлегемдәге кебек юллар чатына чыгып баскан кебек тойдым үземне...

...Анда-монда сугылганнан соң, күңелемә ятышлы яңа шөгыль таптым – «Бөтентатар Кызыл Ай җәмгыяте» оештырдым. «Шәфкать» исемле роман язган кеше бит мин – нигә әле мохтаҗларга ярдәм итү белән шөгыльләнмәскә! Моның өчен хезмәткәрләр ялларга, транспорт булдырырга туры килде. Төрле курсларда укыдым,

машиналар белән йөк ташу буенча диспетчер дипломы, шоферларның юлламасына медицина тамгасы куярга хокуклы шәфкать туташы таныкнамәсе алдым. Һәм яшьләр белән беррәттән җигелеп эшкә керештем.

Авыр елларда оешма аша меңнәрчә мескен-фәкыйрьләргә ярдәм күрсәттек. Хөкүмәт безгә акча бирми иде, без хәллеләрдән сорап алып, хәлсезләргә өләштек. Яхшы кешеләрнең күплеге хәйран калырлык иде. Чечняда сугыш барганда өч тапкыр халыктан җыелган ярдәмне зур-зур фураларга төяп, гуманитар колонналар җитәкләп, Татарстан байракларын һәм Кызыл Ай флагларын җилфердәтеп, меңнәрчә чакрым юл үттек...

Безгә кадәр дә, бездән соң да җөмһүриятебездән дөньяның төрле кыйтгаларында фаҗигагә юлыккан халыкларга күп-күп ярдәм җибәрелә. Алар Россия дәүләте исеменнән, Кызыл Хач байрагы астында илтеп тапшырыла. Үз республикабыз исеменнән, милли-дини йөзебезне билгеләгән Кызыл Ай байрагы астында, уннарча фуралар тезелеп, кайчан да булса тагын шундый озын юллар үтә алырлар микән? Без, башка халыкларга ярдәм кулы сузу белән бергә, үз халкыбызның зурлыгын, игелеклелеген күрсәтү өчен дә тырыштык.

Шунысы уйга сала: нишләп безнең гайрәтле ир-егетләребез, хәләл көч белән тапкан малларын гуманитар колонналарга төяп, башка халык исеменнән, ят байрак астында озата икән? Без, хатын-кызлар, игелекне үз халкыбыз исеменнән эшләп булганны исбатладык бит инде!

Бу оешмада мин бик зур тормыш мәктәбе үттем. Һәм киләчәктә язачак әсәрләрем өчен мая тупладым.

Шөкер, илдә сугыш тынды, халыкның хәле яхшырды. Шушы минутта ярдәм өмет итеп бусагабызны атлап кергән ач-ялангачлар күренми башлады.

Миңа гомеремдә өченче тапкыр үземә яңа юл табарга һәм аннан яшьләр белән беррәттән атларга кирәк булды. Хәер, элекке һөнәремә кире кайттым, дисәм дә ярар иде. Коралым шул бер каләм бит. Әмма журналда эшләгәндә баш очымда юл күрсәтүче, киңәш бирүче, эш белән тәэмин итүче һәм хезмәтем өчен әҗерен түләүче бар иде. Хәзер андый ышык-канат юк.

Хәзерге көндә китап кибетләренең киштәләрендә сигез исемдәге китабым тезелеп тора: алар тузан җыеп ятмый, сатылалар. Мин аларны кемнәрдәндер матди ярдәм сорап алып түгел, үз хисабыма бастырып чыгарам. Ел саен берне, ә кайчакта икене дә. Алар үз-үзләрен аклап кына калмый, каләм хакы да китерә. Күпләр акча юклыктан, чыккан китапларның сатылмавыннан зарлана. Татар китап укудан бизде, дигән сүзләрне еш ишетергә туры килә. Бу нахак сүз. Әдәбият сөючеләрнең яңадан-яңа буыннары үсеп тора, матур әдәбиятка, кызык китапка ихтыяҗ зур. Матур, кызык кына булсын, яз да яз!

Һәм мин укучыларымның күңеленә хуш килерлек әсәрләр иҗат итәргә тырышам. Күпләрдән: «Сезнең китапларны укып үстек!» – дигән сүзләрне ишеткәнем бар. Беренче итеп, гадәттә, «Шәфкать» романын телгә алалар, ул мәктәп һәм медицина көллиятләре программаларына кертелгән. Иң куандырганы: аны кибетләрдән хәләл акчаларына сатып алучылар хәзер дә бар.

Гомер уза тора, китапларны язу гына түгел, сату белән шөгыльләнә башлавыма да унбиш ел тула икән. Үзенә күрә бер юбилей. Шуңа өстәп, үземнең дә юбилеем якынлашып килә – сиксән яшемне тутырам. Үткәннәргә борылып карап, баштан узганнарны күз алдыннан уздырам, эшләгән эшләремне барлыйм. Мондый очракта иң беренче итеп гаиләңне уйлыйсың, билгеле. Ул яктан зарланырлык түгел: ирем – шагыйрь Әхмәт Рәшитов белән тигез картаябыз, ике ул үстердек, алар инде шактыйдан үзбаш яшиләр. Иҗади байлыгым турында кыскача шуны әйтергә була: тугыз романым, шактый санда повесть-хикәяләрем басылып чыккан икән. Егерме сигез китабым (дүртесе Мәскәүдә рус телендә) нәшер ителгән, биш пьесам театрларда куелган, «Сөембикә» исемлесе Тинчурин театрында хәзер дә уйнала.

Әдәби әсәрләрнең гомере озын. Китапханәләрдә китаплар озак еллар саклана, аларны яңадан-яңа укучылар алып укый. Язучы өчен зур куаныч бу. Иҗатым үз бәясен алды, дип санарга була. Тик кайсы яктан карыйсың бит... Яхшы язучыларның әсәрләре укучылар тарафыннан гына түгел, рәсми яктан да бәяләнә. Бу нисбәттән исә бер дә мактанырлыгым юк икән бит.

*Заманча әйткәндә, мине күпмедер дәрәҗәдә бизнес-вумен дип атарга да буладыр. Чөнки һәммәсенә берүзем: язучы да, нәшир дә, сатучы да.*

...Бер төркем язучылар авылларда укучыларыбыз белән очрашулар үткәреп йөри идек. Арада мин иң өлкәне. Җитәкчебез аерым-аерым сүз биргәндә һәр язучының исем-фамилиясен, нинди әдәби премиягә лаек булганын әйтә. Чират миңа җиткәч кенә, аның авызыннан нибары өч сүз чыга: «Мәдинә Маликова, язучы». Кырык өч ел элек бирелгән «Язучылар берлеге әгъзасы» дигән таныкнамәдән бүтән берминди әдәби бүләгем дә юк икән бит минем!

Моннан дүрт ел элек «Татарстан язучылары – әдәби премия лауреатлары» исемле саллы китап басылып чыкты. Анда 173 язучы турында мәгълүмат бирелгән. Бу исемлектә мин юк.

Сорамагансыңдыр, диючеләр булыр. Сорап та карадым, әмма һәр очракта берәр ир-егет миннән лаеграк дип табылды.

Журнал – вакытлы матбугат. «Азат хатын» да үз чорында калды, хәзерге яшьләрнең күпчелеге анда басылып чыккан, күп меңнәрнең күңелен кузгаткан язмалар турында белми, минем дә аның битләрендә урын алган мәкалә-очеркларым онытылды инде.

Ә менә андагы хезмәтләрем өчен бирелгән мактаулы исемнәр, журналистларның иң зур бүләк-премиясе калды, алар укучыларым алдында абруемны нык күтәрә.

Ни бәхет – хезмәт юлымны мин «Азат хатын» журналында башладым, шунда үстем, чыныгу алдым!

PRESSA.RU





# МӘСКӘҮДӘ ТУГАН ҖЫР

Шагыйрь Разил Вәлиев үзенең йөзләгән җырлары арасыннан берсен сайлап, аның язылу тарихын тәфсилләп сөйләргә вәгъдә биргән иде. Әмма ул, кайсы җырына тукталырга белмичә, икеләнеп калды. Без аңа соңгы елларда аеруча популяр булган «Зинһар өчен, кермә төшләремә» җырын тәкъдим итеп карадык. «Әйе, ул җыр да бик гыйбрәтле язмышка ия, – диде шагыйрь. – Әлеге җыр мине хәтта кулымнан җитәкләп Бишкәк каласына кадәр алып барды. Кыргызстан җитәкчесенең хәләл җефете, милләттәшебез Рәйсә ханымның, Кыргызстан татарларының да яраткан җыры булып чыкты ул. Көннәрдән бер көнне мине, әлеге «Зинһар өчен, кермә төшләремә» җыры авторын, Бишкәк каласындагы Чыңгыз Айтматов исемендәге Зур театрга иҗат кичәмне үткәрергә чакырдылар. Менә шунда мин татар җырының нинди зур көчкә ия булуына тагын бер кат инандым».

Һәр җырның язылу тарихы, үз язмышы бар. Ләкин Разил Вәлиев өчен арадан иң кадерлесе – иң беренче язылганы икән. Җитмәсә, ул җырны язарга дәртләндерүче, аның күңеленә җыр оеткысы салучы кеше дә татар җырының Падишаһы икән ләбаса. Хәер, бу хакта мәшһүр җырчыбыз Илһам Шакиров үзе сөйләр...

– 1967 елның көзе иде. Мин, «Мелодия» фирмасында үземнең яңа бер патефон тәлинкәмне яздыру өчен, Мәскәүгә килгән идем. Җырлар сайлап шактый иза чиккәннән соң, ниһаять, бер карарга килдек. Тик мәскәүләр белән сайлаган җырлар арасыннан берсенең көе матур булып та, сүзләре бигүк килешле түгел икән... Инде нишләргә? Мәскәүдә җыр язучы татар шагыйрьләре юк. Шуның өчен Казанга кайтыргамы? Кинәт шагыйрь Разил Вәлиевнең әле быел гына Мәскәүнең Әдәбият институтында укый башлаганы кылт итеп искә төште. Татарстан матбугатында аның моңа кадәр берничә матур гына шигыре басылып, күңелгә кереп калган иде. Такси алып, Разилне эзләп киттем. Тулай торак-

## *Дулкын*

***Чем кара карлыгачлары,***
***Гөнаһсыз иде яры.***
***Ник шунда гына калмады,***
***Ник дулкын китте ары?***

***Тарсынып язмыш ярларын,***
***Ул диңгезгә юл алды.***
***Тау-дулкыннар арасына***
***Кереп күздән югалды.***

***Күз яшьле акчарлаклары...***
***Күренми инде яры.***
***Зәңгәр күк һәм зәңгәр диңгез,***
***Йолдызлар монда бары.***

***Бар иде гөлләр, таллары...***
***Ник китте икән ары?***
***Елга ярын сагынып елый***
***Диңгезнең дулкыннары.***

ны табып, ул яшәгән бүлмә ишеген шакыдым.

– Моңа кадәр гомеремдә бер җыр язып караганым юк бит, Илһам абый, – ди бу миңа.

– Җырлый беләсеңме соң? – мин әйтәм.

– Белүен беләм дә, мәктәп хорында да җырлап йөргән идем әле, – ди Разил энекәш.

– Шулай булгач, тагын ни кирәк? Каләмең бармы? Утыр да яз, – дип, мин китәргә җыендым.

– Кайчанга кирәк? – ди бу, бүтән чарасы калмагач. – Бер айданмы, ярты елданмы? Мәскәүгә тагын кайчан киләсез?

– Минем хәзер бер җиргә барып киләсем бар, – дип, сәгатькә карадым. – Ике сәгатьтән «Мелодия» фирмасында булырга кирәк. Сәгать ярымнан урамга чыгып тора аласыңмы? Җыр текстыңны машинкада ак кәгазьгә басарга онытма! – дидем дә, ашыгып, үз эшләрем белән китеп бардым.

Төгәл сәгать ярымнан әйләнеп килгәндә, Разил, кулына әле яңа гына машинкадан төшкән шигырен тотып, тулай торак ишеге төбендә мине көтеп тора иде.

Халык көенә җырлана торган «Дулкын» җыры менә шулай дөньяга килде. Бу, чыннан да, Разил Вәлиевнең гомерендә беренче язган җыры, җыр дөньясына тәүге адымы иде.

«Дулкын» сугыш вакытында ук ишетелә иде. Ләкин сүзләрендә су да, дулкын да юк, кем нинди куплет тели, шуны ябыштырып җырлый. Разилнең шигырен мин укып чыгу белән ошаттым. Чөнки анда фәлсәфи фикер бар, ил язмышы, халык язмышы турында борчылу бар. Кечкенә елга ярыннан аерылып киткән дулкын шау диңгезгә барып кереп, анда югалу, юкка чыгу язмышына дучар булган. Ә безнең халкыбыз язмышы да шулай түгелмени? Чәчелгән-сибелгән мескен татар әллә кая, Каф таулары артына барып чыга да үзенең «кечкенә елга ярын сагынып» җырлый-җырлый әкренләп эри, юкка чыга бара. Шигырьне укып чыккач та, Разил халыкның шушы ачы язмышын аллегорик рәвештә әйтергә теләгән, дип уйладым мин. Ул чакта, «аерылганны аю ашар, бүленгәнне бүре ашар» дигән әйтемне дә әйтергә курыккан чакта, халкың язмышы турында турыдантуры язып кара син! Заманы шундый иде бит, цензура бугаздан алган чор... Сайдан йөзүче, дулкынның астын күрә алмаучы кайбер тәнкыйтьчеләр: «Бу Разил Вәлиев нинди абстракт шигырьләр яза инде», – диделәр. Менә шул еракка китеп карый белмәү, офыгының тар булуы тәнкыйтьче иптәшләрне нинди ялгышка китергән бит!

Озакламый без Разил белән бергә инде онытылды, инде югалды дип саналган тагын берничә җырны халыкка кайтарып бирдек.

Күпне күргән, күпне кичергән татар халкы, нинди генә хәлгә төшсә дә, туганлык, бергәлек, иминлек турында борчыла, кайгысын уртаклашырга, шатлыгын бүлешергә, бәхетен өләшергә омтыла.

«Бер алманы бишкә бүләек» көенең дә сүзләре юк иде. Аңа шигырь язганда әлеге фикерне әйтергә кирәк дип таптык. Халыкның азатлык, бәйсезлек өчен



көрәше чорында аның бердәмлеге, бөтен нәрсәсе уртак булуы, һичшиксез, зарури. Заманалар узар, тормыш әллә нинди төрләргә үзгәрер, әмма милли азатлык хәрәкәте һичкайчан туктамас. Шушы «Бер алманы бишкә бүләек»тә әйтелгәнчә, кешегә һәрчак үз кайгысын, шатлыгын, бәхетен башкалар белән уртаклашу, бүлешү кирәк булачак.

Разилнең җыр дөньясына ныклап кереп китүендә җырчы-шагыйрь Лев Ошанинның да тәэсире зур булгандыр. Ул Мәскәүнең Әдәбият институтында әлеге мәшһүр шагыйрь һәм профессор уздырган семинарларда биш ел буе иҗат серләрен өйрәнә бит...

Җырчы шагыйрь, көрәшче шагыйрь Разил Вәлиевнең шундый җырлар иҗат итүен мин һәрдаим сөенеп күзәтеп торам. Заманында «Дулкын»га салынган оеткы бәрәкәтле булды. Хәзер инде композиторлар Разил сүзләренә җыр язарга атлыгып торалар. Аның җырчы шагыйрь булып китүендә үземнең дә бәләкәй генә өлешем булуына мин куанып бетә алмыйм.

Илһам ШАКИРОВ,
Россиянең һәм Татарстанның
халык артисты.

PRESSA.RU





Фото интернеттан алынды

# БАЛАЛАР ХАКЫНА...
## ЯКИ ТӘКЪДИР КӨЛМӘК ТҮГЕЛ



Гөлнур
САФИУЛЛИНА

ИРТӘН ИРТҮК ШАЛТЫРАГАН ТЕЛЕФОННАН НИГӘДЕР БЕРКАЙЧАН ДА ХӘЕРЛЕ ХӘБӘР КӨТМИСЕҢ. Ә БУ ЮЛЫ ШИКЛӘНҮЕМ, ЧЫННАН ДА, РАС КИЛДЕ.

**Нәкыя апа, ике генә сүз әйтте дә, трубканы куйды:**
**– Руфинә апаң вафат... Корт чаккан – сырхауханәгә алып барып җиткерә алмаганнар...**

«Күлмәк! Яңа күлмәген бер тапкыр булса да кияргә өлгердеме икән?!» Ул көнне иртәдән кичкә кадәр башымда гел шул уй бөтерелде. Әйтерсең, аның күлмәкне кигән яки кимәгән булуы барысыннан да мөһимрәк иде... Башкортстаннан кунакка килеп йөрүче ахирәте белән Нәкыя апаның мине күптән очраштырасы килә иде инде. «Аның язмышы күпләргә гыйбрәт булырлык», – дип гел кабатлады ул. Ул көнне алар икәү кибетләрдә йөреп кайтканнар иде. Руфинә апага яңа күлмәк алганнар. «Шушы күлмәккә туры китереп яңа сумка да таптым бит әле!» – дип ихластан сөенеп сөйләве әле дә күз алдымда. Гел көтмәгәндә инде менә шушы хәбәр... Беренче очрашуыбыз соңгысы да булыр дип кем уйлаган?! Ул көнне Руфинә апа мине ике сүзнең берендә: «Таһирым гына исән булсын!» – дип кабатлап шаккаттырган иде.

«Исән генә булсын»ны ире дә шулай сүз саен кыстырамы икән?» – яңа танышымны тыңлаганда башымда гел шул уй бөтерелде. Хатын-кыз әйтер... Ул хыянәтне дә гафу итә, башкасын да. Нишләтәсең, без шундый инде... Үзе өчен өзелеп торган хәләлен башка берәү кочагына алыштырган ирнең телендә исә, белмим, бу сүзләр ничек яңгырар икән? Хәер, яңгырармы икән?!

Вакыйгалар менә шундый юнәлеш алмаса, ул минем: «Сезнең белән очрашырга телим», – дип шалтыратуыма, бәлки, кул гына селтәр иде. Күрмәгән-белмәгән кешегә кинәт кенә күңелен ачкан ир-атны очраткан юк әле. Алар җанындагы серләр, гадәттә, тирәнрәк яшерелә, җиде кат биктә була. Әмма Таһир абый минем: «Руфинә апа...» – дип сүз башлавымны ишетүгә: «Ярый, киләм», – диде. Һәм килеп тә җитте. «Хәсрәте тарала төшсен, яраларына кагылмый торыйм», – дип вакытны болай да сузарга тырышкан идем. Әмма барыбер ашыкканмын, күрәсең. Якыныңны мәңге кайтмаска озатканда югалту ачысын юарга бер ел кайдан җитсен, ди, инде?! Таһир абыйның әледән-әле күзләренә мөлдерәп яшь тула, тамагына төер тыгыла, кулы, үзеннән-үзе кесәсендәге валидол төймәсен эзли башлый... Күңеле тулып, ул туктап калган чакларда мин сабыр гына көтәм. Чал чәчле ирнең күңелендә купкан сагыну, юксыну, өзгәләнү давылы аз гына тынсын да... Мин бит бу икәүнең язмышын сезгә Руфинә апа сөйләвендә ишеттерергә теләгән идем. Ә менә ничек килеп чыкты.

Таһир абый сүзне шактый еректан башлады.

– Туганнан туган абыем шахтага эшкә киткән иде. Елга бер туган якка кайта: өс-башы ялт иткән, чемоданы тулы бүләк... Без, яңа гына мәктәп тәмамлап колхоз эшенә тотынган егет-җилән, аңа кызыгып карыйбыз. «Тот та минем янга эшкә кил, энекәш, – диде ул саубуллашканда. – Тормыш кайда да җиңел түгел анысы. Әмма һич югы уч тутырып акча алырсың».

Көзгә тәвәккәлләдем бит. Безнең бригаданы, татарлардан гына торганга, «автоном республика» дип йөртәләр иде. Эштән курыкмыйбыз – безгә җиткәннәр сирәк. Рекорд арты рекорд куябыз. Ул арада хәрби хезмәткә чакыру килеп төште. Гармуннар уйнап, җырлап – нәкъ авылдагыча озаттылар егетләр мине солдатка. Киттем... Җиде тәүлектән соң товар поезды белән Уфага килеп төштек. Туган якка дисәң дә була. Дөрес, безне Уфадан йөз егерме чакрымдагы Бөре каласына алып киттеләр. Яңа тормыш башланды. Армиядә булган ир-егетләр белә инде: берсе икенчесенә бик тә охшаган көннәр... Дөрес, ара-тирә вакыйгалар да булгалый. Минем чаңгы ярышында беренче урынны алуым, мәсәлән. Кар күрмәгән таҗик егетләрен узу алай авыр булмады анысы. Әмма шушы хәлдән соң солдат хезмәтем шактый җиңеләйде минем. Ротаның чаңгычысы санала башладым: махсус кием, чаңгы, ботинкалар бирделәр. Ярты көнем тренировкаларда уза – үз вакытыма күбрәк үзем хуҗа.

## Аерылган ирләре турында хатын-кызларның кайсы шулай әйтә ала?!

Октябрь бәйрәме көнне парадка чыктык. Бездән алда Бөре педагогика училищесында укучы кызлар чыгыш ясады. Миңа фотосурәткә төшерүне дә йөкләгәннәр иде: беррәттән спортчы кызларны да төшердем. Ясадым фотосурәтләрне, инде ничектер бирергә кирәк бит. Тулай торакларын эзләп киттем боларның. Берсенең исемен «Галия» дип ишетеп калган идем. Соравымны ишетүгә, арадан бер кыз: «Мин Галия!» – дип чәчрәп килеп чыкты. Дөрес, сөйләшә башлагач, аның Галия түгел, Руфинә икәне бик тиз ачыкланды. Без шулай таныштык. Фотода иң алда басып торучы кыз булып чыкты ул. Чибәр, ягымлы, шактый чая да.

Инде җай чыккан саен мин боларның бүлмәсенә килеп йөри башладым. Кызлар шунда ук чәй куялар: кем авылдан нәрсә алып килгән, табынга шуны чыгаралар. Берсе белән дә аерым очрашмыйм, «Калганнарыгызны үпкәләтәсем килми», – дип шаяртам. «Алайса башка кызлар белән таныштырыйк», – дип бәйләнәләр. «Юк, кирәкми», – дим. Йөрәгемә кем якын икәнен үзем беләм анысы... Өч ел шулай узды. Минем кайтыр вакыт җитте. «Сайла инде беребезне!» – дип көләләр кызлар. Мин шунда Руфинә исемен атадым...

Укуын тәмамлагач, аны эшкә Күмертауга җибәрделәр. Хат язышып торабыз. Сизәм, яратам мин аны! Мәхәббәтне аерым тору сыный диләр, кая ул оныту: аңа тартылуым көннән-көн арта гына бара. Өзелепләр сагынам үзен... Хат аша килештек тә Уфада очраштык. Икәү кино карап чыктык. «Синсез яши алмыйм, минеке бул, чык миңа кияүгә!» – дим. Шунда ук, өздереп: «Мин риза», – дип тә әйтмәде, «Юк», – дип кырт та кисмәде. «Әти-әниеңне дә бел-

PRESSA.RU



мим, туганнарыңны да», – ди. «Соң кил безгә кунакка», – дим.

Август ае иде, урак өсте. Мин машина белән иген ташыйм. Башкалар көнгә ике рейс ясый, мин – бишне! Өченче рейска – бер, дүртенчегә – ике, бишенчегә өч сум өстәмә акча түлиләр. Район буенча үземне җиңүче дип таптылар, машинама флаг элеп куйдылар. Беркөнне печәнлектә йоклап ятам шулай. Әткәй уята: «Тор, кунак бар!» – ди. Руфинә! Безнең авыл тимер юл кырыенда урнашкан – иртәнге дүрттә «Казан–Уфа» поездыннан төшеп калган ул. Эзләп тапкан менә. Күземә күренә дип торам... Кочаклап, үбеп алганмындыр инде, анысын хәтерләмим. Кызу эш вакыты бит, ул бик тиз китте. Әмма без туйлар турында сөйләшергә өлгердек!

Көзгә мин Казанга күчеп килдем. Таксист булып урнаштым. Шәһәрне белмим, анысына йөри-йөри өйрәндем. Ә ничекләр итеп кооператив фатир алуымны сөйләп тормыйм – сүз озынга китәр. Шахтада эшләп кайткан бер мең ике йөз сум акчам кассада ята иде. Колхоздан да шактый эшләп алдым бит. Тик кулыңда акчаң булса да, торак сатып алу мөмкинлеге юк иде әле ул елларда. «Бу кадәр акча сезгә кайдан килде?» – дип хәтта тикшерүчегә чакырттылар. Саклык кенәгәмне ташламаган идем, шуны күрсәткәч кенә тынычландылар.

*Шундый иде ул, беркайчан миңа авырлык күтәрергә теләмәде.*

Кыскасы, Руфинәне мин яңа йорттагы бер бүлмәле фатирыма алып кайттым. Бер елдан соң булды бу хәл. Бөтен шартын китереп сорарга бардым. Ә әбинең бирәсе килми! Дөрес, табын әзерләде. Мулла чакыртып, никах та укыттык. Әбинең йөзе һаман ачылмый. Җитмәсә, мулла да китешли: «Саграк булыгыз, бигрәк мут күренә!» – дип әйтеп киткән икән. Фатирым бар дигәч, алар бөтенләй шикләнә калдылар: кем бу, нәрсә белән шөгыльләнә янәсе. Шул вакыт тагын бер мәзәк хәл булды. Табыннан торырга өлгермәгән идек, көтү керде. «Терлекләрегез дә бармы?» – дим әбигә. Ул бөтенләй кара коелды. Бу якта кызның бирнәсен шулай диләр икән. Менә сөйли белмәсәң...

Руфинәнең туганнан туганнары безне озата килделәр. Әткәй исән түгел иде инде, авылдан әнкәйне чакырып алдык. Шулай тиз генә туй ясадык. Руфинә мәктәпкә эшкә урнашты, немец һәм рус телләре укытты ул. Яшибез матур гына.

Мине эшкә озатып кала Руфинә, каршы ала. Җайлы, ипле хатын, өйгә кайтып кергән саен сөенәм. Аны да сөендерү өчен еш кына чәчәкләр тотып кайта идем. И-и, куана иде инде! Кешеләр дә яраталар иде Руфинәне. Парлап кая гына барсак та, ул мәҗлесләрнең күркенә әйләнә: җырлый, табыннарны алып бара. Унсигез ел шулай үтте... Бар да әйбәт иде, тик... Балабыз булмады безнең. Кая гына бармады, кайда гына тикшерелмәде Руфинә. Мин дә күрендем. «Гаеп синдә түгел», – профессорның соңгы сүзе шул булды.

Руфинә гел бала дип хыялланды. Телевизордан әниләр яки бәбиләр күрсәтсәләр дә елап ала. Үзе миңа сиздермәскә тырыша. Бик озак уйлап йөргәндер инде, тәвәккәлләп: «Тәрбиягә алсак...» – дип сүз кузгатты берсендә. «Юк инде, Руфинә җаным, кеше каны кирәкмиӈ!» – дип ризалашмадым.

Икенче хатыным белән Польшадан кайткач таныштык. Өч елга дип, хәрби комиссариат аша киткән идем анда. Мин шофер булып эшләгән госпитальдә китапханәче урыны бушады да, бер елдан Руфинәне дә кайтып алдым. Аз гына буш вакыт булса, экскурсиягә чыгып китәбез – Польшаны аркылыга-буйга гиздек икәү. Аннан кайткач, фатирны зурайттык – ике бүлмәлегә күчтек.

Фәниянең дус кызы белән театрга баруы иде. Соңга кала язганнар да такси тотканнар. Миннән унбиш яшькә яшьрәк, авылдан әле генә килгән кыз бу. Чибәр! Күз төште инде. Икенче көнне очрашуга чакырдым моны. Күңелемдә берәүгә дә әйтмәгән ниятем дә бар... Бардым тора торган җиренә, чыкты бу. Сөйләшәбез. Миңа гел сорау арты сорау яудыра Фәния: «Кем белән торасың?» – ди. «Карт әнием белән», – дим. «Сиңа ашарга кем әзерли?» – ди. «Кайчак эштә ашап кайтам, кайчак өйдә», – дим. «Ә Руфинә апа нишли, ул кайда?» – димәсенме берзаман! Бу инде минем хакта ничектер бөтенесен белергә, сорашырга өлгергән! Чая мишәр хатыны инде, нишләтәсең. Шунда ук: «Синнән ак башлы бер малай табып үстерәсем килә», – дип әйтеп, үзенә бәйләп тә куйды. Минем бик тә балам булуын теләвемне дә әйткәннәрдер, күрәсең. «Холкы авырракка охшаган охшавын, әмма анысына гына түзәрмен», – дип, эчтән уйлап куйдым да:

– Тап соң әйдә, акча белән булышырмын, әмма үзең беләсең, хатыным бар – мин гаиләмнән китмим, – дидем.

Биш ел очрашып йөргәннән соң улыбыз туды. Миңа охшаган! Аларны бала тудыру йортыннан каршы ала алмадым, туры килмәде – хатын моның өчен хәзергә кадәр үпкәли. Аннан Фәния тагын балага узды – бу юлы кыз алып кайтты. Мин аларга фатир алырга булыштым, аңарчы тулай торакта яшәделәр. Улым туганда миңа 42 яшь иде инде. Көтеп алган балалар бит, аларны үзем тәрбияләргә тиешмен, дигән нәтиҗәгә килдем. Мин бу карарны кабул иткәндә, улыма – өч, кызыма яшь ярым иде. Руфинә бу яңалыкны, бу хәбәрне авыр кичерде дип кенә әйтсәм, аз булыр... Миңа да җиңел булмады. Аны да, үземне дә: «Балалар хакына бит...» – дип юаттым.

Беренче мәлләрдә Руфинә янына гел кереп йөрдем. Фатирга үзем түли идем – аңа бу яктан бер дә авырлык китерәсем килмәде. Без беркайчан талашмадык, гел матур гына, тыныч кына аралаштык. Әйе, икенче хатыным яшьрәк тә, чибәррәк тә иде. Тик болар бит барысы да икенче урында. Минем өчен беренче урын-

да һәрвакыт балалар булды. Алар булмаса, юк, мин бу адымга бармый идем... Укырга кергәнче үк икесен дә бассейнга бирдем. Мәктәпкә, ата-аналар җыелышларына гел үзем йөрдем. Икесе дә әйбәт укыдылар. Улым университетның юрфагын тәмамлады, өйләнде, прокурор ярдәмчесе булып эшли. Икесе белән дә араларыбыз бик якын, әмма Руфинә апасы турында улым гына белә.

Берара Руфинә: «Уфага күчсәм?» – дип карады. «Анда якын бер кешең юк, берьялгызың нишләрсең?» – дидем. Аннан: «Мин авылга кайтып китәм, Таһир, әнине карарга кирәк», – диде. Әнисе ике ел урын өстендә ятты. Без гел аралашып, хәбәрләшеп тордык. Елга ике тапкыр Казанга килә иде ул. Килгән саен күрешәбез, акча бирәм. Ул гел: «Кирәкми, минем акчам бар бит, Таһир», – дия иде. «Булса да ал, җаның кая тели, шунда бар, дөнья күр. Йөрү, сәяхәт итү гомерне озынайта ул», – дим. Без бит бергә торганда гел йөрдек. Камчаткаларга кадәр барып җиттек. Һиндстанда булып кайттык.

Бер килүендә, сүз арасында: «Түбәдән су үтә», – дип ычкындырды. Өй түбәсен калай белән яптырдым. Ябучы кешесенә кадәр Казаннан алып кайттым. Мин ялгыз дип кимсенмәсен, кайгы-борчу, мәшәкать күрмәсен дидем инде... Йортны сайдинг белән тышлатырга да акча бирдем. «Бик матур килеп чыкты. Авылда: «Руфинәнең ире Казанда эшли, ул булыша», – дип сөйлиләр», – диде. Фотога төшереп алып килеп тә күрсәтте.

Умарта кортына аллергия минем, дип әйткәне бар иде. Ул көнне Руфинә бакчасына сарафаннан гына чыга. Корт аның иңбашын чага. Үзенә-үзе укол да ясый ул. Күршеләренә хәбәр итәргә дә өлгерә. Тегеләре шунда ук «Ашыгыч ярдәм» дә чакырталар. Әмма әҗәле җиткән булгандыр инде, күрәмсең – сырхауханә ишеге төбендә җан бирә ул...

Сеңлем белән дә аралаша иде ул – туганнары аңа шалтыратканнар. Ул исә – миңа... Руфинәнең өй номерын җыйдым. «Әйе, барысы да хак. Иртәгә җирлибез...» – диләр. «Алайса мин килеп җитәм», – дим. Берәүгә дә әйтмәдем, җыендым да чыгып киттем... Җыендым дип, башыма хәтта түбәтәй алырга да онытканмын. Көтмәгән хәбәрдән югалып калганмындыр инде... Чаллы, Минзәлә, Дүртөйле, Борай... Кичкә кайтып кердем. Руфинәне инде алып кайтып салганнар. Түрдә ята, бәгырькәем... «Йөзен ачып күрсәт инде», – дим балдызга. Иелеп маңгаеннан үбеп алдым... Гафу итегез, күңелем тула...

Юл кайттың, дип, урын җәеп бирделәр. Кая ул йоклау?! Төнне мәет саклаучылар янында утырып уздырдым. Әкрен генә таң атты. Иртән капкаларны төбенә кадәр ачып куйдылар. Мин барып чәчәкләр алып кайттым. Ул арада озатырга халык җыелды. Хушлашу башланды. Миңа да сүз бирделәр:

– Бик кешелекле иде Руфинә. Аны яратучылар Казанда да күп иде, – дидем. Шуларны гына әйттем дә, менә хәзерге кебек тагын күңел тулды. Башка бер сүз дә өсти алмадым. Карале, валидол да каптым бит, барыбер тынычланып булмый...

Ләхеткә үзем иңдермәдем, шулкадәр халык алдында елармын дип курыктыммы икән соң? Хәзергә кадәр үкенәм. Югыйсә мәетне кабергә иң якын кешеләре төшергәнен белә идем. Өчесен, җидесен, кырыгын үткәрергә, каберенә таш куярга акчалар биреп калдырдым. Ел ашына да бардым әле мин аның. Яңа машина алган идем. «Авылга кайтам әле», – дидем дә китеп бардым. (Дөрес, каяндыр сизенеп, кич хатын тавыш куптарды. Юк, Руфинәнең үлгәнен әйтмәгән идем, белгәндер, андый нәрсәләрне тиз ишетә ул. «Кайткач сөйләшербез», – дип, трубканы куйдым да башка җавап бирмәдем. Инде малайдан шалтыраттыра бу. «Әти, син кайда?» – ди улым. «Башкортстанда, Руфинә апаңның ел ашында», – дим. «Исән-сау кайт, әти», – диде дә саубуллаштык.)

## *Руфинә ул мал, байлык, дип, минем белән беркайчан тавыш чыгармады...*

Аштан соң Руфинәнең туганнары җыелды. Елыннан соң йортын сатү турында күптән сөйләшкән идек инде – туганнан туган сеңлесе читтән кайтып аның бакчасына йорт салды. «Сиңа нинди өлеш чыгарыйк, Таһир?» – диләр. «Миңа Руфинәдән берни кирәкми, – дидем. – Ул миннән беркайчан да артыгын таләп итмәде». Чыннан да шулай булды, Польшадан алып кайткан бөтен сервизларны, келәмнәрне миңа биреп җибәрде ул. Фатирыбыз да минем малайга калды. Әле күптән түгел улым аны сатарга рөхсәт сорады. «Юк, – дидем. – Әниегезнең холкын беләсез... Мине кем карап күмә, фатир шуңа була». Яшермим, кадерле миңа ул фатир...

Төшкә кергәне юк дисәм дә була. Бер-ике тапкырны санамаганда. Күңелемдә аның турында гел матур хатирәләр генә саклана. Ярый әле очрашканбыз, дим. Ә аерылу... Анысы балалар өчен иде бит! Фәния... Оныклар үстерәбез инде, ә үзебез һаман язылышмаган. Ул – балаларымның әнисе. Ә мин – улым белән кызымның әтисе. Баштагы елларда: «Закон белән кавышыйк», – дип еш сорый иде. Хәзер искә төшергәне юк. Загс кәгазе хөкүмәт өчен генә кирәк, безнең мөнәсәбәтләрдә барыбер бернәрсәне дә үзгәртмәс иде ул...

...Казанга соңгы килүендә алган яңа күлмәген, юк, кияргә өлгермәгәндер Руфинә апа. Кайтып кына киткән иде бит әле. Бәясе язылган кәгазе дә өзелмәгән ул күлмәкне туганнары: «Руфинә апа төсе итеп киярсез», – дип, бәлки, авылдагы берәр танышына биргәннәрдер. Әйе, күлмәкне кияргә дә, салырга да, үзеңә ошамаса, башка берәүгә дә бүләк итәргә була.
Ә тәкъдиреңә язылган язмышны менә «күңелемә ятмый әле», дип, берничек ташлап калдыра алмыйсың. Сиңа язылганны – син үзең яшәргә, үзең күрергә, үзең кичерергә тиеш. Руфинә апа кебек...

PRESSA.RU











# КЕМДӘ НИЧЕК, БЕЗДӘ ШУЛАЙ



Ләйсән Рәхмәтуллина

**КЕШЕ ҮЗЕН ЧОЛГАП АЛГАН МОХИТКӘ ТОРА-БАРА ИЯЛӘШЕП, АҢА ИГЪТИБАР ИТМИ БАШЛЫЙ, КАЙВАКЫТТА ГАДИ ГЕНӘ НӘРСӘНЕ ДӘ КҮРӘ, ТОЯ БЕЛМИ.**

**Ә менә инде ул күздән югалса, бөтенләй башка дөньяга эләксә, шунда ук юклыгын сиздерә, сагындыра икән. Минем белән дә нәкъ шулай булды.**

Моннан берничә ел элек мин – авыл кызы, Германиягә барып чыктым. Алман телен чарлау иде максатым. Анда алман гаиләсендә гувернантка булып эшләргә туры килде. Бу гаиләгә килгән өченче гувернантка идем мин. Балалар да бу хәлгә күнеккән, кем килер икән, дип, зур кызыксыну белән ишек төбенә үк чыгып каршы алдылар. Берсеннән-берсе кечкенә... балаларның, борчак кебек тәгәрәшеп, этешә-төртешә каршыга чыгып басулары бүгенгедәй күз алдында. Ул арада әниләре Беттина күренде, шунда ук алар, бертавыштан диярлек, кычкырып та җибәрделәр:

– Hallo, Leysan! Wie war dein Flug?

Һәм менә шушында биш ел университетта укып өйрәнгән алман телем тел очына бөгәрләнеп килде дә катып калды. Бар белгәнемне һәм батырлыгымны җыеп:

– Hallo, Guten Abend, Kinder, – дип кылтырап, чак ишетелерлек тавыш белән мин дә исәнләштем. Пәри башка, җен башка дигәндәй, китаптан өйрәнү – бер нәрсә, сөйләшү икенче икән ул...

Гаилә башлыгы «Folkswagen»да инженер, ул бөтән шәһәрдә эшли иде. Шуңа күрә гаиләсе янына җомга эштән соң гына кайта. Беттина (хуҗабикәнең исеме) – белеме буенча укытучы, әлегә декрет ялында. Аның әтисе – фермер, бәрәңге һәм кишер үстерү белән шөгыльләнгән. Хәзер аның бу эшен төпчек улы дәвам итсә дә, ул әле һаман аңа булышып йөри, әниләре – хуҗабикә. Алманнар, төгәл халык буларак, бер генә төрле эш белән мәшгуль: табиб икән – табиб, укытучы икән – укытучы. Алардагы авыл укытучысы яки табибы эштән кайткач бездәге сыман эш аты кебек хуҗалык эшләренә җигелми.

Монда да мин авылга килеп эләктем. Бремен шәһәреннән йөз чакрым ераклыкта, урман эчендәге Отерзен дигән кечкенә генә авылда яши иде бу гаилә. Биредә балалар бакчасы, янгын сүндерүчеләр штабы, кибетләр, авылдан бераз читтә чиркәү бар. Мәктәп күрше авылда, балаларны анда автобус йөртә. Башка зуррак авыллардагы кебек кунакханә, кафелар юк.

Мин күреп ияләшкән, туып-үскән авылга охшамаган бер оҗмах почмагыдай тоелды ул башта. Иң беренче чиратта күзгә ташланганы, әлбәттә, чисталык булды: юллар төзек, тирә-якта чәчәкләр, яшеллек эчендә утырган төзек, матур өйләр. Ике катлылары да шактый. Татар авылларындагы сыман капкалар тапмассың, биек коймa, рәшәткә ише әйберләр дә күзгә чалынмады. Бар җирдә диярлек «тере читән» – тигез итеп шакмаклап киселгән куаклар. Чәчәкләрнең нинди генә юк! Искитәрлек! Ботактан ботакка сикерешеп йөрүче тиеннәре белән бу авыл бөтенләй әкияти кебек тоела. Ишегалларына йә тигез юлдан, йә матур ташлар түшәлгән тротуардан үтәсең, һәр тарафта ямь-яшел газоннар, төрле төс белән балкып утырган чәчәкләр.

Җәйнең соңгы ае булуга карамастан, кичләрен әле шактый җылы. Шунлыктан балалар мине үзләренең өй тирәсе белән таныштырырга булдылар. Бүлмәгә кереп әйберләремне калдыргач, алар белән бакча карарга ашыктым. Нинди икән ул? Кызык бит, помидорлары пешкәнме? Бәрәңгеләрендә шулай ук кортлар бар микән? Өй артына чыксам, әле могҗиза бетмәгән икән бит! Яшел келәм җәелеп ята диярсең: тигез итеп кыркылган газонлы парк каршы алды. Мондагы иркен болында балалар рәхәтләнеп уйный, кунаклар килгәндә, өлкәннәр учак ягып утыра. Күңел дигәнең һаман чагыштыра бит әле ул: бездә булса, әрәм-шәрәм ятмасын дип, печән үстерерләр иде анда дим. Шунда ук өстәл, эскәмия, урындыклар тезеп куелган, гамак та бар. Һәммәсе ял итү өчен җайлаштырылган. Әнә, юан кәүсәле агачка таган да элеп куйганнар. Чаттарак кечкенә генә җирдә яшелчә түтәлләре күзгә чалынды. Анда дүрт төп помидор, фасоль, кишер, укроп, петрушка, базилик, тимьян, розмарин, салат, тагын әллә нинди ят үләннәр үсә иде, һәм нибары бер-ике буразна бәрәңге!!! (Әллә тәҗрибә өчен генә утыртылган инде?) Ашарлык бәрәңгесе булмагач, корты да юк инде.

## *Беренче атналарда, колак-тел күнеккәнче, елмаеп кына йөрдем...*

Беттина чәчәкләрне үлеп яратанга, бер ханымның үз бакчасында ачык ишекләр көне үткәрүе турында гәҗиттән укып белдек тә, балалар белән машинага төялеп чыгып та киттек. Бу кадәр күп чәчәкне минем әле беркайда да күргәнем юк иде! Бар вaклары, зурлары, сарылары, аклары, үрмәләп үскәннәре, җәелеп киткәннәре. Һәр нәрсә зур зәвык белән эшләнгән.

Беттинаның вакыты җитмәгәнлектән, бакчаны кайчакларда чакыртылган бакчачы карап киткәли иде. Кечкенә чактан шунда казынып үскән бала буларак, мин дә авылымның бәрәңге, яшелчә бакчаларын искә төшерә-төшерә, чүп утый, сулар сипкәли башладым – сагынуымны шулай бастым. Яз җиткәч, яшь ботаклардан читән үреп, зуррак балаларга җир бүлеп бирдек. Кайсы борчак, кайсы фасоль, кемдер кишер утыртты. Барысына да кызык иде башта, бөтен кеше бакчада кайнаша бит! Балалар эшкә өйрәнеп үссен өчен кирәк ул дип аңлатты Беттина. Тора-бара балаларның кызыксынуы кимеде, бакча онытылды. Инде кул астына керерлек булсалар да, алар бу эш өчен җаваплы түгел иде. Теләкләре булса гына килеп ярдәм итә алалар. Үз үсентеләренә су сибәргә, чүбен утарга кирәклеген искәртteләр генә, берәү дә баланы эшләргә мәҗбүр итмәде. Бездәге балалар исә, түтәлдәге чүпне утап, кичен су сипкәч кенә дуслары белән уйнарга чыга ала.

Сүз, гамәлләр ягыннан шактый гына иркәле алман балалары да елый, көйсезләнә беләләр. Тыңламаган очраклар да булгалады. Балаларга тавыш күтәрү бик сирәк күренеш, ә башкасы турында сөйләп тә торасы юк. Тыңлата алмыйсың икән, анысы – синең эш. Бервакыт шулай өч яшьлек малайларын подгузниксыз йөрергә өйрәтә башладым. Үземчә аңлатам моңа: «Менә

PRESSA.RU



кара, соңгысы, башка подгузнигың калмады», – дим. Озак уйлап утырмады, мине кухняларындагы шкаф янына китереп, һәр баланың исеме язылган кечкенә савытларга күрсәтте дә: «Әнә анда минем акчаларым бар, бабам миңа алып кайтып бирә», – дип авызымны ябып та куйды. Ул бала хаклы иде. Германиядә әти-әниләр балаларына кече яшьтән үк банкта счет ачып, шунда атна саен (яшьләренә карап билгеләнгән күләмдә) акча салып бара. Зуррак балалар әтиләренә шул савытларга акча салу кирәклеген дә искәртә. Хәтта алты айлык баланың да инде акчасы җыелып бара...

Гаиләдә биш бала, иң олысына сигез яшь, иң кечкенәсенә әле нибары өч көн иде. Бәләкәй Ребекканың ике зур апасы һәм абыйсы булуга да карамастан, кирәк вакытта аның белән уйнаучы, караучы табылмаска да мөмкин. Син аларга ярдәм сорап мөрәҗәгать итә аласың. Монда балалар бу яктан да ирекле.

Болай тәрбияләгәндә, чын эгоистлар үсүе дә ихтимал дип уйларга була. Ләкин шул ук вакытта аларда һәрвакыт рәхмәт әйтү, нәрсәдер сораганда, үтенүле тавыш белән «мөмкинме» дию зарур. Бу кагыйдәнең үтәлешен әниләре гел тикшереп тора, үзе дә балаларына зур үрнәк күрсәтә. Кайда гына булмасын, ата-ана киләчәк буынны тәрбияле, итагатьле, шәфкатьле итеп күрергә тели.

*Монда һәрвакыт ата-ана килешү юлын табу ягында.*

Әйләнә-тирәлекне ярату хисен тәрбияләү йөзеннән, йомшак куяннар да асрый иде хуҗаларым. Болары олыраклар җаваплылыгында. Кайвакытта, үзебез карыйбыз дип алынган хайваннарны ашатырга иренсәләр дә, әниләре белән берлектә бу көндәлек эш тә үтәлә килде. Алман балалары куян үстерсә, безнекеләр җаен казбәбкә карый, бозауларга яшел үлән җыя, су эчерә.

Бик төгәл халык дип дан тоткан алманнарда, чынлап та, көндәлек тормыштагы тәртипкә зур игътибар бирелә. Мәктәпкә автобус белән барып кайтканнан соң, һәрберсенең үз хоббие. Әниләре кайсын гитара, флейта уйнарга, кайсын дзюдога йә француз теленә йөртә. Алар анда телне өйрәнеп кенә калмый, берәр тәм-том пешереп, сыйланып та кайталар. Шул авылдагы бер француз хатыны атнага бер тапкыр өендә дәрес бирә. Эшләре беткәч, бездәге авыл балалары кебек уйнарга да чыгып чаба алмыйлар. Әти-әнидән рөхсәт сорау мәҗбүри, әгәр дә инде дустың белән уйныйсың килә икән, шалтыратып, уйнау вакытын билгеләү бик мөһим. Төшке аштан соң кешеләр ял итә, шуңа күрә бары көндезге сәгать өчтән соң гына телефон шалтыравын ишетеп була. Язылмаган бу канунны балалар бер карусыз үти.

Шундый кануннарның берсе – ашау алдыннан кулгакул тотынышып, Аллаһы Тәгаләгә дога кылу, рәхмәт әйтү иде. Бары шуннан соң гына ризыктан авыз итәргә мөмкин. Аш вакытлары да төгәл билгеләнгән сәгатьтә, соңга калу рөхсәт ителми. Өстәл янында әле әйбәтләп утыра да белмәгән ике яшь ярымлык бала алдына да чәнечке белән пычак куела. Ул матур, пөхтә итеп, башкалардан үрнәк алып ашарга өйрәнергә тиеш. Культуралы кеше тәрбияләүгә игътибар зур булса да, татарлардагы кебек олы кешеләргә, әби-бабайларга булган тирән ихтирамлы мөнәсәбәтне күрмәдем мин анда. Биредә өлкән буынны һичшиксез яраталар, хөрмәт итәләр, бергә концерт-театрларга йөриләр. Әмма бездәге оныклар кебек дәү әти, дәү әниләргә булышу юк, аралашу гына.

Әти-әнисенең, туганнарының, дусларының туган көненә үз кулы белән бүләк ясамаган, чәчәк җыймаган бала бар микән ул?! Беттина да балаларын матурлыкны күрә белергә, үз куллары белән гүзәллек тудырырга өйрәтә иде. Шуңа багышланган нинди генә китап юк эш бүлмәләрендә! Оригами, квиллинг, пластилин белән эшләү дисеңме! Һәр бала үзе теләгән әйберне сорап, кирәксә, олылар ярдәме белән башкара ала. Алар әниләре белән бергә рәхәтләнеп вакыт үткәрәләр. Чөнки монда аларның сыер савасы да, бәрәңге үстерәсе дә юк!

Бездә әле бик популяр булып җитмәгән аудиокитап тыңлауны балалар үлеп ярата инде менә. Яисә китапны аларга йоклар алдыннан олылар укый. Телевизор карау бик сирәк монда, атнага бер-ике тапкыр ярты сәгать чамасы гына. Гадәттә, ул берәр мультфильм яисә хайваннар турындагы фильм була. Пульт бары тик олылар кулында гына.

Тагын бер игътибарга лаек нәрсә – балаларга кече яшьтән дини тәрбия бирәләр. Дөрес, бездә дә ял көннәрендә кайбер авылларда мәчет яны мәктәпләре эшли анысы. Ләкин бу әле сирәк күренеш. Германиядә исә һәр айның бер ялында чиркәүдә балалар өчен махсус чаралар үткәрелә иде. Бәйрәмнәрдә кечкенә генә скетчлар куялар, Тәүрат белән танышалар. Теләк белдерсәләр, йоклар алдыннан балалар өчен аңлаешлы телдә язылган махсус Тәүрат укылган көннәр дә булды.

Германиядә барлык эшне дә диярлек машина яисә махсус белемле кеше башкара. Шуңа күрә балалар өй эшләреннән азат. Табак-савытны, керләрне машина юа, киптерә, идән-тәрәзәләр гувернантка карамагына кала. Менә шундый ул алман авылы баласы! Минем иелеп идән юганымны күргәч, Беттина аптырап калды: «Бездә алай юмыйлар», – дип кулыма швабра тоттырды.

Безнең халык исә бөтен эшнең рәтен белә, җиренә җиткереп башкара. Авыл балаларының әти-әнисе белән утырып рәсем ясарга вакыты булмаса да, алар бу вакытны печәндә яисә көтүдә үткәрә. Менә шул хуш исле иксез-чиксез болыннарда, тугайларда ятып җиләк җыйганда таныша да инде ул матурлык белән! Дзюдо, каратэ биргән көч-егәрлекне бәрәңге бакчаларында, болыннарда ала татар авылы баласы!

Беттинаның әйтүенә караганда, гувернанткаларны алар күбрәк Россия, Украина кебек илләрдән алу ягында, чөнки Европаныкылар сагыз чәйнәп, колакчыннар асып йөрүдән узмый.

Кайда гына, кемнәр генә булмасын, һәр ата-ана алдагы көннәрендә үзенә тиң алмаш әзерләргә тырыша шул. Аның намуслы, чын кешеләр үстерәсе килә!



НУР Гамил

Казан дәүләт ветеринария институты, Галимҗан Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының аспирантурасы.

Карьера:
Журналист, шоумен, хәләл һәм аек бәйрәмнәр оештыручы.

Тормыш шигаре: «Миңа беркем бернәрсә тиеш түгел!»

https://www.facebook.com/suyumbike.zhurnaly

## Милли хисләр уяна!


Владимир шәһәреннән шалтыратып, мине, милли җанлы табынчы буларак, аек туй алып барырга чакырдылар. Туганнары да, дуслары да күбесе руслар икән. Әти-әниләр каршы булса да, яшьләр үзләре шундый теләк белдергәннәр, туганнарын да күндергәннәр. Минем аша татар колоритын күрсәтергә теләүләредер... Казаннан татарча китаплар, флаг, магнитлар алып килергә сорадылар – иң беренче бәйрәмнәрен татар мәдәниятен пропагандалауга багышлаячаклар. Үзләре шулай диләр. Алар Владимирдагы «Бәхет» исемле кечкенә генә татар клубында танышканнар.



## Илбашыннан бер рәхмәт


Рамазанда Казанның бик күп мәчетләрендә утызар көн ифтар үткәрәләр хәзер. Ә бит моннан ун ел элек беренче ифтарларны «Шәрык» клубында миңа һәм татар журналистларына оештыра башларга туры килгән иде. Инде ул мәчетләргә һәм спонсорлары булган мәхәлләләргә күчте. «Ярдәм» мәчетендә узган бер ифтарны алып барырга чакырдылар быел. Күзләре күрмәүчеләр янына Президент вазыйфаларын вакытлыча башкаручы Рөстәм Миңнеханов та килде. Соңыннан ул хәзрәткә шалтыратып: «Рәхмәт! Әйбәт чара булды. Алып баручыны дөрес сайлагансыз», – дигән. Бу миңа бик зур бәя булды!

## Дуслык хәерлерәк!

Конфронтация киңәйгән бер вакытта дөньяда дуслашу процессы да бара. Файдалы дошманлыкка караганда, начар булса да, дуслык хәерле! Халыкара мөнәсәбәтләрне йомшартып, Куба белән АКШ дипломатик мөнәсәбәтләр урнаштыра башлады – «салкын сугыш»ка, ниһаять, нокта куелды. Вашингтон үзенең илчелеген – Кубада, Куба үзенекен Америкада ачты. 1961 елда, Куба җитәкчелеге Американың утраудагы милкен тартып алгач бозылган иде ике ил арасындагы дуслык.

сөендерде  
көендерде 

сөендерде  
көендерде 

сөендерде  
көендерде 

## Вакытны ничекләр җиткерәсе?!

Аек туйлар форматы әкрен генә Башкортстанга да күчеп бара – аларда аек тормыш рәвеше милли идеягә әверелеп килә. Ә алып баручылары: «Әйдә, күтәреп куйыйк!» – дип әйтмичә кунак сыйлый белми әле... Башкортстанның ерак районнарына, Чиләбе, Свердлау, Пермь, Төмән, Омск, Томск якларына, бик чакырсалар да, барып җитә алмыйм. Ара ерак! Дусларымны, коллегаларны да гел җибәреп булмый. Әйе, хәмерсез туй үткәрергә теләгән яшьләр читтә дә күп, тик ничек оештырырга белмәгәнгә генә моңа тотынмыйлар.

## Без Кырым түгел ләбаса...

Быел бик күп яуган яңгырлар Болакның ярларын тәмам юып бетерде – караган саен йөрәк әрни. Нигәдер анда көньяк төбәкләрдә генә үсә торган зур, биек пирамидаль тупыллар утырттылар. Трамвай юлы буйлата да шактый күп итеп утыртканнар иде аларны. Кызганыч, быел кыш шуларның күбесе өшеде. Нигә шәһәрне яшелләндерү өчен үзебезнең тал, тупыл, каен, миләш, балан, зелпе кебек агачларны сайламыйлар икән?! Елга ярында, гадәттә, әрәмәлек үсә бездә, бөдрә таллар... Болакны да чын, табигый хәлендә күрәсе килә.

## Ислам диненә тагын тап...

Бөтен интернет шаулый: Кабулда бер мөселман кызын башта кыйнаганнар, аннан яндырып үтергәннәр...
Ул бер муллага: «Дөрес эшләмисез», – дигән булган. Мулла аңа шуның өчен нахак гаеп ташлаган: «Коръәнне яндырды», – дигән.
Кайбер кешеләр үз гамәлләрен әнә шулай ислам диненә, аның югары кыйммәтләренә сыенып кыла.
Суд кызны гаепсез дип тапкан. Чынбарлыкта ул изге китапны яндырмаган, хәтта киресенчә, үзе Коръән укытучысы булган. 4-5 кешене төрмәгә утыртканнар, тагын унлап кешене эзлиләр. Ә кыз бит инде юк...

PRESSA.RU



16+

# МӘХӘББӘТСЕЗ ЯШӘП БУЛМЫЙ

Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя... Ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән? Сүзне аларга бирик.



**Эрнст МУЛДАШЕВ,** медицина фәннәре докторы, профессор, Бөтенроссия күз һәм пластик хирургия үзәге директоры, Россиянең атказанган табибы, спорт туризмы буенча спорт мастеры, СССРның өч тапкыр чемпионы. Өйләнгән.

**1 Иң элек хатын-кызда нәрсәгә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...**

– Башта күзләренә игътибар итәм. Кайбер хатын-кыз беренче карашка әллә ни матур күренмәскә дә мөмкин, әмма күзләре янып тора икән, минем өчен ул шундук дөньяның бер чибәренә әйләнә. Хатын-кызның күзләрендә Мәхәббәт чагылуын яратам – бәхетлеләр гел матур була...

**2 Хатын-кызның кайсы сыйфатларын гафу итәргә була?**

– Мин, мөгаен, аның башка кешегә гашыйк булуын гафу итә аламдыр. Дөресрәге, аңлый аламдыр. Нишлисең, көчләп үзеңне яраттыру берничек тә мөмкин түгел... Йөрәк мондый мәсьәләдә кеше сүзен түгел, үзенекен дә тыңламый.

**3 Ә нәрсә өчен бик якын хатын-кызны да гафу итмәс идегез?**

– Мин күңелемә якын хатын-кызны комсызлыгы өчен гафу итә алмас идем. Күзләрендә доллар гына күренсә, байлыктан башка аны бернәрсә кызыксындырмаса, акчага гына хирыс булса... Абау, андыйдан Ходай үзе сакласын!

**4 Хатын-кызлар икегә бүленә: ир-атны илһамландыручы алиһәләр һәм өйдә аның өчен комфорт тудыручы хуҗабикәләр. Сезгә аның кайсысы якынрак?**

– Өйне ямьләп, бизәп, өйгә җылылык биреп торган хатын-кыз якынрак миңа. Хатын-кыз өйне карасын, ә ир-ат ул – эш кешесе.

**5 Ир кеше өчен аның хатыны дус та була аламы?**

– Юк, дуслык бит ул мәхәббәт түгел. Әгәр мин хатынымны дустым дип саныйм икән, мәхәббәт, ярату турында онытырга кирәк, димәк. Дуслар арасында мәхәббәт була алмый. Мин, гомумән, хатын-кыз белән артык якынаерга тырышмыйм. Бәласеннән башаяк диләрме әле: үзең дә сизмичә мәхәббәт маҗарасына тарып, дусларың белән араны өзүең бар (син дуслашкан хатын тирә-юнеңдәге берәр танышыңның хәләл җефете булып чыкса, дим). Хатын белән дә тик торганнан нигә мөнәсәбәтләрне бозарга, катлауландырырга? Яратам, хөрмәт итәм бит мин аны.

**6 Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганны хәтерлисезме?**

– Безнең әле студент чак иде. Совет чоры бу. Чәчәкләр бүләк итеп, машиналар бизәп, рестораннарга чакырып тәкъдим ясап булмады, әлбәттә. «Син гомергә минеке булырга ризамы?» – дип сорагач, елап җибәргән иде ул. Күз яшьләре аша сөенечтән балкып миңа карап торганы әле дә истә.

**7 Ир кеше, хатын итеп, әнисенә охшаган кызны сайлый, диләр...**

– Минем гаиләдә нәкъ шулай. Җәмәгатем Татьяна Петровна татар хатыны булмаса да, әнигә бик охшаган: аның кебек үк өйне ярата. Дөресен әйтәм, мин бит кунак кебек кенә: кайтам, алдыма нәрсә куялар шуны ашыйм, йоклыйм, ял итәм... Хуҗалыкны ничек алып барырга икәнен белмим. Безнең өйдә кайда нәрсә ятканын күз алдыма да китермим. Боларның барысын да хатыным гына белә. Әни мәрхүмә дә шундый иде.

**8 Хатыннары ирләреннән күбрәк мал тапкан гаиләләр бар... Ир кеше бу очракта үзен ничек тотарга тиеш?**

– Акчаны өйгә ир-ат алып кайтырга тиеш тә бит, нишләтәсең, тормышта кайчак киресенчә дә килеп чыга... Дөнья соңгы вакытта бик үзгәрде, кыйбласын

югалткан кебек тоела ул миңа. Хатын-кызлар, гомумән, ирләргә караганда үзләрен акыллырак тоталар бүген. Кешелек җәмгыятендә матриархат өстенлек иткән дәверләр булган, аны патриархат алыштырган.
Кем белә, без бәлки тагын матриархатка кайтып барабыздыр? Яшерен-батырын түгел, чын ир-егетләр кимеп бара бит. Гомосексуалистлар килеп чыкты менә.
Әллә космостагы кайбер үзгәрешләр кешегә шулай тәэсир итә инде? Ярый, безнең халыкны ислам дине тотыбрак тора. Боларның барысын да уйлагач, хатын-кызның ирләргә караганда бүген малны күбрәк табуына гаҗәпләнмим.

**9 Гашыйк булуын башлап хатын-кыз үзе белдерүгә ничек карыйсыз?**

– Сез миннән мондый җавап көтмисездер, билгеле, тик үземне заманнан алай артта калган кешегә санамыйм... Әгәр хатын-кыз сине якын иткән, сине сайлаган икән, нигә, бик мөмкин. Ул беренче булып: «Мин сине яратам», – дисә, әйбәтрәктер дә әле. Яшерен-батырын түгел, ир-атны үзенеке итү өчен хатын-кызларның үз ишләре белән йодрыкка-йодрык килгән очракларны да беләм.

**10 Хатын-кызларны ир-атларда иң беренче чиратта нәрсә җәлеп итә?**

– Чын ир кеше булулары дип уйлыйм.

**11 Хатын-кызның үзегезнең кайсы якларыгызга игътибар итүне көтәсез?**

– Тырышлыгымадыр, бәлки? Мин бик күп эшлим. Төнге өчләргә кадәр эштә утырганым бар. Андый чакларда кайтам да авам инде. Ярый, хатыным аңлый.

**12 Ир-атны артык чибәр һәм көчле хатын-кызлар куркыта, диләр.**

– Чибәр ханымнарның ир-атларны куркытуына, өркетүенә шаккатмыйм мин. Андыйлар, гадәттә, синең энергияңне дә суыра торган булалар әле. Сихерлиләр... Дөресен әйтәм, чибәр хатын-кызларны мин үземә бик якын китермәскә тырышам.

**13 Ир-ат һәм хатын-кыз логикасы дигән төшенчә бар.**

– Әлбәттә, алар бер-берсеннән аерыла. Ир-атныкы – конкрет, төгәл, ә хатын-кызныкы – эмоциональ. Нинди эшкә тотынсалар да! Ир кешенең логикасы кырыс, каты булырга тиеш, ә хатын-кызныкы – йомшак, җылы...

**14 Ир-ат белән хатын-кыз икесе ике галәмнән икәне билгеле инде. Кайчакларда аларның бер-берсен аңламаулары шуннан килеп чыга да. Хатын-кызның нигә нәкъ менә шулай эшләгәнен үзегез аңламаган берәр очракны искә төшерегез әле.**

– И-и, хатын-кызның нигә шулай эшләгәнен аңлап бетермәгән очраклар шундый күп алар... Алай гына да түгел, вакыт-вакыт хатын-кызның үзен бөтенләй аңламыйм мин! Ярату гына бөтенесен оныттыра, килешергә, ризалашырга мәҗбүр итә.

**15 Хаклы икәнеңне яхшы беләсең, әмма хатыныңның үз туксаны – туксан, хаклык аның ягында дип саный. Мондый очракта нишләргә?**

– Нишлисең, хатын-кыз белән бәхәсләшеп дәрәҗәңне төшерә алмыйсың инде... Аңлатырга тырышып карыйм каравын, барыбер үз фикерендә калганын күрәм икән, борылам да китәм – бәхәсне тагын куертып тормыйм.

**16 Ир кеше ачыгып, арып-талып эштән кайтып керә, ә өйдә ашарга пешмәгән. Хатыныгыз, мин ардым, дип, диванда кырын ятып тора.**

– Безнең гаиләдә мондый хәлнең булганы юк! Булмас та! Тәүлекнең теләсә кайсы вакытында өйгә кайтып керсәм дә, хатыным мине табын әзерләп, җылы ризык белән каршы ала. Ашамыйча йокларга яту... Юк, мин бу хәлне күз алдыма да китерә алмыйм!

**17 Сер түгел, берәр җиргә җыена башласак, без, хатын-кызлар, соңга калучан...**

– Нишлим, көтәм, түзәм инде... Хатын-кыз кеше арасына матур булып чыгарга тиеш. Бу – бәхәссез!

**18 Хатын-кызлар еш кына... бүләк сайлауда ялгыша: ир-атка ошамастай бүләк бирә.**

– Мине бүләкләр күптән кызыксындырмый, дулкынландырмый... Әйе, яши-яши шулай да була, тормыш кыйммәтләренә карата карашың нык үзгәрә икән. Беләсезме, хатын-кызның күзләрендә сиңа булган хөрмәт, ярату, мәхәббәт чагылса – менә шул иң зур бүләк була! Мәхәббәттән мәхрүм булу – бу тормышта иң авырыдыр...

Редакциядән: Табиб Эрнст МУЛДАШЕВ – бөтен дөньяга билгеле шәхес. Бүгенге офтальмология өлкәсендәге казанышларга ул инде дистә еллар элек ирешкән.
Зур галим, медицина өлкәсендә яңа юнәлешкә – регенератив хирургиягә нигез салган кеше.
Ул уйлап тапкан «аллоплант» биоматериалының авыру кеше организмына ничек, нинди юллар белән тәэсир итүен, сәламәтләндерү серен аңлата алучы юк. Әмма чирлеләр терелә! Мулдашевның Уфа шәһәрендәге Үзәгендә дөньяда моңа кадәр ярдәм итеп булмый дип саналган күз авыруларына да дәва табалар.
Ул – чын-чынлап Могҗиза тудыручы! Аны Тибет һәм Мисырга булган сәфәрләре – экспедицияләреннән соң язган китаплары, мәкаләләре буенча да беләләр.
Алдагы саннарыбызда бу сәяхәтләр турында да язмалар булачак.

PRESSA.RU



**Гөлнара КХТИның җиңел сәнәгать, мода һәм дизайн факультетын тәмамлаган. Борынгы читек-кәвешләргә карап: «Боларны ничек чиктеләр икән?» — дип сокланган кыз берзаман үзенең дә күн мозаикасы белән кызыксынып китәчәген уйламагандыр да әле. «Казан җөе» серләренә күн остасы Илдар ШӘЙХЕТДИНОВтан өйрәнгән ул. Гөлнараның кызыксынганы бер ул гына түгел: кына белән тәнгә бизәк төшерү (мехенди) һәм тегү белән дә мавыга сәләтле кыз. Тегү буенча мастер-класслар күрсәтә.**
**Без укучыларыбызны «Сөембикә»нең 2014 елгы ноябрь санында «Казан җөе»н чигәргә өйрәткән идек инде. Хәзер Гөлнара белән бизәк кисәргә өйрәнербез һәм бергәләп күн янчык чигәрбез.**






Мастер-классны Гөлнара ГЫЙНИЯТУЛЛИНА үткәрә.

# БИЗӘКЛЕ КҮН ЯНЧЫК

***Кирәк:***

- янчык тегү өчен 17x43 см үлчәмендәге йомшак күн;
- бизәк өчен 10x10 см зурлыгындагы башка бер төстәге күн (ясалма күн дә ярый);
- бизәкнең урта өлеше өчен 5x5 см булган тагын бер күн кисәге (зуррак булса, кисү өчен уңайлырак);
- «молния» замогы;
- машина энәсе сапланган без;
- камыт энәсе;
- чигү җебе;
- армирланган ныклы тегү җебе;
- орчык;
- балавыз;
- чигү станогы.





Янчыкка чигеләсе бизәк. Аның иңе – 9 см, буе – 10 см.




***Эш барышы:***

■ Ак ватман кәгазенә алгы якның макетын – 14x20 см үлчәмендәге турыпочмаклык сызабыз. Аның уртасына иңе – 9, буе 10 см булган тагын бер турыпочмаклык – бизәк урыны сызыла.

■ Бу соңгы сызган кечкенә турыпочмаклыкны күчергеч кәгазьнең читенә





дә сызарга кирәк булыр. Шунда бизәкне ясарбыз.

■ Күчергечтәге турыпочмаклыкның бер ягына бизәкнең яртысын ясагач, урталайга бөкләп, шул эздән икенче яртысын төшерәбез. Тигезлек бозылмасын өчен шулай эшлибез. Күчергечтәге бизәкнең чит-читләрен йомшак карандаш белән җиңелчә буйыйбыз. Ә уртадагы «тамчы» тулысынча буяла.

■ Бизәкне буялган ягы белән ватман кәгазенә салабыз. Күчергечтәге турыпочмаклыкның читләре ватман кәгазендәгесе белән туры килсен. Бармак бите белән сак кына сыпырып, бизәкне ватманга күчерәбез.

■ Ватман кәгазен тактага салып, бизәкне каләм эзе буенча махсус пычак белән кисәбез. Бу – үрнәк була. Аны янчык тегеләчәк күнгә салып, каләм белән эзен төшерәбез (бизәк урынын янчык күненә алдан ук билгеләп куярга кирәк. Ул алгы якның кыл уртасында булырга тиеш). Күнне тактага салып, пычак белән каләм эзеннән кисәбез.

■ 10x10 см зурлыктагы чәчәкле күн дә шушы ук үрнәк белән киселә. 5x5 см зурлыктагы күннән уртадагы «тамчы»ны кисәбез. Бизәкне җыеп, сул яктан тамгалар сызабыз. Чиккәндә алар бер-берсенә туры килергә тиеш.

■ Инде чигү эшенә керешик. Камыт энәсенә сапланасы тегү җебен балавызлыйбыз. Чигү җебен исә 14 катлап, орчыкка чорныйбыз. Шуннан 1,5 метр җеп сүтеп алып, орчыкка элмәкләп куябыз. Бу җепне катабыз. Җеп очын шулай ук орчыкка элмәкләп торабыз. Катылган җеп беткән саен, элмәкне ычкындырып, яңадан катабыз.

■ Чигү кечерәк кисәкләрне зуррагына ялгау тәртибендә башкарыла. Станокка бизәкнең кырый өлешен каеш белән кысып куябыз. Шуңа, «Казан җөе» белән чигеп, уртадагы «тамчы»ны ялгыйбыз. Чигү техникасы белән, әйткәнебезчә, журналыбызның 2014 елгы ноябрь саныннан танышырга була.

■ Бизәк әзер булгач, станокка янчык күнен салабыз. Инде янчык белән бизәкнең үзен тоташтырыйк. Чигеп бетергәч, күнне чак кына чылатып, авыр әйбер белән бастырып тотабыз – тигезләнсен.

■ Янчыкның чит-читләрен машина җөе белән тегәбез. Тегәргә керешкәнче алгы як белән арткы якны читеннән генә аяк кием җилеме белән ябыштырып куябыз – шуып, урыныннан күчмәсен.

■ Ахыргы эш итеп янчык авызына «молния» замогы тегелә.

■ «Казан җөе» белән чигүне видеога да яздырдык. Аны сайтыбыздан карый аласыз.

PRESSA.RU



# АМЕРИКАНЧА ИРТӘНГЕ АШ



**Иделияне кемнәрдер «Татарстан—Яңа гасыр» каналындагы «Яшьләр тукталышы» тапшыруының алып баручысы буларак хәтерлидер. Кемгәдер ул татар эстрадасына яңалык булып килеп кергән җырлары белән таныш. Экраннардан ник юк булды, дисәк, Иделия Америкага ук китеп, Майамида яши икән. Бәйсез компания белән килешү төзеп, Америкада җырлар яздыру белән мәшгуль. Бүген ул «Сөембикә» укучыларына Майамиларның бик яраткан иртәнге ашын әзерләп күрсәтә (гәрчә америкалылар үзләре ашарга әзерләми, кафеларда туклануны хуп күрә икән). Әчкелтем бу ризык йокыны ача, күңелне күтәрә.**



***Кирәк:***

(бер кеше өчен)

- 1 әзер күзикмәк (калынрак булса әйбәт);
- 1 кызыл помидор;
- ярты баш суган (кызылы яхшырак);
- 1 кисәк татлы борыч;
- 2 йомырка;
- 5-6 шампиньон;
- 1 тәгәрмәч халапиньо дигән яшелчә (ачы борыч белән алыштырып була);
- 50 г каты сыр;
- 0,5 бал кашыгы лимон суты;
- зәйтүн мае;
- аштәмләткеч үләннәр.

*Эш барышы:*







■ иң элек яшелчәләрдән соус әзерлибез. Моның өчен помидор, суган, аштәмләткеч үләннәр һәм орлыгыннан арындырылган баллы борыч белән халапиньоны бик вак итеп турыйбыз.

■ Эре итеп туралган гөмбәләрне майлы табада кыздырабыз. Гөмбә әзер булгач, йомыркаларны сытабыз, тоз сибәбез. Тәбәне сыеклыгы беткәнче болгата-болгата кыздырабыз. Йомырка өстенә сыр уып сибәбез.

■ Коры табаны кыздырып, төргәгебезне шунда салабыз һәм ике ягын да җиңелчә генә кызартып алабыз. Табынга аны урталай бүлеп чыгарабыз. Янына кибет каймагы куябыз.







■ Туралган яшелчәләрне бер савытка бушатып, тәменчә тоз сибәбез. Лимон суты һәм 1 бал кашыгы зәйтүн мае салып, бик яхшылап болгатабыз.

■ Кузикмәкнең бер читенә иң элек гөмбәле тәбәне салабыз. Аның өстенә соусны түшәп, кузикмәкне тәгәрәтеп төрәбез.

**P. S.** Бу ризыкны үзегез яраткан теләсә кайсы яшелчәдән әзерләп була. Гөмбә урынына ит ризыклары кулланасаң да ярый.

*«Ә» дигәнче.*

# АЛМАЛЫ ТӨЕНЧЕКЛӘР




**«Сөембикә» журналы игълан иткән аш-су конкурсыбыз дәвам итә. Чираттагы катнашучыбыз — ФАТЫХОВА Адилә. Белеме буенча юрист ул. Ире Адил һәм кызы Амелияне төрле тәм-томнар белән сыйларга ярата. Көтелмәгән кунаклар килә калса, Адилә һич югалып калмый, моның өчен аның әллә никадәр рецепты әзер. Шуның берсен ул безгә дә тәкъдим итә.**

*Кирәк:*

• 1 кап туңдырылган катлы камыр (слоеное);
• 3 алма;
• шикәр комы;
• 100 г атланмай;
• туңдырма.

*Эш барышы:*

■ камырны җебетәбез һәм 10 сантиметрлы шакмакларга бүләбез.
■ Алманы юып, юка телемнәргә турыйбыз.
■ Һәр шакмакның уртасына бер уч алма салабыз. Алма өстенә шикәр комы сибәбез, 1 бал кашыгы атланмай куябыз.
■ Шакмакны дүрт читеннән күтәреп, төенчек ясыйбыз.
■ Төенчекләрне майлы табага тезеп, 200 градус кызулыктагы мичкә тыгабыз.
■ Өсте кызаргач, мичтән алып бераз суытабыз һәм табынга биргәндә һәр төенчек өстенә берәр аш кашыгы туңдырма салып чыгабыз.

PRESSA.RU



**Җәй көне хатын-кызның бар җире дә матур булырга тиеш. Ә менә үкчәләр турында күп вакыт онытып та җибәрәбез. Алсу, йомшак үкчәләр — хатын-кызның тагын бер бизәге ләбасы. Матур үкчәләрен ялтыратып атлаган хатын-кыз артыннан үзегез дә сокланып карап каласыздыр әле. Яргаланып һәм каралып беткән үкчә берәүне дә бизәми. Үкчәләрне йомшарту өчен берничә киңәш тәкъдим итәбез. Берәрсен сынап карагыз әле.**



# ҮКЧӘҢНЕ ДӘ ОНЫТМА

! Беренче эш итеп, аякларны ярты сәгать буе сабынлы җылы суда парландырабыз. Суга диңгез тозы яки чәй содасы да кушарга мөмкин. Чәй содасы тирене йомшарта. Аннан соң аякны корытып, түбәндәге ысулларның берсен сынап карыйбыз.

! 1 йомырка сарысына 1 чәй кашыгы лимон суты һәм 1 аш кашыгы крахмал кушып болгатабыз. Шушыны үкчәгә сылап, кипкәнче тотабыз. Аннан соң аякны җылы суда юып, үкчәгә майлы крем ягабыз.

! Менә бу ысулны куллану да яхшы нәтиҗә бирә. Алоэның зур бер сусыл яфрагын изеп, үкчәгә ябабыз һәм полиэтилен элпә белән урап, өстеннән оекбаш киеп куябыз. Төнлә шулай йоклыйбыз. Алоэ яраларны бик яхшы төзәтә.

! Телевизор караган арада да вакытны бушка үткәрмибез. Пешкән бәрәңгене кайнар килеш изеп, шуңа ваклап туралган ярты баш суган белән кәбестә яфрагы кушабыз. Шушы боламыкны ике капка бүлеп салабыз, капны аякка чорнап куябыз.

! Суганның үзен генә кулланганда да нәтиҗәсе яхшы. Бер баш суганны урталай бүлеп, бер-ике кат кайнар су белән пешекләп алабыз да, шуны үкчәгә бәйләп, йокларга ятабыз. Иртән аякны кырчын таш (пемза) белән ышкып юабыз, майлы крем сылыйбыз.

! Ваклап туралган канлы үләннән төнгелеккә куелган компресс та файдалы. (Канлы үлән тиредәге гөмбәчекләрне җиңәргә дә булыша.)

! Каешланган үкчәне эре бөртекле тоз (ә иң яхшысы – диңгез тозы) кушылган зәйтүн мае белән ышкып карагыз әле. Зәйтүн мае үкчәне йомшарта, ә тоз чистарта.

! 1-2 алманы уып, 200 г сөт, 1 чәй кашыгы чәй содасы кушып болгатабыз һәм калын итеп үкчәгә ягабыз. Өстеннән бинт һәм полиэтилен элпә белән урап, ярты сәгать тотабыз.

! Бик нык яргаланган үкчәләрне дәвалар өчен ак чыршы (пихта) бәлзәме дә булыша. Аны үкчәгә калын итеп ягып, өстеннән бинт белән урап куярга һәм шул килеш төнгә калдырырга кирәк.

! Пешекләнгән кәбестә яфрагына бал сылап, шуны үкчәгә ябу да бик файдалы. Бал яраларны төзәтсә, кәбестә яфрагы тирене йомшарта. Кәбестә яфрагы булмаса, балның үзен генә ягарга була.

! Үкчәләр ярылып интектерсә, менә бу рецепт та файдалы булыр: тигез күләмдә парафин, салицил кислотасы һәм балавыз алып, шуны «су мунчасы»нда эретегез дә, җылы көенчә үкчәгә ягыгыз. Бер каты кипкәч, икенче һәм өченче кат итеп ягарга кирәк. Шуның өстеннән бинт белән урап, йокларга ятыгыз.
Иртән аякны сабынлы-содалы җылы су белән юып, кырчын таш белән ышкыгыз.


! Халык ысуллары нәтиҗәле булса да, үкчә ярылу – организмга А һәм Е витамины җитешмәүне аңлата. Безнең рецептларны куллану белән бергә, өстәлегездә шушы витаминнарга бай ризыклар да күбрәк булсын. А витамины сөттә, йомырка сарысында, балык маенда күп. Ә Е витаминына үсемлек майлары, чикләвек һәм бодай ярмасы бик бай.


**КУЧКАР.** Эшегез һәм бурычларыгыз күбәеп китәр. Көтелмәгән эшләр килеп чыгу ихтималы зур. Талантыгызны ачу өчен бик яхшы ай. Нииндидер бер очраклылык тормышыгызны үзгәртеп җибәрер.


**ҮГЕЗБОЗАУ.** Үзгәрешләр күп, ләкин аларның барысы да сезнең өчен файдалы түгел. Иркенәергә җай чыкмас. Җитәкчеләр белән бернинди дә бәхәскә кермәгез. Тыныч кына яшисегез килсә, көндәлек күрсәтегез. Яңа эш башлау өчен җайсыз вакыт.


**ИГЕЗӘКЛӘР.** Теләсә кайсы бәхәстән җиңеп чыгачаксыз. Бу айда җиң сызганып эшләсәгез, киләчәктә моның файдасын күрерсез. Тормыш биргән мөмкинлекләрне файдаланып калырга тырышыгыз – отарсыз. Эшегездә күтәрелер өчен дә яхшы ай.


**КЫСЛА.** Тоткан юлыгыздан бераз читкә каерырга туры килер. Тормыш гел үзгәрештә шул, кичә яраган бүгенгә ярамаска да мөмкин. Әлек кызыксыз тоелган нәрсәләр белән мавыга башлавыгызны үзегез дә сизми калмагаегыз. Иске гадәтләрдән җиңел генә котылырсыз.


**АРЫСЛАН.** Мәшәкатьле ай булырга охшаган. Проблемаларны хәл итү өчен актерлык осталыгы күрсәтергә туры килер. Дусларыгызның ярдәмен тоярсыз, алар кирәкле вакытта кирәкле кеше белән таныштырырлар.



**СӨМБЕЛӘ.** Әлегә кадәр сез гел саклык күрсәтә килдегез. Инде аяк терәп, үз сүзегезне әйтер вакыт җитте. Сезгә тәвәккәл булырга, кыю гамәлләр кылырга туры килер. Яңача яши башлау өчен кулай вакыт. Эштәге авырлыкларны җиңеп чыгачаксыз.


**БИЗМӘН.** Тормышка яңалык һәм үзгәреш кертү өчен кулай ай түгел. Барлык мәсьәләләрне дә гадәти юл белән хәл итегез, нииндидер могез чыгару сезгә файда китерми.


**ЧАЯН.** Хыялларга чумарсыз. Шушы хыялый халәтегез тирә-юньдәге мәшәкатьләргә күз йомдырачак. Ә бит мәсьәләне вакытында хәл итү кирәк, югыйсә ахырдан сезне гаепләүчеләр табылачак. Җитәкчеләр белән уртак тел табу өчен яхшы вакыт.


**УКЧЫ.** Кайсы да булса бер өлкәдә үсеш кичерерсез. Бу карьера үсеше дә, рухи үсеш тә булырга мөмкин. Әлек бик катлаулы тоелган вакыйгалар да җиңел генә хәл ителер. Тормышның яңа этабын башлар өчен уңай ай.


**КӘҖӘМӨГЕЗ.** Нәрсәнедер үзгәртер өчен башка бер вакытны көтегез. Ә менә яңа планнар корыр өчен шәп ай. Эштә көтелмәгән «урак өсте» башланыр. Тәкъдимнәрегез булса да, аларны берәүгә дә сиздерми торыгыз, вакыты ул түгел.


**СУКОЯР.** Бу айда үз-үзегезгә генә ышаныгыз. Бер егылып, бер торырсыз – катлаулы чор. Шулай да өметсезлеккә бирелмәгез, иң кирәкле вакытта көтмәгән җирдән ярдәм килеп ирешер. Һәр карарны мең кат үлчәгәч кенә кабул итегез, ялгышу ихтималы бик зур.


**БАЛЫК.** Баштарак уңышсыз ай кебек тоелса да, соңга таба яхшы нәтиҗәләр күренә башлаячак. Әллә кайчаннан ияреп килгән эшләрне менә дигән итеп башкарып куячаксыз. Яңа тәкъдим һәм идеяләрегезне яшереп яткырмагыз. Җитәкчегез үзегезне бәяләр.

## августта кабынган йолдызлар

### Татарстан



**Лима Кустабаева** (3.08.1945) – **Россиянең халык артисты, Россия һәм Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, профессор.**
Магнитогорскида туа. 1969 елда Казан консерваториясенә укырга керә. Студент чагында ук Ленин исемендәге Мәдәният йортындагы капелла белән җитәкчелек итә. Татарстан Министрлар Кабинеты каршындагы һөнәри техник белем бирү идарәсенең җыр һәм бию ансамблендә эшли, музыка училищесында укыта. 30 елдан артык гомерен Татарстан дәүләт җыр һәм бию ансамбленә багышлый. 1978 елдан аның сәнгать җитәкчесе була, ансамбльне дөньяга таныта. 25 ләп театральләштерелгән тамаша авторы. 2000–2008 елгача «Сәйдәш» мәдәният үзәгенең директоры, 2008 елдан – арт-директоры.

### Россия



**Екатерина Васильева** (15.08.1945) – **актриса.**
Мәскәүдә туа. Әтисе – танылган шагыйрь Сергей Васильев. Атаклы педагог Антон Макаренконың якын туганы. 1962 елда ВГИКка укырга керә. Аны тәмамлау белән үк, 1967 елда Мәскәүдәге М. Н. Ермолова исемендәге драма театрына эшкә алына. Беренче тапкыр «На завтрашней улице» фильмында кечкенә генә роль башкара. Берара «Современник»та эшли, аннан МХАТка күчә. Танылу китергән фильмнары – «Солдат һәм патшабикә», «Адәм белән Һава». 1993 елда сәхнәне калдырып, монастырьга китә. 1996 елда яңадан сәхнәгә кайта, «Королева Марго», «Графиня де Монсоро» телесериалларында уйный.

### Чит илләр



**Морин Фитцсимонс** (17.08.1920) – **актриса.**
Ирландиядә туа. Әтисе – бизнесмен, әнисе опера җырчысы. Балачактан ук үз аббатлыкларының сәхнәсендә уйный һәм соңрак Дублиндагы драма мәктәбендә сәнгать серләренә өйрәнә. Саф сопрано тавышка ия кыз опера җырчысы булырга хыяллана. Дублинда укыганда ук аңа Лондонда фильмда төшү бәхете елмая. Шунда аны британияле актер Чарльз Лоутон күреп алып, үзенең компаньоннарына тәкъдим итә. Нәтиҗәдә, «Mayflower Pictures» киностудиясе Морин белән җиде елга килешү төзи. Зур экраннарга чыккан тәүге эше: «Таверна «Ямайка» фильмы. Аннан соңгы «Париждагы Изге ана соборы бөкресе» фильмы да уңыш китерә. Үзен таныткан иң яхшы рольләрен ул режиссер Джон Форд төшергән фильмнарда уйный.

PRESSA.RU









# ТӨСЛӘР КӨЕН ИШЕТӘМ

Аның остаханәсендә – бихисап савыт-саба. Киштәсендә – китаплар. Аларның да саны бихисап. Булат – китап рәссамы. «Менә «Сөембикә белән Леонардо да Винчи». Сөембикә дә, Чечилия Галлерани портретындагы кебек үк, кулына ас тотып утыра. Ханбикә даһи Леонардо сызымнары буенча очу аппараты ясаткан һәм... күрәсезме, ул Казан күгендә оча!» Булат үз фантазиясенә үзе шат. Ул башка яшәү яссылыгындагы имраларны да сурәтләп караган хәтта. Булат Әлфир улы театрлар өчен спектакльләр бизи, милли фестивальләрдә катнаша. Алабуганың 1000 еллыгына багышланган фильм өчен җыр язарга һәм Россия сынлы сәнгать академиясенең Казандагы иҗат остаханәсендә дәресләр алып барырга да өлгерә. Мәртәбәле исемнәр иясе: Б. Урманче һәм М. Җәлил исемендәге дәүләт премияләре лауреаты. «Кыйссаи Йосыф» – әтисе бу китапны алып кайткан көннән бирле Булат өчен юлдаш. «Йосыф кыйссасы» темасын гомерем буе язачакмын», – ди ул. Аның диплом эше инде «Евразия» триптихы итеп киңәйтелгән, һәм ул «Россия яшьлеге» күргәзмәсенең «Рәсем техникасындагы үзенчәлек өчен» номинациясендә җиңү яулаган әсәр, Кол Галинең тууына 830 ел тулу уңаеннан нәшер ителгән «Кыйссаи Йосыф» китабы да аның иллюстрацияләре белән бизәлгән. «Алтынчәч турындагы риваятьләр», «Мәгърифәтчеләр», «Болгар риваятьләре» серияләре... Алар арасындагы «Җир җиләге», «Пышылдау», «Бер әйләнеп карадым», «Кәләш»... ягъни «Төшләр» сериясен Булат Шәрык сәнгате калыбына салып, томанлы, тонык төсмерләр белән, күп мәгънә өстәп иҗат итә. Ул бит әле шигырьләр дә яза. «Башта көй ишетәм, аннан соң гына күңелгә сүзләр килә. Сәнгать тә минем өчен шул ук көй. Мин линияләр ритмын, Ак һәм Кара көчләр көрәшен сизәм, җылы һәм салкын төсләр берләшүен күрәм, һәм әгәр дә алар бер-берсе белән гармониягә керә алса, димәк, җан халәтемне күрсәтеп бирүче картинам әзер», – ди рәссам. Иҗатындагы башка теманы да үз гомер агышы белән бәйләп алып бара – заман хатын-кызларын гаярь болгар амазонкаларының якты образлары сыман сурәтләп, гасыр хәтеренә терки. Аның өчен Ватан – газиз. «Мин үз төшемнән үзем куркып уяндым. Төшемдә кешеләр... төрекчә сөйләште! «Арт-Истанбул» Халыкара сынлы сәнгать ярминкәләрендә катнашсам да, Әнкараның сәнгать галереялары белән 5 ел рәттән хезмәттәшлек итсәм дә, тәмам төрекчә сөйләшеп, Төркиядә яшәп калырга теләсәм дә, кире уйладым», – ди Булат. Үз тамырлары береккән җиргә кире әйләнеп кайткан кылкаләм остасы бүген Болгар дәүләте хакында зур күләмле картиналар яза. Димәк, картиналарындагы төсләр көе – борынгы көй. Күкләр Булатка бик күп сәләт биргән. Һәм ул алга бара!

Булат өчен иң мөһиме – аны борынгы болгар халкының илаһи Рухы үз итә. Димәк, без генә түгел, картиналарын яратып өлгергән бүтән илләрнең сәнгать сөючеләре дә аның тарихи юнәлештәге классик әсәрләрен күреп тагы бер кат сокланырлар. Иҗатчы тамгасына ия Булат Гыйльванов үзе дә картиналарына билгеләр сала. Мәсәлән, чия. Аның өчен ул – мәхәббәт һәм тормыш концентрациясе. Алма – бала-багалма. Билге-символлардан торган әсәрләр иҗат кешеләренә хас нәрсә. Чөнки алар белә: мәңгелек – алда!

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА













БУЛАТ ГЫЙЛЬВАНОВ

PRESSA.RU




МАССАКҮЛӘМ МАТБУГАТ ЧАРАЛАРЫ БӘЙГЕСЕ



ЛЕГЕНДАЛАРНЫ БЕЛЕГЕЗ!
БРЕНДЛАРНЫ САЙЛАГЫЗ!

ТАТМЕДИА

ЛЕГЕНДАР БРЕНДЛАРЫ

TATMEDIA.RU САЙТЫНДА
ТАВЫШ БИРҮДӘ КАТНАШЫГЫЗ



ДҮРТ НОМИНАЦИЯДӘ ТАВЫШ БИРЕРГӘ МӨМКИН:

- ЛЕГЕНДАР ГАЗЕТА
- ЛЕГЕНДАР ЖУРНАЛ
- ЛЕГЕНДАР ТЕЛЕРАДИОКОМПАНИЯ
- ЛЕГЕНДАР МУЛЬТИМЕДИЯЛЕ РЕДАКЦИЯ

TATMEDIA.RU

ТАТМЕДИА

Реклама, 16+. Акцияне оештыручы – "ТАТМЕДИА" АҖ. Үткәрү сроклары һәм акция турында тулырак мәгълүмат www.tatmedia.ru сайтында.




КОНКУРСНЫҢ ГЕНЕРАЛЬ ПАРТНЕРЫ:
«ПРОСТО МОЛОКО» ИК ҖЧҖ

ЯРАТКАН ЖУРНАЛЫБЫЗ ӨЧЕН ТАВЫШ БИРЕРГӘ СОҢЛАМАГЫЗ!
«СӨЕМБИКӘ» ИСЕМЕН БЕРГӘЛӘП ТАНЫТЫЙК!